PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№5 (305) – МАЙ 2017

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Безнең дөнья сурәте

Ашаган белми, тураган белә

Онытырлык түгел бер гомер

РОССИЯДӘГЕ ТӘҖРИБӘБЕЗ ЕВРОПАГА КИРӘК

PRESSA.RU

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Авторлар: Хәмидә Гарипова, Катерина Котова,
Ксения Сёмина, Фаяз Хуҗин, Әлфия Шамова
Фотографлар: Ната Смирнова, Дмитрий Резнов
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Диана Сираҗиева

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-1130

Басарга кул куелды: 19.05.2017

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Коммерция директоры:
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com,
тел. (843) 222-09-76
Сату бүлеге белгече:
Гөлфия Фәттахова
Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ДУСЛЫК БЕЛӘН СУГАРЫЛГАН...

Әлеге саныбыз яз һәм халыклар дуслыгы хисләре белән сугарылган – һәм бу социаль челтәрләрдәге гадәттә уңай ракурслардан камерага елмайган яз һәм дуслык түгел. Бүген монда барысы да самими һәм матур, кешене үзгәртеп җибәрүдән бигрәк, аны чын итә, асылын күрсәтә торган милли костюмнардан. «Татарстан» мондый кешеләрне Татарстан халыклары съездында күзәтте. Төрле милли костюмнар барлык милләт вәкилләрен чын-чынлап бизи. Бу инде төсләрнең җетелеге буенча бернинди карнаваллардан калышмый, чөнки монда әкият персонажлары түгел, бәлки халыкларның борынгы, инде онытылып бара торган матурлыгы калкып чыкты.

...Әле кичә генә кар яудырган күктә язгы болытлар йөзә, аларны, мөгаен, көньякның җылы җилләре бирегә кагадыр, чөнки Халыклар дуслыгы йортында җыелган кешеләр арасында тарихи Ватаннары Кавказ республикалары, көньяк-көнчыгыш илләре булганнар биниһая күп җыелган иде. Зал шау-гөр килде, һәркайда дуслык атмосферасы хөкем сөрде. Шундый дуслык-татулык белән сугарылган халыклар инде без! Бу турыда сезгә «күкрәгендә» Халыклар дуслыгы ордены балкыган «Татарстан» журналы сөйли!

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
900 сум 00 тиен

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ



Рәссам: Вреж Киракосян

МАЙ. КАЗАН

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Мең чалымлы дөнья.
Татарстан халыклары съезды үзенә масштаблылыкны, ихласлыкны һәм гармонияне ничек итеп сыйдыра алган

10. Бердәмлек – төрлелектә.
Европа Советы мәйданчыкларында нинди тәҗрибә таләп ителәчәк

32. Татарстан алдындагы казанышлар.
Күк капусы кемгә ачылган

34. Законадагы үзгәрешләр.
Авыл кибетләренә яңалык ни китерер

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

42. Кече Ватан патриотлары.
Татар язучыларыннан кем өч сугышны кичкән

46. Хәтеребез көйләре.
Ни өчен без бүген дә сугыш җырларын җырлыйбыз

50. Тыл ветераны.
Озак яшәүнең сере нидә

62. Аш-су.
Кычыткан ашы ничек тәмле була

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

60. Тарих битләре.
Болгарлар Урта Иделгә кайчан күчкән

64. Оркестр репетициясе.
Нәрсә ул «татарча джаз»

68. Мода.
Татар ләләсе кайчан чәчәк ата

76. Китап киштәсе.
«Ел китабы» бәйгесендә кайсы китап җиңде

108. Татар авыллары.
Күгәрчен авылында нәрсә белән мавыгалар

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

22.04

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – ТР халыкларының III съездында:

– Советлардан соңгы чорда Татарстанда кулланылган үсеш моделе иң уңышлыларның берсе булып чыкты. Бүгенге көндә республика ирешкәннәрнең барысы да – күп буыннарның – төрле милләт вәкилләренең тырыш хезмәте нәтиҗәсе ул. Мин сезгә, Татарстанның күпмилләтле халкы вәкилләренә, аңлап эшләвегез һәм турыдан-туры катнашуыгыз, туган республикабыз һәм безнең гомуми уртак Ватаныбыз хакына күрсәткән хезмәтегез өчен ихлас ихтирамымны белдерергә телим.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

07.04

Александр Хлопонин, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары, – Казанда чүп яндыру заводы төзү проекты турында:

– Без пилот проектларына кайсы төбәкләр дәгъва итәчәге турында карар кабул иткәндә, Татарстан өстенлекле урын алган иде. Республикада беркайчан да иң катлаулы һәм стандарт булмаган бурычларга алынудан куркып тормадылар. Яңа заводка экологик таләпләр дөньяда иң югарылардан берсе булачак.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

18.04

Валерий Гергиев, дирижёр, Мариин театры җитәкчесе, – Әлмәттә Мариин театрының Симфоник оркестры куйган концерттан соң:

– Мин үзем осетин, һәм илнең төп казанышы аның кешеләре генә түгел, ә бәлки аларның коллектив хәтере, аларның үз тамырларына, чыгышына, безнең бөек казанышыбыз – Россиянең күпмилләтле мәдәниятенә битараф булмаган мөнәсәбәт дип саныйм, ә Татарстан анда – мәдәни мирас буенча әйдәп баручы булып тора.

Фото: president.tatarstan.ru, yarreg.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстан халыклары съезды **НИЧЕК** үтте

Европа Советы мәйданчыкларында **НИНДИ** тәҗрибә таләп ителәчәк

Нәни мигрантларны алар өчен чит мохиткә **НИЧЕК** адаптацияләргә

Күк капусы **КЕМГӘ** ачылган

Авыл кибетләренә яңалык **НИ** китерер

PRESSA.RU

Фото: Дмитрий Резнов

БЕЗНЕҢ ДӨНЬЯ СУРӘТЕ

Татарстан халыкларының III съезды үзендә, беренче карашка, бик төрле булган нәрсәләрне гаҗәеп рәвештә берләштерде. Соңгы 25 елда республика узган юлның җитдилеге... Милләтләр һәм диннәр арасында алып барылган эш тәҗрибәсенең күләмлелеге... Күптән күрешмәгән һәм менә кабат очрашкан кешеләр өчен бәйрәм рухияте... Уртак сәбәп – үз йортына, үз җиренә мәхәббәт хисе берләштергән төрле мәдәниятләрнең гармониясе.

PRESSA.RU

Автор:
Ксения Сёмина

СЕЗНЕҢ БЕЛӘН БУЛДЫРАБЫЗ!

Съездның меңгә якын делегаты һәм кунагы җыелган зал, алтын һәм куе кызыл төсләрдә бизәлеп, мизгелнең тантаналы булуын чагылдыра иде. Ә нотыкчыларның бер-бер артлы ясаган чыгышлары киң күләмле һәм һәр нәрсәне колачлаган гомуми бер тарихка – үз халыкларының бердәмлеген һәм килешеп яшәвен үсеш нигезе итеп алган бүгенге Татарстанның барлыкка килү тарихына берләште.

Без, журналистлар, сәхнәдән яндарак – ложаның икенче рәтендә урын алдык. Беренче рәттә – яулыклы әбекәй белән бәрхет түбәтәй кигән, чандыр гәүдәле ир.

Фәрит Мөхәммәтшин, оештыру комитеты рәисе буларак, съезд эшен башлап җибәрү тәкъдимен кертკәч, әбекәй делегат карточкасы төшерелгән бейджикны бик теләп югары сузды.

Трибунага беренче булып күтәрелгән Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев үзенә хас колачлылык белән рус-татар татулыгы тарихындагы мөһим чорларга кагылып узды.

– Бу – «Повесть временных лет» елъязмасында теркәлгән тарихи факт. Әле 985 елда ук Владимир кенәз белән татарларның ерак ата-бабалары – болгарлар арасында килешү төзелгән. Анда мондый юллар бар: таш суда йөзә, ә икмәк бата башлагач кына, безнең арада тынычлык бетәр.

Янымда утырган делегат кызның шулчак смартфоннан интернетта таш белән икмәк турында гыйбарәне эзләгәнен күреп алдым. Текст ачылгач, ул аны җентекләп укырга кереште, шул ук вакытта Татарстанның беренче Президенты чыгышын борынгы язма белән чагыштыргандай, әледән-әле башын күтәргәләп, трибунага күз салгалый иде.

Минтимер Шәрипович әүвәлге съездлар белән бәйле мәгълүм мөһим вакыйгаларны хәтергә алды. 1992 елда булган тәүге җыен Милли-мәдәни җәмгыятьләр ассоциациясе оештырылу белән тәмамланды. Соңыннан ул Татарстан халыклары ассамблеясе итеп үзгәртелде. Нәкъ 10 ел элек уздырылган икенче съезд Татарстан Республикасында милли сәясәтнең төп концепциясен кабул итте.

– Татарстаныбыз моделе, милли һәм дини өлкәне үстерү моделе Россиядә дә, халыкара дәрәҗәдә дә бик кирәкле булып чыкты, – дип белдерде Дәүләт Киңәшчесе һәм, сүзен дәвам итеп, съездларда кабул ителгән эчке һәм тышкы сәясәткә бәйле карарларның дөрес булуларын билгеләп үтте.

Күрше ложадагы ике хатынның пәрдә артында үзара сөйләшүен ишеттем, алар Россия белән Шартнамәне озайту турында Татарстанның беренче Президенты сүз әйтер микән дип гәпләштеләр. Минтимер Шәрипович бу мәсьәләне дә читтә калдырмады.

– 1994 елда РФ дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында гаять мөһим Шартнамә имзаланды. Икенче съезд узган елда икенче Шартнамәгә кул куелды, ул федераль үзәк белән республика арасындагы мөнәсәбәтләрне ул вакыттагы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы конституцияләре кысаларында рәсмиләштерде. Анда Татарстан өчен ниндидер салым өстенлекләре яки икътисадый-финанс

Фото: Дмитрий Резнов

* С вами мы можем!

“ Татарстаныбыз моделе, милли һәм дини өлкәне үстерү моделе Россиядә дә, халыкара дәрәҗәдә дә бик кирәкле булып чыкты.

преференцияләре каралмаган. Бүген исә, бу Шартнамәнең иҗади нигезен искә алганда – без моның нәтиҗәсен республиканың уңышлы үсешендә күрәбез – килешүнең яшәргә хокуклы булуын искәртү урынлы. Илебезнең федератив нигезен ныгытуга ярдәм иткән конституция нормасы буларак, ул эчтәлегенә һичбер үзгәртүләр кертмичә озайтыла ала, – дип белдерде Минтимер Шәймиев.

– Менә күрдеңме, әйттем бит мин сиңа! – дип пышылдады беренчесе, сүзе хак чыгуына шатлык катыш дулкынлану хисе кичереп.

– Тик резолюция проектында юк бит ул! – дип үзенекен тәкрарлавын дәвам итте икенчесе.

Алда утырган әбекәй бу әңгәмәне ишетте булса кирәк. Саквояжын ачып, съезд алдыннан таратылган материалларны алды да, резолюция проектын җентекләп укый башлады.

Дәүләт Киңәшчесе чыгышын күптән инде республиканың визит карточкасына әйләнгән гыйбарә белән тәгәлләде:

– Уңышлар, иминлек, саулык, муллык сезгә! Без сезнең белән булдырабыз!

РФ Президенты Администрациясе җитәкчесе урынбасары, РФ Президенты каршындагы Милләтара мөнәсәбәтләр советының җаваплы сәркатибе Магометсалам Магомедов милли һәм дини өлкәдәге нәтиҗәле хезмәт тәҗрибәсенең, аерым алганда, Татарстан тәҗрибәсенең ни өчен бик зур әһәмияткә ия икәнен искә алды.

– 193 милләт вәкиле тормыш иткән илебез өчен гражданнар һәм милләтләр арасында татулык дәүләт буларак яшәүнең иң төп шартларыннан берсе, – дип ассызыклады ул. – Татарстан бик күп мәсьәләләрдә Россиянең башка субъектларыннан алда бара, барлык Россия Федерациясе өчен үрнәк булып тора. Монда милләтара мөнәсәбәтләрне күзәтеп торуның төбәк системасы булдырылган һәм эшләп килә, Халыклар дуслыгы йортларын оештыру һәм эшләтү комплекслы ысул белән алып барыла, гражданлык җәмгыяте институтлары белән уңышлы хезмәттәшлек ныгый. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов милләтара мөнәсәбәтләр торышына бик игътибар бирә. Моның өчен бик зур рәхмәт.

Президиумның уртасында утырган Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ягына караган делегатлар алкышларны кызганмады.

Чираттагы чыгыш залны сагаеп, тынып калырга мәҗбүр итте. РФ Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары Владимир Васильев экстремистлар кулында диннең никадәр куркыныч коралга әйләнергә мөмкинлеге турында тыныч тавыш белән, ләкин төпле, үтемле итеп сөйләде. Катлаулы 1990нчы елларда республиканың милли низаглар ялкынын вакытында сүндерә алганы өчен, спикер Татарстан җитәкчелегенә һәм съезд делегатларына рәхмәтен җиткерде.

Чираттагы чыгыш ясаучыны тәкъдим иткәндә, Фәрит Мөхәммәтшин аның «Минем татар халкым» исемле китабын телгә алуга, дәррәү алкышлар яңгырады. Дагыстан Республикасы башлыгы Рамазан Абдулатыйповка аталган алкышлар залның бер ягында тынып өлгермәде, башка тарафында янә башланды. Делегатларның хуплау, көлү тавышлары, кул чабулары Рамазан Абдулатыйповның бар чыгышы дәвамында ишетелеп торды. Кыскасы, аны туган ягындагы кебек хөрмәтләп каршы алдылар.

Ул арада исә Рамазан Гаджиморатович тарихка күз салды:

– Ун ел элек Татарстан халыклары ассамблеясе ачылуга махсус килгән идем. Ул вакытта сезгә өметләребез зурдан иде, ә сез аларны да уздырып җибәрдегез. Сез әйткәнне эшли, хакыйкать, дуслык, туганлык юлыннан бара торган намуслы кешеләр икәнлегегезне исбатладыгыз. Шуның бәрабәренә республикагызны, Ватаныгызны тәэсисез.... Татарлар – бөек халык, әлбәттә, тарихи яктан бөек халык, аларның биләмәләре Кытай чикләрен-





нән Европага кадәр сузылган булган. Татар халкының иң бөек уңышларыннан берсе һәм язмышы – аларның руслар, Россия белән берләшүе, хәзерге заман шартларында Россия Федерациясе составында үзләренә лаеклы урын табуы. Һәм мин Казанда шуны әйтми булдыра алмыйм: татарлар башка һәр милләткә караганда да Россияне ныграк бизи, алар – ил күрке, бу чыннан да шулай, – дип белдерде Дагыстан башлыгы, янә алкышлар диңгезен уятып, дулкынын кузгатып.

Трибунага Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов чыкты. Республиканың соңгы 25 ел эчендә нинди карарлар кабул итүен, шул исәптән милләтара мөнәсәбәтләрне үстерү юнәлешендә нинди гамәлләр кылуын һәм аларның нинди мөһим нәтиҗәләргә китерү хакында бик төгәл, анык сөйләде ул.

– Милли-мәдәни үсешне тиешле югарылыкта тәэмин итү, социаль программаларны тормышка ашыру нәтиҗәле икътисад нигезендә генә мөмкин, – дип басым ясады Рөстәм Миңнеханов. – Советлар Союзыннан соңгы чорда Татарстан сайлаган үсеш моделе иң уңышлылардан берсе булды. Бүген республика ирешкәннәрнең барысы да – бик күп төрле милләт вәкилләренең, аларның берничә буынының тырыш хезмәт нәтиҗәсе. Бу эшләрнең әһәмиятен аңлап һәм аларда катнашып, туган республикабыз һәм уртак Ватаныбыз чәчәк атсын дип кылган хезмәтегез өчен Сезгә ихлас рәхмәтемне белдерергә телим, – диде Президент алкышлар яңгыры астында.

– Татарстан һәм Россия Федерациясендәге социаль-икътисадый процессларның кисешү нокталары бихисап, – дип ассызыклады Рөстәм Миңнеханов.

– Республиканың төрле тармактагы уңышлары да уртак Ватаныбызның уңышлары һәм аның халыкара мәйдандагы абруе күтәрелү белән бик нык бәйләнгән. Татарстан өчен Россиянең көчле булуы мөһим, бу – уңышлы үсешебезнең бер нигезе. Нәкъ шул рәвешле Татарстанның куәтле булуы Федерация мәнфәгатьләренә туры килә.

Съезд делегатлары исеменнән ул, экстремизм һәм терроризмга каршы торуның барлык дәүләт структуралары һәм иҗтимагый институтларның уртак бурычы икәнен билгеләп, дәүләтнең куәтлелеген ныгыту, экстремизм һәм терроризм очраклары белән көрәшкәндә милләтара һәм динара татулык һәм иминлекне саклау, халыкара аренада Россиянең милли мәнфәгатьләрен яклау юнәлешендә Россия Федерациясе Президенты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган курска тəләктәшлеген белдерде.

Съезд резолюциясенә Татарстан белән Россия Федерациясе арасында гамәлдә булган Шартнамәне озайту турында маддә өстәү тәкъдиме Татарстан Республикасының халык шагыйре Зиннур Мансуров тарафыннан да телгә алынды.

– Без Татарстанда халыкның шулкадәр оешканлыгына һәм Россия Федерациясен үстерү өчен бөтен ил белән чишелергә тиешле киң күләмле мәсьәләләрне чишәргә әзер икәнлегенә тагын бер тапкыр инандык, – диде соңыннан Фәрит Мөхәммәтшин, съездга нәтиҗә ясаганда.

Съездның ахыргы резолюциясе берничә көннән соң расланды. Аның соңгы абзацларында делегатлар Россия Федерациясе Президенты Владимир Путинга Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасын саклап калу тәкъдиме белән мөрәҗәгать итте. Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында Шартнамәнең вакыты чыгу белән бәйле рәвештә, федераль үзәк белән Татарстан арасындагы вәкаләтләрне бүлешүгә кагылышлы мәсьәләләрне җайга салу формаларын хәзерләүне федераль хакимият һәм республика органнарына йөкләү тәкъдиме дә резолюциядә урын алды.

ТӨРЛЕ КЫЙТГАЛАР АРАСЫНДА

Съезд көнендә «Корстон» фойесы иртәдән үк илаһи рәссамның очкыннар чәчеп торган якты, матур, җылы милли палитра пәйда булырлык итеп төрле төсләргә буялган картинасын хәтерләтә иде.

Күзгә янында кем чәчен төзәткәли дисәм... чын Шәрык принцессасы. Купшы кызыл күлмәк, төз буй-сын, биек итеп ясалган, кечкенә таҗ (соңыннан аның «чоктури» дип аталуы беленде. – Ред. искәрмәсе) белән бизәлгән чәчләр... Әйләнә-тирәмдә аллы-гөлле милли киемнәр кигән дистәләгән кешене күрәм. Һәм монда нинди дә бернинди ясалмалылык та юк. Чын, ихлас елмаюлы йөзләр, үз гореф-гадәтләре өчен чын горурлык, күтеп алынган бу бәйрәмнең ун елдан соң кабат узуына ихлас шатлану...

Мин төрле телләрдә сөйләшкән кешеләр төркеме арасыннан үтәм, әйтерсең лә ачык буяуларга күмелгән төрле дөньяларны аралап узам. Шул вакытта исә Татарстан авыл-калаларының әлеге күптөрлелекне шулай табигый, бер-берсенә ярашлы рәвештә үзенә сыендыруына һәм саклавына шаккатам. Бәйрәмчә киенгән делегатлар арасында журналыбызда дөнья күргән мәкаләләрнең геройларын да күреп гаҗәпләнәм, бу исә күңелгә җылылык һәм куаныч өсти.

Гадәти эшлекле костюмнан киенгәнгәдер, мөгаен, сүз катарга кыюлыгым җиткән беренче кеше Ван Юн әфәнде булды:

– Мин тумышым белән Үзәк Кытайдан. Күпмедер вакыт Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, Сургутта яшәп алдым. Тик барыбер Казанны сайладым. Ни өченме? Без охшаган бит, – дип елмая Ван Юн. Ул яктылык диодлары нигезендә яктырту җиһазлары җитештерү белән бәйле бизнесы турында сөйләп китте. Монда, съездда, ул яңа танышлар, кызыклы әңгәмәдәшләр табарга ниятли.

Татар милли киеме – көмеш җепләр белән чигелгән яшел бәрхет жилет кигән кара чәчле ханым янына килäм. Балык Бистәсе районының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы вәкиле Фирдания Әхмәтҗанова булып чыкты ул.

– Без үз районыбызда татар милли гореф-гадәтләрен популярлаштыру белән шөгыльләнәбез. Хәзер Бишек туе бәйрәмен әзерлибез. Гадәттә аны бала туу уңаеннан уздыралар. Бу бәйрәм белән бәйле йолалар – исем кушу, бишек җырлары, җырулар, уеннар тамырлары белән ерак тарихларга тоташа. Шунысы да гаҗәп: яшьләр бүген милли йолалар, гореф-гадәтләр белән кызыксына. Әйтик, югары сыйныфларда укучы кызлар арасында калфак тегү буенча осталык дәресләре бик популяр булды. Бу бездә эшкә дәрт уятып җибәрде, – дип хис-тойгылары белән уртаклашты Фирдания апа.

Фото: Дмитрий Резнов

PRESSA.RU

Кунакларның зур булмаган сәхнәгә, ярга иңгән дулкыннар кебек, бер-бер артлы менеп төшүен бергәләп күзәтәбез. Делегацияләр съезд логотибы төшерелгән баннер һәм арка янында фотога төшә.

Менделеевск Халыклар дуслыгы йорты стендындагы купшы муенсага күзем төшә. Казанда удмурт җәмгыятен җитәкләгән Павел Александров аңлатма биреп үтте:

– Бу – Кукмарада яшәүче удмурт Әхмәтовлар гаиләсенең гаилә ядкәре. Әлеге кадерле истәлекне съездга алып барырга рөхсәт иттеләр. Ә менә монысы, – Павел кызыл скрипканы күрсәтә, – Баулыдагы удмурт гаиләсе раритеты. Шул рәвешле без Татарстанның төрле почмакларында яшәп яткан удмуртларның үз гореф-гадәтләрен онытмавын һәм хөрмәт итүен күрсәтергә телибез. Кардәшләрең белән күрешү рәхәт. Республикабыз зур бит, без, удмурт җәмгыятьләре җитәкчеләре, әллә ни еш очраша алмыйбыз.

Яңарак килүчеләр бер-берсен бәйрәм белән котлый. Кунаклардагы дәрт, энергия ташып чыга, аеруча оркестр уйнаган почмакта. Милли көйләрнең заманча аранжировкадагы искиткеч пассажлары чын-чынлап тыпырдап биеп алырга чакыра. Һәм менә ике татар әбисе, сумкаларын читкә атып, җилкенчәк кызлардай көлешә-көлешә, бөтерелеп биеп тә китә. Күз ачып йомганчы, аларга яшьрәк делегатлар да кушыла.

Аклы-кызыллы чуваш күлмәге кигән ханым да янымда бию көенә тыпырдый. Аның кайсы җәмгыятьтән, кайсы төбәктән килүе турында сорашам.

– Мин монда үзем генә түгел, – дип рус һәм татар милли киемнәре кигән дус кызларын чакыра ул. Ирина Малышева исемле яңа әңгәмәдәшем Татарстанның Буа районы делегациясе белән таныштыра.

– Съездның шулай сирәк узуы кызганыч, ешрак күрешәсе, безнең шулай күп, шулай дус булуыбызны ешрак тоемлыйсы килә, – ди ул. – Буа районында без барлык бәйрәмнәрне дә бергәләшеп билгеләп үтәбез. Руслар бездә татарча сөйләшә, ә татарлар чувашча белә. Аллага шөкер, без бүген менә шулай дус-тату яшибез.

Идәнгә кадәр җиткән озын кызыл күлмәкле, биек башлыклы яшь чибәркәй янына барам. Ул үзенең Цагана исемле булуын, Калмыкиянең Каспий диңгезе буендагы кечкенә бистәсендә тууын сөйләп китте. Казанда институтта бергә укыган калмык дусларын Цагана хәзер бик сирәк күрә икән, туган якларына да елга бер генә кайта.

– Туган телебездә әбием белән генә сөйләшәм. Аңа инде 90 яшь. Әнием белән әбием минем гореф-гадәтләрне күбрәк белү теләгән һәрчак хуплады. Өйдә, Калмыкиядә, мин биюләр белән шөгыльләндем һәм шушы костюмны тектем. Казанга киткәндә, әнием, үзең белән алып кит, кирәге чыгар, диде. Чыннан да, менә кирәге чыкты, – дип елмая Цагана.

Алтын бизәк чигүле куе кызыл күлмәк кигән икенче кыз Татарстан халыклары Яшьләр ассамблеясе әзерләгән стендлар белән таныштыра.

– Әти-әнием Әрмәнстанның төрле почмакларында яшәгән, хәтта Азәрбайҗандагы Кировабад каласында да тормыш итәргә өлгергән, тик шулай да монда, Казанда, танышкан. Ул чакта әтием Казанның Халыклар дуслыгы йортын җитәкләгән, ә әнием грузин телен өйрәнергә дип шунда килгән булган. Әтием исә канәгатьсезлеген белдергән, янәсе, башта әрмән телен өйрәнсән әле! Менә шулай танышып та киткәннәр, – дип сөйли Анаит Хачатурян. – Мин әрмән мәдәниятен һәм шуның белән бәйле һәрнәрсәне яратам. Әрмәнстанга ел саен барам, аны үз Ватаным дип саныйм. Өйдә туган телдә сөйләшәбез. Яшьләр үз мәдәниятен өйрәнергә һәм сакларга атлыгып тормый, дип уйлый күпләр, тик Яшьләр ассамблеясендә бу сүз белән килешмиләр. Мәдәниятләребезне саклап калу өчен, барлык чараларда катнашырга, хәлебездән килгәннең барысын да эшләргә тырышабыз.

Архалыг* кигән мәһабәт ир-ат янына киләм. Фикрәт Бакиров Әлмәттә тормыш итүче азәрбайҗаннар милли-мәдәни мохтариятеннән вәкил итеп җибәрелгән.

– Без – 160 лап кеше. Һәрдаим аралашып-күрешеп торабыз, бәйрәм-кичәләр уздырабыз. Әлмәттәге Халыклар дуслыгы йортында безнең якшәмбе мәктәбе дә эшли, анда балаларыбыз туган телне өйрәнә. Хәзер ел саен уздыра торган хәйрия чарасына әзерләнәбез: районыбызның ветераннары яшәгән картлар йортына юл тотачакбыз. Аларны бәйрәм белән котларга ниятебез, – дип сөйли Фикрәт Аждар улы.

Ахырда кызыл киемле принцесса янына килергә батырчылык иттем. Корейле ханым булып чыкты ул.

– Ирем Чаллы шәһәренең корея халкы автономиясен җитәкли. Анда 500 чамасы кеше бар. Бездә Көньяк Корейдән делегатлар еш кунак була. Менә шуннан миңа бу күлмәкне һәм «чоктури» дип аталган баш киемен алып килделәр. Миңа бик-бик ошый ул. Чоктури миндә ниндидер генетик хәтерне уята төсле, хәтта минем әти-әниләрем дә гомер буе Россия территориясендә яшәгән югыйсә. Гаиләбез Чаллыга «КАМАЗ» төзелгән вакытта күчеп килгән, без ирем белән монда таныштык, – дип сөйли Наталья Ким. – Кызыбыз якшәмбе мәктәбенә бик теләп йөри, тел өйрәнә. Без милли бәйрәмнәребезне онытмыйбыз, һәрчак билгеләп үтәбез. Алар җете төсләргә бай, эчтәлекле. Күптән түгел төрле милләт, төрле мәдәният вәкилләре катнашындагы бер чарада без буяулар турында бер риваять тәкъдим иттек. Анда бер тартмага салынган буяулар ызгыша. «Мин иң яхшысы, иң шәбе», – ди кызылы. «Юк, мин!» – дип каршы төшә сарысы. «Нәрсә беләсез соң сез, һәрнәрсәнең асылында – мин!» – ди ак буяу. Рәссам килә дә, барлык буяуларны катыштырып, картина ясый. Әлеге риваять бик гади дә, бер үк вакытта бик мәгънәле дә: без барыбыз да бик төрле, тик нәкъ шуңа күрә әйләнә-тирә дөньябыз да төсләргә шундый бай, шундый якты, шундый матур.

* Архалыг – кафтан, Азәрбайҗанда милли ир-ат киеме.

PRESSA.RU

Фото Европа Советының Жирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессы сайтыннан

Фото: Андрей Данилов

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН: «РОССИЯДӘГЕ ТӘҖРИБӘБЕЗ ЕВРОПАГА КИРӘК»

Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Европа Советының Җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессының медаленә лаек булды. Бүләкләү тантанасы март ахырында Страсбургта, Европа Советының төп бинасындагы атаклы ярымтүгәрәк залда узды. Фәрит Мөхәммәтшингә Конгрессның Шәрәфле әгъзасы дигән мактаулы исем дә бирелде. Аның бай тәҗрибәсе Европа Советы эшендә киләчәктә дә кирәк булачак әле – «Татарстан» журналындагы әңгәмәбез әнә шул хакта.

– Фәрит Хәйруллович, соңгы елларда Россиянең Европа Советы белән хезмәттәшлеге матур, шома гына барды дип әйтү хаклыкка хилафлык булыр. Илебез хәтта ПАСЕда – Европа Советының Парламент Ассамблеясендәге әгъзалыгын да вакытлыча туктатып торды. Шушы вакыйгалар фонында Россия делегациясенең Җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессында уңышлы эшләп калуын ничек бәяләргә? Килешә, уртак фикергә килә белүнең тантана итүеме?

– Беләсезме, мәсьәлә бүгенге күзлектән караганда гына гади булып күренә, ләкин чынлыкта алай түгел. Конгрессның чираттагы сессиясендә Кырым референдумы нәтиҗәләрен игълан иткәч, Европадагы партнёрларыбыз ягыннан шактый җитди басым тойдык. Конгресс Бюросының Россия Федерациясендә күчмә утырышлар уздыруны тыю турында карарын аеруча авыр кичердек. Бу карар «иске демократия» дип аталган аерым бер вәкилләр тырышлыгы белән туды. Сүз уңаеннан, ул устав процедураларын бозып башкарылды. Моны никадәр авыр кабул иткәнлегебезне күз алдына китереп карагыз. Ул вакытта инде Актуаль мәсьәләләр буенча комитет һәм Мониторинг буенча комитет утырышларының Казанда һәм Ульяновскида узачагы планлаштырылган, оештыру эшләре башкарылган, аларның әчтәлеге бик нигезле итеп әзерләнгән иде!.. Кызганыч...

– ПАСЕдагы вәкилләребез кебек, ишекне шапылдатып ябып чыгып китү теләге тумадымы?

– Европа Советының төрле ике органын бер-берсе белән чагыштырудан тыелыйк әле. 47 дәүләтнең парламент депутатларыннан гыйбарәт Парламент Ассамблеясе, гадәттәгечә, Европа Советының иң сәясиләштерелгән органы булып кала бирә. Россия Федерациясе вәкилләре икеле стандартларның, Европа халыклары гаиләсендәге мөнәсәбәтләр һәркемгә дә бер төрле түгеллекнең нәкъ менә шул форматта үз башыннан тулысы белән кичерде. Ул чакта ПАСЕда хөкем сөргән атмосфера, Россия делегациясенә карата берьяклы карарлар, мөгаен, эшне дәвам итү мөмкинлеген, мәгънәсен калдырмагандыр.

Россия делегациясе составында мин хезмәт куйган Җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессы исә гомумевропа сәясәтенең төбәк һәм муниципаль югарылыктагы карашларын чагылдыра. Асылда, иҗтимагый тормышыбызның иң мөһим мәсьәләләре буенча ачыктан-ачык һәм турыдан-туры бәхәс мәйданы оештырган тиңдәшсез парламент институты ул, чөнки нәкъ менә төбәк һәм җирле хакимиятләр дәүләтләребездә гомер кичергән халык белән иң якын, иң туры элемтәдә тора. Сез ничек уйлыйсыз, бәхәсләшү генә түгел, әңгәмәдәшләреңне ышандырырга, үгетләргә мөмкинлек бирә торган урыннан үзебезне мәхрүм итү акыллы гамәл булыр идеме?

Менә шуңа күрә дә, искиткеч басым тоюга карамастан, Россия делегациясе Конгресста эшен дәвам итте. Хәзер инде серне ачарга да була: делегациябезнең Җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессы составыннан чыгу мәсьәләсе 2014 елның мартында Страсбургка юлга кузгалыр мизгелгә кадәр ачык торды.

– Сезнең фикер нинди: Конгресстагы Россия Федерациясе вәкилләре шушы ике елдан артык вакыт эчендә хезмәттәшләренә үз фикер-карашларын, килеп туган хәлгә карата үз позицияләрен тиешенчә җиткерә, аңлата алдымы?

– Иң мөһиме, 2016 ел башына Россиягә карата мөнәсәбәтләрдә «киеренкелек градусы» акрынлап кими башлады. Страсбургтагы Европа сараенда алып барган җентекле хезмәтебезнең дә нәтиҗәсен күрәм мин монда. Һәм бу – соңгы ике елдан артык вакыт эчендә башкарылган эш кенә түгел. Мин Россия төбәкләре һәм муниципалитетлары вәкилләре делегациясе составына беренче тапкыр инде 2001 елда ук кергән идем, димәк, чагыштырып, фикер йөртеп карар нәрсәм бар. Беренче елларда һәр утырышта диярлек «чын демократия», толерантлык, һәркемгә ачык мультикультурализм турында, төпчек балага аңлаткандай, үгет-нәсихәтләр тыңлап утыруыбызны хәтерлим әле. Әйтерсең, безне алдынгы Европа җәмгыятеннән әллә ничә гасыр артта калганлыгыбызга ышандырырга тырыштылар.

Унбиш елдан соң безнең хәтта иң үзсүзле партнёрларыбыз да, ниһаять, Россиядә демократиянең барлыгын, һәм аның нигезе моннан

инде күп гасырлар элек салынганлыгын төшенде. Әйе, Европа демократиясенең бөтен хасиятләренә ия түгелбез, ләкин безнең бу өлкәдәге тәҗрибәбез «уртак йорт»ны, бердәм Европаны ныклы итеп төзү өчен, әнә шул Европаның үзенә дә бик кирәк.

– 2012 елда сез Конгрессның актуаль мәсьәләләр буенча комитетының рәисе итеп сайланып, тарихка комитет җитәкләгән иң беренче россияле булып кердегез...

– Моны Европа җәмгыятендә Россия Федерациянең абруен күтәрү һәм ныгыту юнәлешендә барлык делегациябез белән күп еллар дәвамында, төрле яклы алып барылган уртак хезмәтебезне бәяләү дип саныйм. Безгә инде хәзер төпчек бала итеп кимсетеп карамыйлар. 2016 елда исә без, Россия делегациясе әгъзалары, Европадагы партнёрларыбызга урыннарда халык хакимиятен ныгыту, дәүләтчелектә федератив башлангычны үстерү, күп милләтле һәм төрле динле җәмгыять төзү тәҗрибәбез турында сөйләдек. Һәм бу җәмгыятьнең нигезендә «толерантлык» һәм «мультикультурализм» кебек матур сүзләр, буш төшенчәләр түгел, ә халыкларның, диннәрнең, цивилизацияләрнең күп гасырлар дәвамында бер-берсе белән йөрешеп-керешеп яшәве ята.

Нәкъ менә шундый, күп милләтле Россия дәүләтенең гадәт-йолаларын, ата-бабалар мирасын хөрмәт итүгә корылган караш илебез вәкилләренең теләсә кайсы халыкара мәйдандагы төп эш нигезе булырга тиеш.

– Март ахырында Страсбургтагы Европа Сараенда Европа Советының Җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессы рәисе Гудрун Мослер-Тернстрем сезгә Конгрессның медален тапшырды. Конгресс үсешенә керткән зур өлешегез өчен, сез аның шәрәфле әгъзасына әверелдегез...

– Ихлас әйткәндә, трибунага катлаулы хис-кичерешләр белән чыктым. Россия делегациясе составында унбиш ел хезмәт куйдым, ике срок рәттән Конгрессның актуаль мәсьәләләр буенча комитетын җитәкләдем. Конгресста эшләү дәверендә күпме кеше белән дуслаштым. Шушы бүләкне озак еллар иңгә-иң куеп бергә эшләгән кеше кулыннан алуы аеруча рәхәт булды. Әлеге медальне Россия төбәкләре һәм муниципалитетлары делегациясендәге һәр вәкилнең Европа Советына керткән дәүләтләр белән ачыктан-ачык аңлашу булдыруга керткән өлешен тану дип кабул итәм.

Европа Советы мәйданындагы берничә баскычлы парламентаризм системасында сайлап куелган вәкилләрнең катнашуы, актуаль мәсьәләләр буенча сәяси тәкъдимнәрне алга этәрү мөмкинлеге хәзерге дөньяда парламентаризм институтының әһәмияте артуга булыша.

– Фәрит Хәйруллович, Европа Советында эшләгән дәвердә сезгә, мөгаен, йөзләгән сәясәтче белән аралашырга туры килгәндер. Россияне дошман күрүдән кайчан туктарлар икән, бу мәсьәләдә фаразыгыз ничегрәк?

– Россиядә дә, чит илләрдә дә бер төркем политологлар «Россия агрессиясе» каршында курку сеңдерә торган милитаристлык риторикасыннан җәмгыятьнең котылырга теләвен телгә ала. Бу илләрнең гражданнары, шул исәптән санкцияләр кампаниясенең бер нәтиҗәсе буларак, үзләрендәге социаль-икътисадый халәтнең чын-чынлап начараюын тоя. Эш урыннары кыскару дисеңме, үз продукцияләренә Россия кулланучылары тарафыннан сорау кимү дисеңме... Ә бу – йөзләрчә миллиард евро югалту дигән сүз бит...

Икенче яктан, дөнья бит ул куласа, бер әйләнә, бер баса. Менә Көнбатыш сәясәтчеләре үз хаталарыннан сабак алса иде... Мин 2011 елның мартын искә алам. Ул чакта Европадагы партнёрларыбыз Төньяк Африкадагы «гарәп язы» дигән күтәрелешне шундый җанланып каршы алды, хәтта Ливия һәм Тунистагы җирле үзидарәгә булышлык программасын да кабул итте, теләктәш әгъзалар сыйфатында безнең утырышларга да чакырырга планлаштырды... Биш елдан соң исә бу илләрнең миллионлаган кешесе, хакимияткә килгән кланнарның туктаусыз сугышларыннан котылыр почмак эзләп, Европага юл тотты. Былтыр гына да Европага миллионлаган качак килде. Һәм шулкадәр күләмле миграциянең иң тәүге нәтиҗәләрен нәкъ менә муниципаль хакимиятләр татыды, шуның белән бәйле рәвештә без әле 2016 елның март аенда узган сессиядә дә берничә көн дәвамында фикер алыштык...

– Сер булмаса, әйтегез әле, Европа Советының Җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессы рәисенә нинди сувенир алып барган идегез?

– Сер түгел. Татар халкы тарихындагы мәгълүм шәхес – Сөембикә ханбикә сурәте төшерелгән панно. Күп гасырлар буена ул риваятьләребездә якты киләчәккә өмет һәм ышаныч, халкыбызның рухи көчен, милли үзенчәлеген чагылдырган символга әйләнде. Әлеге панно «Бердәмлек – төрлелектә» дип исемләнгән галереяда лаеклы урын табар, дип уйлыйм. Европа Советы да 70 еллык тарихында «бердәмлек – төрлелектә» принцибына таянып, шуны алга сөреп эш итә бит. T

Әңгәмәдәш – Сафа Гәрәев.

Фото Европа Советының Җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессы сайтыннан

“ – 2016 елда без Европадагы партнёрларыбызга урыннарда халык хакимиятен ныгыту, дәүләтчелектә федератив башлангычны үстерү, күпмилләтле һәм төрле динле җәмгыять төзү тәҗрибәбез турында сөйләдек.

PRESSA.RU

БЕЗНЕҢ ТӨП ТЕЛӘК-ХЫЯЛЛАРЫБЫЗ ШУЛ УК КАЛА БИРӘ: **БӘХЕТЛЕ ЯШӘҮ ҺӘМ ДӘВАМЫБЫЗНЫ БАЛАЛАРЫБЫЗДА КҮРҮ**

Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Дәүләт Советы спикеры, – үткәннәрнең кадерен белүнең, көнләшүдән өстен булу һәм ачу сакламауның мөһимлеге турында.

– Мин кечкенә вакытта безнең Рус Акташы авылында армиядән кайткан майор пәйда булды. Без бала-чага аның артыннан көтүебез белән ияреп йөрдек. Ул шундый төз, матур иде, һәм безгә бик бәхетле, җитешле һәм булдыклы кеше булып күренде. Безнең барыбызның да аңа охшыйсы килде. **Шуңа инде мин балачактан ук космонавт та, бигрәк тә депутат булырга хыялланган малай түгел идем… Әмма язмыш үзенчә хәл кылды.**

Хәзерге югары технологияләр заманында приемга язылу һәм әллә ничә чакрым ераклыкка «дөреслек эзләргә» йөрү мәҗбүри түгел. Республиканың теләсә кайсы министрлыгы, Дәүләт Советы сайтына кереп, мөрәҗәгатеңне юлларга мөмкин. Ул җавапсыз калмый. **Мин үзем көн саен шәхси сайтымны, «Твиттер»дагы сәхифәмне карап барам, аралашам,үзем турында күп яңа нәрсә белəм, алар һәрвакытта да уңай булмаска мөмкин.** Ләкин бу тормыш, дөреслекне эш автомобиле тәрәзәсеннән белгәнгә караганда, болай ишетү яхшырак.

Балачагым сугыштан соңгы авыр елларга туры килде. Әле дә хәтерлим, иртүк торасым килми, әмма үземне җиңеп, аякка басам һәм коедан су ташыйм, әти кушканны көтмичә, утын ярам, ишегалдын себерәм… Дөрес, иркә-куркак та булмадым: малайлар белән дәрестән балык тотарга дип кача идек; әти-әнидән яшереп тәмәке дә тарткаладым.

«Хаким, көчкә түгел, гаделлеккә таянып идарә итә» – Конфуцийның әлеге вәгазе миңа бик якын һәм таныш. **Безнең һәрберебез нинди генә вазыйфаларга, нинди генә регалияләргә ия булсак та, Кеше булып калырга тиешбез.** Әхлакый иммунитет булдырырга һәм аны җуймаска кирәк. Ә сәяси лидер, миңа калса, кешеләрне дошманлык һәм ызгыш-низаглардан – татулыкка, татулыктан – үзара аңлашуга, аңлашудан – ышанычка, ышанычтан үзара ихтирамга алып килергә тиеш…

Әтием чын коммунист иде, гомере буена Алла юк, дип сөйләде. Ә инде гомер көзе якынлашканда, мин Ходайдан синең өчен сорыйм, диде. **Мин мәчеткә намазга йөрмим, әмма дөньяви эшем буенча чиркәүләргә дә, мәчетләргә дә керәм.** Өемдә Коръән дә, Библия дә бар. Аларны укып чыктым – танышу, үземне үстерү өчен.

Галстук – минем өчен ияләшелгән кием детале, аңардан башка үземне уңайсыз хис итәм, кул үзеннән-үзе галстукны рәтләргә сузыла. Тормышымның бик зур өлеше галстук таккан килеш узды, инде ничәнче елдан бирле галстук тага башлаганымны хәтерләмим дә. Мөгаен, 1970 нче еллардандыр, Әлмәт шәһәр комитетында эшли башлаганнан бирле… Шуңа да минем галстук таккан халәтем – иң чыны.

Минем тормыш принциплары – чыдам һәм сабыр булу, – үткәннәрнең, ышанычлы дусларым һәм коллегаларымның кадерен белү. Көнләшүдән өстен булу һәм ачу сакламау.

Минем өчен иң шатлыклы һәм әһәмиятле вакыйгалар арасында – улым һәм кызымның туган көннәре. Бу, минемчә, аңлашыла да: гел үзгәреп торган дөньяда нәрсә генә булмасын, безнең төп теләк-хыялларыбыз шул ук кала бирә – бәхетле яшәү һәм дәвамыбызны балаларда күрү.

Минем өчен аеруча әһәмиятле вакыйгалар бар, алар минем һөнәри эшчәнлегемә бәйле булудан бигрәк, республикама һәм туган халкыма мәхәббәт белән аңлатыла. Бу, иң беренче чиратта, Татарстан Республикасы көне һәм ТР Конституциясе көне. Татарстан җәмгыятенең тамырдан үзгәртеп корылуларга юнәлгән юлының никадәр сикәлтәле булуы миңа бик яхшы билгеле… Бу еллар эчендә күпме кичердек? Боларның кадерен белми булдыра алмыйм.

Дәүләт урыннарында да, сәясәттә дә хатын-кызларның азчылыкта булуы кызганыч. Алар белән ышанычлырак һәм тынычрак, аларның кызгана, кискен сорауларны йомшарта һәм уртак тел таба белү сәләтләренә сокланып карарга була бит.

Әнинең безгә, үзенең өч баласына, әйткән сүзләре әле бүген дә истә: **«Әтиегезне оялтырлык гамәлләр кылмагыз!»** Мин әлеге принципларга таянып тәрбияләндем һәм бүген дә шул кагыйдә буенча яшим.

Сәясәтчеләргә «образ ясаучы» һөнәри имиджмейкерларны кабул итә алмыйм. Имиджмейкер сине кемнеңдер зәвыгы буенча үзгәртә булып чыга. Син булдыра алган кадәр күбрәк кешегә ошарга тиешсең. Ләкин син, бәлки, бөтенләй башкадыр?.. **Минемчә, халык сине чынлыкта нинди булсаң, шундый итеп күрергә тиеш – табигый, бизәлмәгән, үзгәртелмәгән килеш.**

Волейбол яратам. Бу бик динамик, коллектив һәм корректлы спорт уены. Шуңа күрә кайда гына эшләсәм дә, үземнең коллегаларымны әлеге уенга тартырга тырышам. Менә хәзер дә халык депутатлары һәм Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре белән, мөмкинлек чыкканда, волейбол уйныйбыз.

Гаилә өчен вакытым, кызганычка каршы, җитеп бетми. Алай гына да түгел, кайчак хәтта форс-мажор хәлләр аркасында алдан ук планлаштырылган гаилә чараларын туктатып торырга туры килә… **Ләкин гаиләмдәгеләрнең мине аңлаулары һәм минем һәрвакыт эштә булуым белән килешүләре өчен рәхмәтлемен.**

Малай чактан итеккә кидертелгән тимераякларда ишегалдындагы боз шугалакта рәхәтләнеп хоккей уйнап үстек. **Профессиональ хоккейчы булып китмәсәм дә, язмыш җилләре мине хоккейдан ерак җибәр-**

мәде: Әлмәттә 10 елдан артык Хоккей федерациясен җитәкләдем, «Ак Барс» хоккей клубы президенты булдым. Без ул чакта Россия чемпионатында бронза, көмеш медальләр яуладык, чемпионнар булдык.

Минем күптәнге мавыгуым – автомобиль. Машина йөртү таныклыгын унтугыз яшемдә алдым, шуңа әлеге хоббиемнең стажы шактый дип әйтә алам. **Яраткан егерме беренче «Волга»мны, беренче белемем буенча автомеханик буларак, рәхәтләнеп үзем тәртипкә китерәм, үз кулларым белән сүтеп-җыям!** Идеаль тәртиптә тотам. Берничә ел элек без хәтта республикада егерме беренче «Волга» һәвәскәрләре җәмгыятен оештырдык, ул «Клуб –21» дип атала.

Мине һәрвакыт Шәүкәт Биктимеровның үзенчәлекле, кабатланмас иҗаты сокландырды. Җырчыбыз Хәйдәр Бигичев турындагы хатирәләремне, аңа карата булган җылы, сокланулы мөнәсәбәтемне кадерләп саклыйм. Кино сәнгатенә килгәндә, Евгений Леоновны яратам. Аның геройлары, кагыйдә буларак, дөреслек, намус кушканча яшиләр… **Минем яраткан артистларым, күргәнегезчә, төрлеләр. Аларны бер нәрсә берләштерә: һәрберсе халык артисты дигән югары исем бирелгәнче күпкә алданрак халыкныкы булдылар.**

Ел саен дөньяда төрле халыкларның йөзләгән телләре югала бара. Әгәр глобальләшү шартларында алга таба шулай ук дәвам итсә, чуваш, мари, мордва һ.б. телләр юкка чыгачак… ахыр чиктә – рус теле дә. Халыкара аралашу теле буларак бары тик инглиз теле генә калачак… **Мондый глобальләшү процессында һәр халык үз туган телен саклап калуны кайгыртырга тиеш.**

Шәхси планга килгәндә, мин күп еллар элек үземнең ярымны сайладым, шуннан бирле Луизадан башка бернинди хатын-кыз да мине кызыксындырмый (көлә). Луиза мәгълүм фильмдагы кебек – үзе чибәр, үзе комсомолка, үзе активистка иде. Бик энергияле һәм, иң мөһиме, – яхшы гаиләдән.

Улым Дамир армиядә булмаса да, – чын ир, аның белән горурлана алам. Унынчыда укыганда ук шәһәр комсомол комитетына: «Әфганстанга хезмәт итәргә җибәрүегезне үтенәм», – дип гариза юллаган иде. Сыйныфташ кызларының әти-әниләре кичләрен урамга чыкканда: «Кем белән чыгасың? Дамир беләнме? Ну, ярар, алайса», – дип рөхсәт бирәләр иде. **Чыгарылыш кичәсендә улым «Әлмәт шәһәре 2нче мәктәбенең иң гадел укучысы» дигән титул алды…**

Балык тотарга бик яратам. Көймәгә утырып, Иделгә балыкка чыгу – минем өчен стресстан котылуның иң яхшы чарасы. Кышын балык тоту да кызык. Тагын әле бильярд уйнарга яратам. Бүген танылган сәясәтчеләрнең күбесеннән начар уйнамыйм. Бильярдта син көндәшең белән бергә-бер, күзгә-күз каласың, монда инде сиңа беркем дә булыша алмый, шунысы шәп!

Миннән спортчы чыкмады, әмма физик культура һәм сәламәт яшәү рәвеше эшемдә ярдәм итеп тора. Һәрвакыт тонуста, яхшы формада булу – хезмәт бурычларымның бер өлеше. **Бәлки, бу бик баналь яңгырар, әмма кайчак син үзеңә үзең хуҗа була алмыйсың. Проблеманы чишү хакимияттән катгый гамәлләр таләп иткәндә, баш авырта дип, котылып калу – мөмкин эш түгел.**

(Төрле еллардагы ММЧ буенча)



PRESSA.RU

«Иң мөһиме – кеше, аның тормышы һәм аңа ихтирам»

Тәлгат Абдуллин,
«Татарстан Республиксы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы башкарма директоры

Хөрмәтле Фәрит Хәйруллович!

Юбилеегыз белән ихлас тәбрикләвемне кабул итегез!

Сәясәтче буларак та, хакимиятнең һәрбер баскычында һәрвакыт республика мәнфәгатьләрен яклаучы буларак та Сезнең эшчәнлек, һичшиксез, иң күренекле һәм сәләтле шәхесләр белән бер рәттә тора. Дәүләтчелек төзелгән елларда, Югары Совет бәхәсләшә, үз фикереңне әйтергә мөмкинлек бирә торган мәйданга әйләнгәч, Сез кешене тыңлый һәм ишетә, төрле фикерләр уята һәм аңлый белүегез белән аерылып тордыгыз, һәм бу карарлар кабул итү өчен шартлар тудырырга ярдәм итте.

Сез үзара килешүгә, карарларны эшкәртү һәм кабул итүгә мөмкинлек бирә торган торган дәвамлы һәм ныклы эш алып бара беләсез. Премьер-министр постында чактагы тәҗрибәгез законнарны практик тормышка ашыру мәсьәләләрендә Сезне баетты, һәм бу алга таба Дәүләт Советында һәм республика Хөкүмәтендәге эшегездә тагын да нәтиҗәлерәк чагылыш тапты.

Сез кешеләрне идеологик фикер йөртү буенча берләштерә белү сәләте белән аерылып торасыз, ә ораторлык сәнгатенә ия булуыгыз, мөлаемлыгыгыз республиканы һәм аның закон чыгаручы органнарын республикабызда һәм аннан читтә, Россия Федерациясе һәм Европа дәрәҗәсендә төрле структураларда күрсәтә белергә ярдәм итә.

Сез, Фәрит Хәйруллович, үзара аңлашу, түземлелек һәм дуслык принципларына, ягъни кеше хокуклары критерийләренә нигезләнгән энергия генераторы, ә бит иң мөһиме – кеше, аның тормышы һәм аңа булган хөрмәт.

Сезгә тирән ихтирамымны белдереп, чын күңелдән нык сәламәтлек, эшегездә сабырлык һәм түземлек, республика бәхете хакына актив иҗади эшчәнлек, гаиләгезгә, туганнарыгызга һәм якыннарыгызга иминлек телим!

Җәмгыятькә һәм дәүләткә хезмәт итүнең ачык мисалы

Р. МИСТАХОВ,
«А.М. Горький ис. Яшел Үзән заводы» АҖ генераль директоры

М. ПОДГОРНОВ,
«А.М. Горький ис. Яшел Үзән заводы» АҖ профсоюз оешмасы рәисе

Хөрмәтле Фәрит Хәйруллович!

70 яшьлек юбилеегыз уңае белән «А.М.Горький исемендәге Яшел Үзән заводы» АҖнең меңнәрчә кешедән торган коллективы һәм үз исемемнән иң җылы, чын йөрәктән чыккан тәбрикләүләребезне һәм иң изге теләкләребезне кабул итегез!

Тормыш юлыгыз – җәмгыятькә һәм хөкүмәткә хезмәт итүнең ачык мисалы. Эшлекле һәм зирәк кеше, илебезнең патриоты буларак, абруегыз, актив гражданлык позициягез, эшкә тулысынча бирелгәнлегегез, лидерлык сыйфатыгыз һәм стратегик уйлау сәләтегез Сезгә Татарстан мәнфәгатьләрен иң югары дәрәҗәдә күрсәтергә һәм саклап калырга мөмкинлек бирә. Гаять бай тәҗрибәгез белән тәңгәл килә торган прогрессив эш ысулыгыз һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәислеге постында әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итүдә принципиальлек һәм эзлеклелек күрсәтүегез белән Сез югары абруй һәм хөрмәт казандыгыз.

Сезнең Татарстан үсешенә керткән бәяләп бетергесез өлешегез, аның икътисади мөмкинчелекләрен ныгыту һәм үстерү югары исемнәр һәм күпсанлы дәүләт бүләкләре белән расланган.

Бүген республикабыз үзенең куәтле промышленность мөмкинчелекләре белән горурлана – монда Сезнең хезмәтегез дә зур. Озак еллар дәвамында җаваплы хезмәттә булып, нинди генә постны биләсәгез дә, һәрвакыт Татарстанның сәнәгать предприятиеләренә актив ярдәм иттегез һәм итәсез. «А.М.Горький ис. Яшел Үзән заводы» АҖ коллективы исеменнән безнең предприятиегә күрсәткән игътибарыгыз һәм ярдәмегез өчен рәхмәт сүзләрен җиткерәсе килә. Бүгенге көнгә завод илебезнең судно төзелешендә югары рейтингка ия, без үз продукциябезне иң югары дәрәҗәдә күрсәтә алдык, һәм ул дөнья базарында танылуга иреште. Соңгы елларда җитештерү күләме сизелерлек артты. Моңа техник яктан кабат җиһазландыру һәм камилләштерү программасын тормышка ашыру шактый ярдәм итә. Предприятиебезнең җитештерү куәтләрен яңарту процессы 2011 елда башланды һәм бүгенгә кадәр дәвам итә. Җитештерүне күп елларга алдан планлаштырырга мөмкинлек бирүче казанышларыбыз Татарстан Республикасы җитәкчелегенең гаять зур ярдәменнән башка мөмкин булмас иде.

Бүгенге тантаналы көндә Сезгә иң мөһимен – ныклы сәламәтлек һәм озын гомер, түземлек һәм ихтыяр көче, Ватанга хезмәт итү кебек изге эштә куелган максатларга ирешү өчен бетмәс-төкәнмәс энергия, иминлек, бәхет һәм изгелекләр телим! Дусларыгызның һәм хезмәттәшләрегезнең, якыннарыгызның һәм туганнарыгызның рухи җылысы һәм ярдәме тормышыгызны тулыландырып торсын, һәрвакыт уңыш юлдаш булсын! Алга таба да куелган максатларыгызны тормышка ашырудан канәгатьлек хисе кичерү һәм Татарстанның күпмилләтле халкының рәхмәте энергиягезнең даими чыганагы булсын.

PRESSA.RU

Сезгә сайлаучылар да, депутатлар да ышана

Вәгыйз Минһаҗев,
«Россия авыл хуҗалыгы үзәге» ФДБУнең ТР буенча филиалы җитәкчесе

Хөрмәтле Фәрит Хәйруллович!

Сезне матур юбилеегыз – 70 яшьлегегез белән тәбрикләвебезгә ихлас шатбыз!

Сез, һичшиксез, Татарстанның күренекле парламент җитәкчеләре исәбенә керәсез, республика, Бөтенроссия һәм Европа масштабындагы зур сәяси кеше булып торасыз.

Республика Дәүләт Советы Рәисе булудан тыш, Сез «Татарстан – яңа гасыр» республика иҗтимагый оешмасы лидеры, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәге бүлегенең Сәяси советы секретаре, Татарстан халыклары Ассамблеясе Рәисе, Европа Җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессының Төбәкләр палатасының Мәдәният һәм мәгариф комитеты рәисе булып торасыз. Вазыйфаларыгызны санап чыгу гына да бик күп урынны алыр иде. Бу – спикер өчен гаять зур күләмдәге эш. Моннан тыш, сәясәт фәннәре докторы буларак, күпсанлы хезмәтләрегез дә бар. Сезнең тәүлеклек вакыт 24 сәгатьтән күбрәктер кебек тоела. Шунысы куанычлы: Фәрит Хәйруллович, казанышларыгыз югары хөкүмәт бүләкләре – Дуслык һәм Почёт, «Намуслылык һәм батырлык» орденнары, «Ел спикеры» номинациясендә «Россия милли Олимпы» премиясе белән билгеләп үтелгән.

Шулай да Сезнең төп хезмәтегез – бу, һичшиксез, чирек гасыр дәвамында диярлек ТР Дәүләт Советы Рәисе постында эшләү. Рәислеккә кыска гына тәнәфес ясап, республика Премьер-министры постын да биләп тордыгыз. Бу Татарстан өчен авыр, икътисадны тотрыклыландыру чоры иде. Шул еллар эчендә республиканың 10 мең тирәсе гаиләсе Президентның тузган торакны бетерү программасы буенча яңа фатирлар алуга иреште. Шулай ук республика торак пунктларын газлаштыру дәвам иттерелде.

ТР Дәүләт Советын кабат җитәкли башлагач, республика халкы, аларның ихтыяҗлары һәм таләпләре турында кайгыртуны үзегезнең төп эшегез итеп калдырдыгыз. Эшне ахырынача җиткерүче кеше буларак, хакимиятне халыкка мөмкин кадәр ныграк якынайту өчен бөтенесен дә эшләп, иң мөһим федератив принципны тулаем хуплап киләсез. Туктаусыз республика районнарына чыгасыз, шәһәр һәм авыл халкы белән йөзләрчә, меңнәрчә очрашулар үткәрәсез. Һәрвакытта да гади тел белән, акыл сатмый гына әңгәмәдәшегезгә белгәннәрегезне аңлатасыз, Татарстан гражданнарына Президент һәм республика хөкүмәте проектларын җиткерәсез, сайлаучыларны законлы инициативалар белән чыгарга өндисез.

Сезне Татарстанның теләсә кайсы ноктасында таныйлар. Кешеләрчә җылылык, югары интеллект, ышандыра белү, сәясәтче һәм дипломат сәләте Сезгә, Фәрит Хәйруллович, парламенттагы гаять катлаулы хәлләрне уңышлы хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Сез Татарстанга хезмәт итүегезне элеккечә дәвам итәсез. Катлаулы елларда республикабыз җитди каршылыкларны һәм тәртипсезлекләрне читләтеп үтә алды. Бередә парламентның, шәхсән Сезнең хезмәтнең роле бәяләп бетергесез.

Фәрит Хәйруллович, ихлас күңелдән Сезгә алга таба да эшегездә уңышлар, бетмәс энергия, оптимизм һәм ныклы сәламәтлек телим!

Парламент көче векторы

Хөрмәтле Фәрит Хәйруллович!

Сезнең күркәм юбилеегыз – җитмеш яшегез якынлаша. Бу олы да, матур да дата – аңа Татарстан үсешенең өр-яңа тарихы белән бәйле нәтиҗәле хезмәт елларыгыз сыйган.

2000 нче еллар башында республиканың нинди куәтле сикереш ясаганын аның казанышлары сөйли. «Казан Гипронииавиапромы» АҖ XXI гасырда Россия тарихында беренче Иннополис – мәгълүмат технологияләре шәһәрен төзү, С.П.Горбунов ис. Казан авиация заводы, «КВЗ» ГАҖ, «КАМАЗ» ГАҖ, «Радиоприбор» ГАҖ, «ПОЗиС» ГАҖ стратегик предприятиеләрен камилләштерү һәм технологик яктан кабат җиһазландыру кебек киң колачлы проектларның шаһиты булды һәм анда турыдан-туры катнашты. Татарстан Россиянең төзелеш өлкәсендә әйдәп баручыларның берсе, күп кенә мөһим федераль программалар өчен тәҗрибә ясау регионы, социаль юнәлештәге күпсанлы проектларны тоташтыручы буын булды.

Бу процессларның барысына да Сез Татарстан Дәүләт Советы Рәисе буларак та, «Бердәм Россия» БСП ТРБ секретаре сыйфатында да һәм, билгеле, федераль дәрәҗәдә генә түгел, халыкара дәрәҗәдә дә республика мәнфәгатьләрен чагылдыручы актив җәмәгать эшлеклесе буларак та бәяләп бетергесез зур өлеш керттегез.

Сезнең дәрәҗәдәге дәүләт эшлеклесе өчен һәр ситуациянең асылын тирәнтен аңлап бетерү мәҗбүри түгел дә кебек… Шулай да гаять тыгыз график белән эшләвегезгә карамастан, Сез республиканың иң ерак районнарында булырга, гражданнарның сорауларын тыңларга һәм ишетергә, аларга реаль ярдәм күрсәтә ала торган муниципалитетларны һәм республиканың эре предприятиеләрен ул проблемаларны хәл итүгә тартырга өлгерәсез. Мондый эшнең нәтиҗәлелеге республиканың аеруча уңышлы проектларында чагыла. Аларның күбесе, шул исәптән закон чыгаручы инициативалар да, РФ төбәкләре өчен үрнәк булып тора.

Сез илһамландыра да, кирәк чакта кырыс һәм нык куллы җитәкче була да беләсез. «Бердәм Россия» партиясенең төбәк бүлеге юкка гына иң нәтиҗәлеләрнең берсе булып исәпләнми. Парламент инициативаларының гына түгел, урыннарда тормышка ашырылган проектларның саны буенча да. Менә быелга каралган планнарда да – мәгариф, социаль яклау, сәламәтлек саклау, ТКХ өлкәләрендә 20дән артык федераль һәм төбәк проектлары бар.

Бер интервьюгызда Сез Дәүләт Советының һәр утырышы – ул закон чыгару өстендә эшләүчеләр өчен һөнәри имтихан, ләкин, беренче чиратта, рәис өчен, дигән идегез. Һөнәри эшчәнлегегез өчен Сез дәүләт эшенең бик күп юнәлешләрен үзләштереп һәм алар белән бәйле гаять күп сорауларны хәл итеп, исәпсез санда имтихан бирдегез. Дәүләт эшлеклесе өчен тагын бер мөһим имтиханны уңышлы тапшырып киләсез: ул – ышаныч казануга имтихан. Республика җитәкчелеге һәм хезмәттәшләрегез алдында да, гади татарстанлылар каршында да. Ә халык ышанычы – теләсә кайсы сәясәтче өчен эшнең нәтиҗәлелеге дигән сүз ул.

«Казан Гипронииавиапромы» АҖ коллективы һәм үз исемемнән Сезгә бетмәс-төкәнмәс энергия һәм нык сәламәтлек, шулай ук гаиләгезгә, балаларыгызга һәм оныкларыгызга иминлек телим! Татарстанның чәчәк атуы хакына элеккечә үк яңа планнар һәм омтылышлар юлдаш булсын!

Казанский Гипронииавиапром

Реклама

PRESSA.RU

Ышаныч күрсәткече

Владимир Козонков,
Алексеевск муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе

Хөрмәтле Фәрит Хәйруллович!

Алексеевск районы халкы һәм үз исемемнән Сезне 70 яшьлек юбилеегыз белән тәбрикләвемә шатмын!

Күренекле шәхесләр тормышы еллар белән исәпләнми, аларга башкарган эшләре һәм казанышлары буенча бәя бирәләр. Без Сезне Татарстан Республикасында парламентаризм барлыкка килүгә зур өлеш керткән күренекле дәүләт эшлеклесе буларак беләбез. Күпкырлы эшчәнлегегез Татарстан һәм халык мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән. Республика мөстәкыйль дәүләт булып оешкан катлаулы чорда, аның язмышы хәл ителгәндә Сезнең гадәти булмаганча карарлар кабул итә белүегез, сәяси зирәклегегез, тәвәккәллегегез һәрчак ярдәм итте. Сезнең бай тәҗрибәгез Татарстан Республикасына гына түгел, халыкара дәрәҗәдә дә әһәмиятле.

Сез беркайчан да дәүләт эшчәнлеге белән генә чикләнмәдегез, республиканың җәмәгать эшләрендә дә актив катнашып килдегез. Сезнең күпкырлы эшчәнлегегез аша хезмәтегезгә чиксез бирелгәнлек һәм шул ук вакытта кеше факторын бернинди шартларда да югалтмавыгызны күреп тордык.

Хөрмәтле Фәрит Хәйруллович! Алексеевскилылар республиканың Дәүләт Советы тарафыннан булган ярдәме, шул исәптән авылны һәм крестьян хуҗалыгын саклауга булган игътибары өчен без Сезгә зур рәхмәтле.

Бүген күпсанлы теләкләргә без дә кушылабыз – бәхет, иминлек һәм уңышлар телибез, алга таба да Сезнең дәүләт эшлеклесе һәм татар халкының данлы улы буларак бай тәҗрибәгез туган Татарстаныбыз бәхете хакына хезмәт итәр, дип ышанабыз.

Республика мәнфәгатьләре шәхси теләкләрдән һәрчак өстен



Нур Шакиров,
«Казан медицина инструментлары заводы» АҖ генераль директоры

Бүгенге сәясәтчеләрнең бик азы гына Сезнең кебек җитди тормыш мәктәбе узгандыр – Сез Россиянең әйдәп баручы төбәгенең Премьер-министры һәм Дәүләт Советы Рәисе постына кадәр күтәрелдегез. Карьерагыздагы күтәрелүләр һәм күчерелүләр, үз теләгегез һәм омтылышыгызга караганда, күбрәк республика мәнфәгатьләре өчен кирәк булды. Сезне хакимият белән сыналган кеше, дип атарга була.

Республикадагы борылыш чорын искә төшермичә кала алмыйм. Элеккеге планлы тормыш 90нчы еллар башында тәмамланды, ә яңасы, базар мөнәсәбәтләрендәгесе, әле башланмаган иде. Республиканың дәүләт бәйсезлеге турындагы декларация без – җитештерүчеләрнең алдына килеп баскан проблемаларны һәм юридик мәсьәләләрне хәл итә алмады. Без Сезнең белән нәкъ менә 1990 елда, Сез Татарстан ССР Министрлар Советы рәисе урынбасары булган вакытыгызда таныштык. Ул чакта КМИЗ, илнең башка предприятиеләре белән беррәттән, полиэтиленга бик зур дефицит кичерә иде. Кулда рөхсәт кәгазе булса да, аны алу – мөмкин түгел эш. Безгә, ул чактагыча әйтсәк, халык кулланышы товарлары җитештерүче заводка полиэтилен бик аз күләмдә генә бүлеп бирелде. Ярдәм сорап Сезгә мөрәҗәгать иттем. Сез заводка килдегез, цехларны карадыгыз һәм... мәсьәләне хәл иттегез.

Икенче тапкыр безгә Сез республиканың Премьер-министры булып эшләгәндә хезмәттәшлек итәргә туры килде. Россия сәламәтлек саклау министры Александр Царегородцев янына килдек. Россиядә медицина инструментлары җитештерү мәсьәләләре турында фикер алыштык. Медицина җиһазлары базарындагы хәлләр турында РФ Премьер-министры Виктор Черномырдин исеменә хат язарга кирәк иде. Сез безнең белән янәшә утырдыгыз һәм хат текстын төзергә булыштыгыз – үтенечне ничегрәк белдерергә, игътибарны кайсы якка юнәлтергә, ә нәрсәләрне җайлы гына уратып үтәргә киңәш бирдегез. Билгеле, катлаулырак эшләрем дә бар, дип, моны үзегезнең ярдәмчеләрегезгә дә тапшыра ала идегез. Әмма Сез ул хатның Россия промышленносте, Татарстан, КМИЗ өчен ни дәрәҗәдә мөһим икәнлеген аңладыгыз. Безнең завод үзенең төп көчләрен – производствоны, коллективны, ассортиментны саклап кала алды. Монда Сезнең тырышлыкның да өлеше бар.

Башка предприятиеләргә дә һәрчак ярдәмгә килергә әзер торганыгызны беләм. Премьер-министр постында чакта Сез республика өчен җитди һәм мөһим проблемаларны хәл итеп, Татарстан предприятиеләренә зур файда китердегез.

Кайда һәм кем булып эшләвең мөһим түгел. Үз эшеңне намус белән башкаруың мөһим. Сез инде озак еллар Татарстан Республикасы Дәүләт Советын җитәклисез. Бу – республика законнарын, аның мәнфәгатьләрен исәпкә алып һәм федераль законнар белән тәңгәлләштереп камилләштерү буенча гаять катлаулы һәм зур тырышлык сорый торган эш.

Сез – чын сәясәтче. Сез җитәкли торган Дәүләт Советы дөнья законнарын өйрәнүгә иҗади якын килде һәм килә. Асылда парламентерлык – тоташ бер фән ул. Хезмәтегез – бәяләп бетергесез. Сез хәл ителмәслек ситуацияләрдән дә чыгу юлын беләсез. Зирәклек, демократлык, акыллы, үзара файдалы килешүчәнлеккә омтылу, башкалар фикеренә колак сала белү, урыннардагы хәлне аңлау – мин Сезне бүген шундый итеп күрәм.

70 яшь – истәлекле вакыйга, вакыт исәбенең яңа ноктасы. Аннан соң инде билгеләнгән барлык проектларны һәм планнарны тормышка ашыру чоры килә. «Казан медицина инструментлары заводы» АҖ коллективы һәм үз исемемнән Сезгә, Фәрит Хәйруллович, уңышлар, сәламәтлек, күтәренке кәеф, иминлек, алга таба да республика бәхете өчен нәтиҗәле эшләүне дәвам итүегезне телим!

Реклама

PRESSA.RU

ЧИТЛӘРМЕ? ҮЗЕБЕЗНЕКЕ!

«Без берсүзсез мигрантларны кабул итәбез, әмма Европадагы кебек түгел. Кем килгән, нинди ният белән, безнең мохиткә яраклаша алырмы – без ачыкларга тиеш...» Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республиканың күчеп килүчеләргә карата гомуми позициясен күптән төшендерде инде. Әмма өлкәннәргә кагылышлы вазгыять шактый анык булса, балаларга кагылышлы сораулар күп әле: ата-анасы ихтыяры белән чит илгә килеп эләккән кечкенә мигрантлар биредә җайлашсын өчен, нишләргә кирәк соң?

Автор:
Ольга Туманская

Әһлетдин Кыргызстаннан килгән. Мәктәп сәхнәсендә ул уйнаган образ беркемне дә битараф калдырмады.

ТӨРЕМКӘЙДӘ КЕМ ЯШИ?

– Әһлетдин, котлыйм сине. Ролеңне яхшы уйнадың!

Ул миңа ихластан елмая. Кызыл костюмлы малайга мин спектакль барышында ук игътибар иттем – Казанның 13 нче мәктәбендә «Төремкәйне» күрсәттеләр. Әһлетдин башкаруындагы купшы әтәч беркемне дә битараф калдырмады.

– Мин Кыргызстаннан килдем, – дип сөйли ул үзе турында. – Математиканы, әдәби укуны, рус һәм татар телләрен яратам... Тиздән «Әлифба белән хушлашу» спектаклендә уйнаячакмын!

– Миңа да, миңа да әйтергә ярыймы? – дип, безнең арага шаян кызчык килеп керә. Әһлетдингә күз кысып, Эльвина үз роленең өстенлекләрен санарга керешә. – Төлкебикә ул шундый хәйләкәр, шундый «модный»...

Тамашачыны әсир иткән Төлкебикә Эльвина да журналист соравына җавап бирергә ашыга.

Фото: Дмитрий Резнов

13 нче мәктәптә беренче ел уку дәверендә балалар шактый рус һәм татар сүзләрен өйрәнеп өлгергәннәр инде.

“ – Театр балаларны уңай аралашуга өйрәтә, фикерләүне үстерә, телне өйрәнү мөмкинлеген бирә. Мәсәлән, мигрант балаларга хас хата – нечкәлек билгесе.

Мәктәп студиясе җитәкчесе Лилия Илдаровна театр нәни мигрантларга тизрәк җайлашырга ярдәм итә дип саный.

– Безнең сыйныфыбыз бик тату, – дип аларга карап елмая башлангыч сыйныфлар укытучысы Лилия Сафиуллина. – Анда җиде төрле милләт баласы укый. Инде укытып чыгарган сыйныфларым буенча беләм, алар башлангыч мәктәптән соң да дус булып кала.

Лилия Илдаровна мәктәп театр студиясе белән инде күп еллар җитәкчелек итә. Үз методикасы буенча эшли, ә ул исә үз вакытында Бөтенроссия дәрестән тыш эшчәнлек программалары конкурсында беренче урынны алган булган. Бүген аның тәҗрибәсе Казанның конкрет бер мәктәбе кысаларында бәләкәй мигрантларны безнең мохиткә күнектерү өчен уңышлы файдаланыла.

– Театр балаларны уңай аралашуга өйрәтә, фикерләүне үстерә, телне өйрәнү мөмкинлеген бирә, – дип илһамланып сөйли ул. – Мәсәлән, мигрант балаларга хас хата – нечкәлек билгесе. Аларның туган телләрендә аның аналогы юк. Шаулы авазлар да бу сабыйларга авыр бирелә. Ә инде дөрес сөйләшергә өйрәнсәң, язу күнекмәләре дә яхшыра.

Тамашачы эскәмияләрендә малайлар утыра. Алар әлегә Татарстан телләрендә начар сөйләшә, әмма алга китеш бар – мәктәптә беренче ел уку дәверендә шактый рус һәм татар сүзләрен өйрәнеп өлгергәннәр инде. Тиздән аларга да йолдызлы рольләр эләгәчәк – «Мәче йортын» куячаклар. Сәхнәгә Әһлетдиннең иң якын дусты Мөхәммәд Али да чыгачак. Бик кәттә «тройка» костюм кигән бу малай Үзбәкстаннан килгән. Алар барысы бергә – Лилия Илдаровнаның иң шәп ярдәмчеләре. Тыйнак, аз сүзле, тыңлаучан малайлар җирле шук сабыйлар фонында аерылып тора: «Шәрык тәрбиясе!»

Әһлетдиннең иң якын дусты Мөхәммәд Али Үзбәкстаннан килгән. Тиздән аңа да мәктәп сәхнәсендә йолдызлы роль тапшырылачак.

Укытучылары әйтүенчә, ул аларга мәктәп тормышында кайнап яшәргә бер дә комачауламый.

ПРОБЛЕМАЛЫ УЙНЫЙБЫЗ!

Башка спектакль, бусы «Мәче йортыннан» җитдирәк. Сәхнәдәге хәлләр өлкәннәрне дә тетрәндерерлек.

– Син алар өчен чит! Һәм чит булып калачаксың да! – дип, башкалага Кавказдан килгән баш геройны «үтерә» аның якташы.

Куючы режиссер спектакльне конфликтның иң кискен җирендә туктата да, тамашачыларга проблеманы тикшерергә тәкъдим итә – Яһүд музее каршындагы Мәскәү толерантлык үзәгендә дулкынландыргыч сорауларга җавапларны шулай эзлиләр. Үткән елдан бирле әлеге технологияне Татарстан халыкларының Яшьләр ассамблеясы да файдалана. Аның каршында төзелгән «МУВИ» (Мирное Урегулирование Вопросов Интернационала) Форум-театры милләтара проблемаларда махсуслаша. Биредә профессиональ актерлар һәм әзер сценарийлар юк. «МУВИ» – ул сезнең белән без, этник стереотипларны юкка чыгарырга тырышучы кешеләр», – дип ышандыра анда йөрүчеләр.

«МУВИ» турында миңа Ләйсән Каюмова әйтте. Мәктәпкәчә тәрбия һәм башлангыч белем бирү кафедрасы ассистенты ул, сыйныфка мигрант бала килгәч пәйда була торган хәвефләрне өйрәнә. Мондый балалар төркемендә нинди хәлләр була? Әлеге фактны укытучы ничек кабул итә?

Биредә профессиональ актёрлар һәм әзер сценарийлар юк. «МУВИ» – бу гади, дөрес булмаган этник стереотипларны юкка чыгарырга тырышучы кешеләр.

ТАТАРСТАНДА
УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ
УКЫ!

КФУ Психология һәм мәгариф институты базасында икенче ел гамәлгә кертелә торган укытучыны мультикультуралы әзерләү проекты кысаларында Ләйсән үстерү технологияләренең мөмкинлекләрен өйрәнә. Форум-театр – шулардан берсе. Күптән түгел «МУВИ»га йөрүчеләр институтта булачак укытучылар белән очрашкан. Алар бергәләп бүгенге җәмгыятьтәге дөрес булмаган стереотипларны тикшергән. Янәсе, кайсыдыр милләт кешеләре – хәйләкәр, кайсылары – явыз, өченчеләре – тәкәббер... Студентларга барлык катлаулы моментларны сценарий итеп язарга кушылган. Чираттагы очрашу вакытында аларны детальләргә таркатып, хәл итү юлларын эзләячәкләр. Ихтимал, булачак мөгаллимнәрнең берсе сәхнәгә чыгып, үзен мигрант бала урынына куеп карар... Шул рәвешле, ул укытучы булып эшли башлаганчы ук, күп кенә кискен сорауларга җавап табачак.

Ә сораулар күп. Иң беренчесе: мондый балалар белән ничек эшләргә? Күп укытучы моны белми. Мигрантлар алар өчен өстәмә йөкләмә булып тора, ахыр чиктә сыйныфның өлгереш күрсәткечләре начарлана. Ә бу өстәмә эш өчен өстәмә акча да түләнмәсә?

КФУ Психология һәм мәгариф институты галимнәре инде икенче ел рәттән Татарстан мәктәпләрендә мигрант балаларның тел һәм социомәдәни адаптациясен тикшерү белән шөгыльләнә. Укытучыларны сораштыру нәтиҗәләре шуны күрсәтә: аларның күпчелеге бәләкәй мигрантлар белән эшләүдә кыенлыклар кичерә. Доцент Резеда Хәйретдинова, бу проблемадан китәргә ярамый, дип саный.

– Телне белмәү нәни мигрантларны үз потенциалын тулысынча файдалану мөмкинлегеннән мәхрүм итә, – ди ул. – Анкета үткәрү күрсәткәнчә, еш кына мондый балалар, бернәрсә дә аңламыйча, дәрестә тыныч кына утырып тора. Укытучы исә бик шатланып булышыр иде дә, инофоннар белән эшләү методикаларына өйрәтелмәгән – бала өчен

чит тел булган рус телен ничек укытырга кирәклеген белми.

«БЕЗНЕҢ МИГРАНТЛАР ИМТИХАН БИРӘ АЛА!»

Бервакыт, мәктәп коридорыннан барганда, 13 нче мәктәп директоры Сергей Овчинников каршына очраган малайдан гадәттәгечә: «Хәлләр ничек?» – дип сораган. «Шәп!» – дигән мәгънәдәге җавап яңгыраган, тик ишеткән сүгенү сүзеннән директор егылып китә язган...

– Әлбәттә, мин башта шаккаттым, – дип көлә бүген Овчинников. – Бәхеткә, мин шундук аның нәрсә әйткәнен аңламаганын чамаладым. Бу, билгеле, бик катгый мисал, әмма ул бик урынлы да. Шундый гаҗәеп нәрсә бар, һәм без моның белән еш очрашабыз, – бала русча шактый яхшы укый һәм аралаша, тик шул ук вакытта күп сүзләрнең мәгънәсен бөтенләй аңламый.

– Без бу балаларны беренче сыйныфтан бирле укытабыз, – дип дәвам итә директор. – Безнең бурыч – алар кимендә тугызынчы класска җитәргә һәм төп дәүләт имтиханын бирергә тиеш. Һәм менә мин нәрсә әйтә алам: безнең мәктәптә укыган бер генә мигрант баланың да имтихан бирә алмыйча калганы булмады. Үзбезнекеләрнең кайберләре бирә алмый, ә менә алар – бирә! Бу күпьеллык хезмәт нәтиҗәсе.

Мәктәп директоры Сергей Овчинниковның эш өстәле мигрант балаларның рус теле буенча язылган эшләренә күмелгән. «Безнең мәктәптә укыган әлеге балаларның берсенең генә дә имтихан бирә алмыйча калганы булмады», – ди ул һәм шунда ук моның артында укытучының зур хезмәте торуын ассызыклый.

“ – Мигрант балалар белән күбрәк эшләгән саен, үзең өчен күп яңа нәрсә ачасың.

Мигрант балаларның адаптация проблемасын хәл итү өчен Казанда күптән түгел Миграцион педагогика үзәге ачылган. Татарстан укытучыларының квалификациясен күтәрү курсларының беренчесе ноябрьдә башланачак. Алай гына да түгел, КФУ Психология һәм мәгариф институты галимнәре Мигрант балаларның тел һәм социомәдәни адаптация үзәген төзү инициативасы белән чыкмакчылар.

– Безнең югары уку йортында моның өчен бөтен шартлар да бар, – дип ышандыра Резеда Хәйретдинова. – Педагоглар, психологлар, методистлар эшли... Бу идея белән ТР Мәгариф министрлыгына мөрәҗәгать итәргә телибез.

Тик әлегә республикада мондый программалар башланмаган, шунлыктан катлаулы мәсьәләләрне хәл итү юлларын мәктәпләр үзләре эзли. Сергей Николаевич мәктәбендә укытучылар рус теле буенча өстәмә курслар алып бара. Укыту берничә этапта үтә. Беренчесе – өйрәнә башлаучылар өчен, соңгысы – инде телдә иркен аралашучылар, дәресләрдә кимендә «дүртле» алучылар өчен. Сүз уңаеннан, коридорда аңа очраган малай хәзер инде КДАТУ тәмамлый һәм русча бик яхшы сөйләшә.

– Мигрант балалар белән күбрәк эшләгән саен, үзең өчен күп яңа нәрсә ачасың, – ди Сергей Овчинников. – Менә, мәсәлән, төрки халыкларның телләре охшаш, шунлыктан үзбәк, кыргызларга башта татарча өйрәнеп, аның аша рус теленә килү җиңелрәк. Без бу үзенчәлекне файдаланабыз. Ә менә таҗиклар белән мондый алым бармый – аларның теле фарсы төркеменә карый. Алар өчен татар теле дә рус теле кебек үк чит.

ТОРМЫШ МИНЕКЕ, КАГЫЙДӘЛӘР СИНЕКЕ

– Беләсезме, максат бит мигрантларның безнең телләрдә мөмкин кадәр тизрәк сөйләргә өйрәнүендә генә түгел, алар безнең закон һәм кагыйдәләр буенча яшәүгә яраклашырга тиеш, – ди Сергей Николаевич. – Һәм без аларга ияреп килгән проблемаларга кул селтәмибез.

Ул Казанга элекке союздаш республиканың ерак бер авылыннан килгән укучысының язмышы белән таныштыра. Әнисенә баланы кыйнарга ярамаганны төшендерү өчен, ярты ел вакыт киткән.

– Ул үзенең гаебен берничек тә аңламый иде, чөнки аның ватанында бу гадәти хәл санала, – дип сөйли директор. – Кызын вакытлыча приютка урнаштыргач, бик гаҗәпләнде хәтта.

Бәхеткә, мәктәптә мондый проблемалар еш очрамый, ә менә көнкүрешкә кагылышлы сораулар гел туып тора.

– Башка илләрдә норма саналган кайбер нәрсәләр безнең җәмгыятьтә аптыраш тудырырга мөмкин. Мәсәлән, кайбер ата-аналар, ризык хәләл булмауны сылтау итеп, балаларын безнең ашханәдә ашатмый. Бала көн буена ач йөрмәскә тиеш бит, әнисе үзе белән биреп җибәрергә ризалаша. Бала ул ризыкны кулы белән ашый... Укытучыга тагын бер бурыч өстәлә – ул аның кулы чиста булуын тикшерергә тиеш...

PRESSA.RU

“ – Без берсүзсез мигрантларны кабул итәбез, әмма Европадагы кебек түгел. Кем килгән, нинди ният белән, безнең мохиткә, безнең культурага яраклаша алырмы – без ачыкларга тиеш...»

(ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның Казан Шәһәр думасы сессиясендәге чыгышыннан, 2016 елның 26 феврале)

– Бер караганда, мәктәптә бөтен бала да бертөсле киенгән һәм бер телдә сөйләшә кебек, әмма һәр сабыйның үз холкы, тәрбия үзенчәлекләре бар бит, – дип шәрехли КФУ Психология һәм педагогика институты доценты, Миграцион педагогика үзәге җитәкчесе Чулпан Громова. – Алар аның канына сеңгән, гаиләсендә кабул ителгән, һәм ул мәктәптә дә үзен шул нормаларга ярашлы тота. Укытучы моңа ничек карарга тиеш?Дөньяви аралашу кысаларында гына күп нәрсәне хәл итү мөмкин түгел. Моның өчен төрле мәдәниятләрнең үзенчәлекләрен белү зарур – һәм бик тиздән мондый белемне безнең үзәктә алу мөмкин булачак.

КҮЧҮ КЫЕНЛЫКЛАРЫ

Бервакыт 13 нче мәктәптә гадәти булмаган ата-аналар җыелышы үткәрелгән. Аны сыйныф җитәкчесе дә, директор да түгел, бәлки... бер милли диаспора рәисе уздырган. БДБ илләренең берсеннән килүчеләрнең балалары түгел, әтиәниләре белән мәктәптә проблемалар башланган. Алар, сүз куешкан кебек, мәктәп кагыйдәләрен дә, администрациянең балалар гигиенасы, киеме, тукклануына кагылышлы таләпләрен дә санга сукмаган...

– Шуңа мин рәискә мөрәҗәгать итеп, хәлне аңлаттым, – дип сөйли директор. – Ул үзе җыелыш үткәрергә теләк белдерде, минем әлеге сөйләшүдә катнашмавымны үтенде. Шуннан соң катлаулы сорауларның бер өлеше үзеннән-үзе чишелде. Мин бик озак гаҗәпләнеп йөрдем, аннан соң исә ул миңа аңлатып бирде: читтән килүчеләрнең безнең алар турында нәрсә уйлавыбызга бер дә исе китми, әмма алар ватаннарында үзләре турында яман хәбәр таралудан курка. Менә нинди милли нечкәлекләр бар икән, ә без аларны бөтенләй аңламыйбыз бит!

Сүз уңаеннан, мәктәп бүген барлык диаспоралар белән балаларны белем бирү мохитенә адаптацияләүдә ярдәм күрсәтү буенча килешүләр төзегән.

ҖИДӘҮ БЕР КЕШЕНЕ КӨТМИЛӘР

Мигрантларның балалары ничек укырга тиешлеге турында бәхәс күптәннән бара. Җәмәгатьчеләр һәм сәяси партияләр вәкилләре, мондый балалар өчен махсус мәктәпләр яки аерым сыйныфлар гына булса да ачуны сорап, инде әллә ничә тапкыр РФ Мәгариф министрлыгына мөрәҗәгать иткән.

– Болай эшләргә һич ярамый! – ди Сергей Овчинников. – Алай гына да түгел, мин, мәгариф идарәсе бер класста бер үк милләттән булган берничә мигрант бала булмавын контрольдә тотарга тиеш, дип саныйм.

Директор әйтүенчә, сәбәбе гади: бала таныш булмаган тел мохитенә эләккәндә, һичшиксез яңа телне

Телне белмәү нәни мигрантларны үз потенциалын тулысынча файдалану мөмкинлегеннән мәхрүм итә, дип саный КФУ галимнәре. Бәхеткә, Казанның 13 нче мәктәбендә әлеге проблеманы ничек хәл итәргә кирәклеген беләләр. Сәхнәдә нәни мигрантлар төп казанлылар белән бергә уйныйлар.

өйрәнергә мәҗбүр, чөнки сабыйлар аралашмыйча тора алмый бит! Ул тиз җайлаша: бер-ике айда бала таныш булмаган телдә аралаша да башлый. Әмма инде сыйныфта бер генә милләттәше булса да, әлеге процесс еллар буена сузылырга мөмкин.

> **– Беләсезме, бала мәктәпкә никадәр күбрәк мәшәкать тудырса, соңыннан шулкадәр рәхмәтлерәк булып исенә төшерә. Мөгаен, үзенә күбрәк кайгырту тигәнен аңлыйдыр.**

ТӘРҖЕМӘЧЕ БАЛАЛАР

Бүген 13 нче мәктәптә РФ Мәгариф министрлыгының мөһим карарын көтәләр – «Мигрант балаларны мәгариф мохитенә адаптацияләү» программасын гамәлгә кертүгә грант алырга өметләнәләр.

– Әгәр без мондый эшчәнлек белән шөгыльләнәбез икән, без моны техник яктан яхшырак коралланып эшләргә тиеш, – ди Сергей Овчинников. – Рус телен өйрәнү өчен лингафон кабинеты алу турында хыялланабыз. 1 сентябрьдән мигрантларны адаптацияләү буенча тагын бер юнәлешне – ата-аналар өчен курсларны эшләтеп җибәрергә телибез. Әнисе баласына өй эшен эшләргә булыша алырлык булсын. Алайса бүген без күп кенә әтиәниләр белән балалары аша гына аралашабыз!

– Беләсезме, бала мәктәпкә никадәр күбрәк мәшәкать тудырса, соңыннан шулкадәр рәхмәтлерәк булып исенә төшерә, – ди Сергей Николаевич саубуллашканда. – Мөгаен, үзенә күбрәк кайгырту тигәнен аңлыйдыр. Мондый балаларга һичшиксез ярдәм итәргә кирәк.

Ә минем мәктәп укытучылары белән галимнәрнең хезмәтен мәгариф чиновниклары да хуплавына, республикада, үз мәдәниятләрен һәм милли үзенчәлекләрен саклап калып, бәләкәй мигрантларга җайлашырга мөмкинлек бирә торган тагын бер уңышлы программа гамәлгә кертелүенә ышанасым килә. Чөнки бу сабыйлар да – Татарстанның киләчәге бит.

PRESSA.RU

КОМАНДАЛЫ УЕН

– Сез биремне үти алмадыгыз! – ди «заказчы».
– Кемнәр? – дип аптырый башкаручылар.
– Барыгыз да!

Автор:
Катерина Котова

Бу биремнәрнең берсеннән соң булган күренеш. Шактый гыйбрәтле һәм эмоциональ. Бүген КФУ Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбендә гадәти булмаган аудитория – министр урынбасарлары һәм республика башкарма комитетлары җитәкчеләре дәрәҗәсендәге зур урыннарда утыручы чиновниклар.

БУ – ПРОВОКАЦИЯ!

Программада катнашучыларны ике төркемгә бүлеп, бирем бирәләр. Бер төркемгә идәндә баудан – турыпочмаклык, икенчесенә өчпочмак ясарга кирәк. Беренче карашка, бик яхшы үтәгәннәр кебек. Шунлыктан «заказчының» канәгатьсезлеге барысы өчен дә көтелмәгәнрәк булып чыга. Ә алар исә аерым фигуралар түгел, бәлки йорт ясарга тиеш булган икән.

– Кем гаепле? – дип сорый катнашучылардан тренер.

Аптыраш тиз арада ачулануга әйләнә: бәхәс вакытында төркемнәрнең берсенең биремендә йорт төзү соралуы ачыклана. Гаеплеләрне эзләү шактый озакка сузыла, һәм менә канәгатьсезлек хәтта «заказчының» үзенә дә барып җитә.

– Менә шундый хәл сезнең министрлыкларыгызда да еш күзәтелә, – дип тагын бер нәтиҗә ясый тренер. – Беләсезме, без һәрвакыт күпбурычлылык, билгесезлек, мәгълүмат кытлыгы шартларында эшләячәкбез. Һәм әгәр без үзара нәтиҗәле аралашырга өйрәнмәсәк, ике күрше территориядә дә икешәр яшелчә саклагыч яки кирәк булмаган җирдә бәрәңге эшкәртү заводы урнашачак...

Татарстан җитәкче кадрларының идарә итү күнекмәләрен үстерү буенча программасы менә шундый провокациядән башланды.

ХЕЗМӘТТӘ – «ЯҢА САЙЛАНУЧЫЛАР»

– Республикабызның җитәкче составын без даими укытабыз, – дип сөйли КФУ Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры Игорь Привалов. – 2015 елда башкарма хакимият органнары җитәкчеләренең бөтен урынбасарларын – барлыгы 95 кешене колачлый алдык.

Ул чактан бирле инде ике ел үткән – бу вакыт эчендә Татарстанда министрлык һәм ведомстволар составлары шактый яңарган. Яңа сайланган җитәкчеләрнең кайберләре әле дәүләт эшчәнлеге спецификасына һәм ведомство культурасына иялэшеп җитмәгән.

– Эш шунда: яңа министр урынбасарлары арасында дәүләт хезмәтендәге карьера баскычының бөтен басмаларын үткәннәр генә түгел, башка тармаклардан килеп, дәүләт секторында эшләү тәҗрибәсе бөтенләй булмаганнар да бар, – дип шәрехли Игорь Привалов. – Алар өчен бердәм мәгълүмат кыры булдыру, республикадагы гомуми тенденцияләр, Стратегия-2030 программасының ничек тормышка ашырылуы турында сөйләү зарур һәм аларны бер-берсе белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итәргә өйрәтү мөһим.

КӨНДӘШЛЕКТӘН – ХЕЗМӘТТӘШЛЕККӘ

– Кайвакыт башка министрлык һәм ведомстволар белән үзара хезмәттәшлек шәхси элемтәләр нигезендә генә урнаштырыла, – дип, проблеманы аудиториядә тикшерүгә чыгара катнашучыларның берсе. – Конкрет кешегә шалтыратасың да «тизләтүне» үтенәсең.

Эш шунда: бу курсның бурычы – программада катнашучыларга яңа идарә итү күнекмәләре генә бирү түгел, алардан фикердәшләр командасы формалаштыру да. Бу бергәлекне алар үзләренең һөнәри эшчәнлекләренә алып китәчәк.

– Җитәкчеләрнең беренче һәм икенче линейкалары – бик кызыклы аудитория, – ди мәктәпнең гадәти булмаган «укучылары» турында әлеге программаның тренеры Галина Маштакова. – Алар белән эшләве кызык. Тик без бер-беребезгә шактый кыен иялэштек. Уку курсларына мондый составта алар беренче тапкыр җыелды. Баштарак коллегалары арасында күбесе үзен уңайсыз хис итте. Шуның өстенә, аларның һәркайсы лидер – югары вазыйфаларга теләсә кемне билгеләп куймыйлар бит. Аларның һәркайсы үзе артыннан ияртергә сәләтле, шунлыктан безнең беренче дәресләребез «аркан тартышуга» әйләнә иде.

Тренер әйтүенчә, әлеге программада катнашучылар үзләре өчен күп ачыш ясаган. Мондый дәрәҗәдәге җитәкчеләргә җаваплылыкны үз өсләренә алу гына түгел, гаепләрен таный белү дә мөһим – «йорт төзелеше» биреме моңа һәркемнең дә сәләтле булмавын ачыклаган. Моннан тыш, тренинг шуны ачык күрсәткән: еш кына

алар көндәшлек стратегиясен төзи, әмма глобаль республика максатларына ирешү өчен, килешү, берләшү осталыгы таләп ителә. Мондый эш – ялгыз йөгерү түгел бит. Бу – командалы уен.

– Кайвакыт лидер позициясе шуннан гыйбарәт: процессны контрольдә тотып, ул башкаларга үзен күрсәтү мөмкинлеген бирә, – дип аңлата Маштакова. – Шул исәптән үзе җитәрлек компетентлы булмаган яки проблеманы хәл итә алмаган очракларда да. Идарә дилбегәсен башкаларга биреп торырга да өйрәттек без аларны.

ХАКИМИЯТТӘ «ОТЛИЧНИКЛАРМЫ»?

Зур урындагы чиновникның эшен бәяләү бер үк вакытта гади дә, катлаулы да бурыч ул. Бер яктан карaганда, илдә яшәүче һәркемнең моңа үз фикере бар. Икенче яктан карaганда, «халык хезмәтчеләренең» хезмәтен конкрет күрсәткечләрдә исәпләү өчен, дөньяның иң акыллы кешеләре тикмәгә генә башларын ватмый бит. Хәер, Татарстан биредә дә калышмый – бездә инде үзебезнең KPI (Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре) системасы кертелә, аны ТР Президенты Аппараты җитәкчелегендәге махсус төзелгән эш төркеме ике елдан артык эшләгән.

Әлеге проект башлангыч режимда моннан өч ел элек эшләтеп җибәрелгән һәм Стратегия-2030 да чагылдырылган. Халыкның тормыш дәрәҗәсе өчен җаваплы сигез интеграль күрсәткеч барлык министрлык һәм ведомстволарда теркәлгән. Нәтиҗәдә бәяләүнең гомуми системасына өч меңнән артык дәүләт һәм муниципаль хезмәткәр кертелгән. Алар арасында – министрлар һәм аларның урынбасарлары.

– Безнең программаның беренче модулендә катнашучылар үз сорауларын аны төзүчеләрнең үзләренә бирә алды, – дип сөйли янә KPI системасын булдыруда турыдан-туры катнашкан Галина Маштакова. – Сорауларның иң «кайнарлары» чиновникларның үз хезмәтләрен бәяләүгә түгел, бәлки аларның бу система ярдәмендә үз хезмәткәрләрен ничек кызыксындыра алуына кагыла иде. Безнең дәүләт хезмәткәрләренең эш хакына килсәк, бүген республика РФ субъектлары арасында алдынгы урыннарда түгел әле.

НОУ ПРОБЛЕМ

– Мин нәтиҗәсез киңәшмәләр проблемасына да тукталыр идем, – ди флипчарт янында торучы ират. – Бу сорауны республика Президенты да күтәргән иде. Кайвакыт андый киңәшмәләрдә көн буе утырырга туры килә, аларның исә бер файдасы да юк.

– Ә безнең киңәшмәләр башка төрле, – дигән реплика ишетелә залдан. – Без аларны бик тиз үткәрәбез һәм һәрвакытта да конкрет карар кабул итәбез. Тәҗрибәм белән уртаклаша алам...

Кадрларның еш алмашынуы, район үзәкләренә белгечләрне җәлеп итүдәге кыенлыклар, эш күләменең зур, хезмәткәрләр эш хакының түбән булуы – исемлектәге проблемаларның республика министрлары урынбасарлары һәм башкарма комитетлар җитәкчеләре программа башланганда аерып күрсәткән кайберләре генә. Мондый шартларда ничек нәтиҗәле эшләргә? КФУ Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбендә алар һәр проблемага җавап табачак. Программада идарә итү компетенцияләрен камилләштерүгә юнәлтелгән блоклар да бар. Мәсәлән, апрельдә үткән беренче модульгә проект һәм финанс идарәсе буенча курс кертелгән булган.

> **“ Кайвакыт лидер позициясе шуннан гыйбарәт: процессны контрольдә тотып, ул башкаларга үзен күрсәтү мөмкинлеген бирә.**

– Шактый югары статусларына карамастан, программада катнашучылар үзләренә нинди белем җитмәвен аңлый башлый, – дип сөйли Галина Маштакова. – Мәсәлән, күбесе үзенә халык алдында чыгыш ясау күнекмәләре җитешмәвен ачыклады. Курс кысаларында без артык сүз сөйләмәскә, кирәклесен генә аерып әйтергә, фикерләрне башкалар ишетерлек итеп әйтә белергә, сорауларны дөрес бирергә өйрәтәбез. Анда тагын бер кызыклы блок – кыен хәл туганда хисләр белән идарә итәргә өйрәтү дә бар.

УРЫНБАСАР ӨЧЕН ИМТИХАН

Чын мәктәптәгечә, биредә дә укыту программасыннан соң имтихан бирү каралган. Министр урынбасарлары өчен үз проектларын яклау мөмкинлеге бар.

– Әлеге проектлар үзебез турында, республика турында, – дип сөйли Галина Маштакова. – Без халыкның тормыш сыйфатының өстенлекле биш күрсәткечен сайлап алып, аларга бәйле конкрет проблемаларны тикшердек. Укучыларыбыз үз проектларында аларны хәл итү юлларын тәкъдим итә.

– Без һәрвакыт кайчандыр үзебезнең мәктәптә туган идеяләрнең югалмавына, бәлки чын тормышта гамәлгә ашырылуына куанабыз, – дип нәтиҗә ясый Игорь Привалов. – Алар республика министрлык һәм ведомстволарының конкрет проектларында чагылыш таба.



PRESSA.RU

АГРОНАНОИНДУСТРИЯ – ЭКОЛОГИК АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҖИТЕШТЕРҮЕНЕҢ ИҢ МӨҺИМ ҮСЕШ ФАКТОРЫ

Борис Павлов,
РФ һәм ТРның атказанган икътисадчысы, РФнең мактаулы машина төзүчесе, Россия Нанотехнологияләр җәмгыяте вице-президенты, А.Н. Туполев исемендәге КМТТУ-КАИ профессоры

Хәзер авыл хуҗалыгы тулай иҗтимагый продуктның 12%тан артыгын һәм Россия милли кеременең 15%тан артыгын җитештерә, илнең төп җитештерү фондларының 15,7% эченә ала.

Шуның белән бергә, хәзерге җәмгыятьнең төрле тармакларында тормыш эшчәнлеген тәэмин итү (шул исәптән энергоресурслар җитештерү) өчен торгызыла торган табигый, экологик ресурслар чыганагы сыйфатында авыл хуҗалыгы продукциясен куллануның глобаль дәрәҗәдә һичшиксез артуы якын киләчәктә тулаем эчке продуктның гомуми күләмендә аның өлешенең 50–55%ка кадәр үсүенә китерәчәк һәм аны дөнья икътисадының әйдәп баручы сегментына әйләндерәчәк. Авыл хуҗалыгы үсешендәге мондый тренд инде бүген үк җитештерү процессында катнашучыларны һәм авыл хуҗалыгы продукциясен файдаланучыларны тармакларга инновацион технологияләр, шул исәптән нанотехнологияләр, эшкәртү һәм кертүнең нәтиҗәлелеген күтәрергә мәҗбүр итә, бу авыл хуҗалыгы продукциясен киңәйтелгән югары көндәшлекле җитештерү һәм эшкәртүне тәэмин итәчәк.

Бүген авыл хуҗалыгын үстерүгә яңача якын килү сорала, алар авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, эшкәртү һәм сатуның тулы тормыш циклын эченә алырга, игенчелектә уңышның яки терлекчелектә баш санының тышкы факторларга бәйлелегеннән мөмкин кадәр котылдырырга тиеш. Шул ук вакытта табигый мохит белән каршылыкка керә торган агрохимикатлар һәм технологияләр кулланудан баш тарту да максатка ярашлы.

Бәхәссез, аграр фән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе үсешендә яңа этап башлана, алар җитештерелә торган продукция күләме һәм сыйфатының һаман да арта барган дотацияләргә һәм әйләнә-тирәлеккә тискәре йогынты ясаучы факторларга бәйлелек дәрәҗәсен мөмкин кадәр киметүне тәэмин итәргә тиеш.

Шуның белән бергә, гәрчә авыл хуҗалыгы теләсә кайсы дәүләт икътисадының иң мөһим тармакларыннан берсе булса да, ватаныбызның авыл хуҗалыгы фән ягыннан чагыштырмача үсмәгән тармак булып кала бирә, агросәнәгать комплексы нанотехнологияләр узышында әлегә калыша.

Россиянең авыл хуҗалыгы үсешендәге әлеге диспропорцияне бүген эшләнеп ята торган Россия милли инновацион системасы нигезе кысаларында юкка чыгару мөмкин, нәкъ менә ул фәнни идеяләрне тупларга һәм коммерцияләштерергә, югары нәтиҗәле, икътисадый һәм экологик яктан максатка ярашлы яңа технологияләр, шул исәптән өстенлекле тәртиптә илнең агросәнәгать комплексында да, уйлап табу һәм кертүне тәэмин итәргә тиеш. Бу бигрәк тә игенчелек өчен мөһим, чөнки биосферага һәм аның иң мөһим өлеше – туфракка техноген тәэсир итү дәрәҗәсе даими үсә, бу исә туфракка антропоген йөкләнешне арттыра, табигый экосистемаларның тулаем тотрыклылыгын киметә һәм агроэкосистемаларга ярдәмгә торган саен күбрәк чыгымнар таләп итә.

Агронанотехнологияләрнең фәнни яңалыгы шунда ки, карала торган процесслар һәм кылына торган гамәлләр пространство үлчәмнәренең нанометрлы диапазонында бара. Традицион технологияләрдән аермалы буларак, агронанотехнологияләргә «шәхси» якын килү хас, бу вакытта тышкы идарә, аерым атом һәм молекулаларга барып җитеп,

алардан өр-яңа физик-химик һәм биологик үзлекле «дефектсыз» материаллар да, биосистемаларның нанометрлы үлчәмле яңа классларын да төзү мөмкинлеге бирә.

Авыл хуҗалыгында һәм азык-төлек сәнәгатендә нанотехнологияләр һәм наноматериаллар куллануның төп юнәлешләрен АСК продукциясен җитештерү һәм эшкәртү, авыл хуҗалыгы машиналары төзү, техник сервис һәм экология тәшкил итә. Авыл хуҗалыгында аеруча перспектив нанотехнологияләр булып биотехнология һәм геннар инженериясе тора.

Халыкара ETC Group* тикшеренү оешмасы экспертларының җир эшкәртүдә агронанотехнологияләрне куллануның нәтиҗәлелеге буенча мәгълүматлары дәлилләгәнчә, барлык ашамлык (бәрәңге, бөртеклеләр, яшелчә, җиләк-җимеш) һәм техник (мамык, җитен) культураларның уңышы уртача 1,5–2 тапкырга арта икән.

Мондый эффектка наноүлчәмле микроэлемент кисәкчекләренең үсемлеккә активрак керүе һәм аларның электрохимик мәгънәдә нейтраль статусы нәтиҗәсендә ирешелә. Аерым алганда, наномагнийның үсемлекләрдәге фотосинтезны тизләтүгә уңай тәэсире һәм, нәтиҗә буларак, авыл хуҗалыгы продукциясенең файдасы артуы күтәлә; шулай ук үсемлекчелектә кулланыла торган нанокремнеорганик биостимуляторлар салкынга, эссегә һәм корылыкка чыдамлыкны арттырыр, стресслы һава хәлләреннән (кыраулар, температураның кискен күчешләре h.б.) зыян күрмәскә булышыр, үсемлекләрнең авыруларга һәм корткычларга каршы саклагыч функцияләрен көчәйтер, дип өметләнәләр.

Нанотехнологияләр шулай ук җыеп алынган көнбагыш, тәмәке һәм бәрәңгене эшкәртүдә, температура көйләнә торган мохиттә алманы саклауда, һаваны озонлаштыруда кулланыла.

Терлекчелектә һәм кошчылыкта азык-төлек әзерләгәндә нанотехнологияләр продуктивлыкны 1,5–3 тапкырга арттыруны, стрессларга каршы торучанлыкны һәм үлем-китемне 2 тапкыр киметүне тәэмин итә. Үсемлек һәм хайваннарга куелган наноҗайланмалар күп кенә процессларны автоматлаштыру һәм кирәкле мәгълүматларны үз вакытында тапшыру мөмкинлеген бирә.

Гомумән, авыл хуҗалыгы җитештерүендәге агронанотехнологияләр ярдәмендә:

- җитештерүнең куркынычсызлыгы арта һәм продукциянең сыйфаты яхшыра;
- үсемлекләрне үстергәндә чыгымнар кими;
- чәчүлек материалның сыйфаты яхшыра;
- авырулар кими, корткычларга каршы тору сәләте арта;
- үсемлекләрнең уңышы арта;
- экологик чиста (куркынычсыз) продукция алына.

Шуның белән бергә, дөньяда агронанотехнологияләрне коммерция максатларында киң куллану аларны файдалану нәтиҗәсендә килеп чыгачак үзгәрешләрне бәяләүне һәм дөнья җәмәгатьчеге тарафыннан аларны куллануга кагылышлы норматив-хокукый документлар эшләнүне таләп итә.

Нәкъ менә шул бурычларны хәл итү өчен, Россия Нанотехнологияләр җәмгыяте химаясе астында «Агронаноиндустрия» консорциумы төзелгән, аның эшчәнлеге агронанотехнологияләрне эшләү һәм кертүгә, югары көндәшлекле авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүгә юнәлтелә.

Быел апрельдә узган Россия венчур форумындагы чыгышында ТР Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов билгеләп үткәнчә, инновацион проектларны сайлап алганда һәм гамәлгә керткәндә өстенлек практик нәтиҗәсе булганнарына бирелергә тиеш, һәм «Агронаноиндустрия» консорциумы эше нигезенә нәкъ менә шул критерий салынган.

Әйтик, «Агронаноиндустрия» консорциумының Татарстандагы партнёрлары гамәлгә

* ETK Груп

кертә торган технологияләр һәм продукция инде бүген үк аларны җитештерү һәм файдалануда түбәндәге өстенлекләргә ирешергә мөмкинлек бирә:

• югары көндәшлекле, экологик авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү;

• вегетация чорын кыскарту, бу Россиянең барлык төбәкләре өчен актуаль;

• җитештерү процессында химия кулланмау;

• төп җитештерүнең кыска җитештерү циклы;

• бернинди калдык та калмау (1%тан да азрак);

• продукциянең базар бәясе түбән булу.

Әйтик, органик гумин препараты яшелчә, чәчәк, яфраклы-декоратив культураларны, җиләк куакларын һәм җимеш агачларын, газон үләнен, бүлмә гөлләрен тамырдан һәм тамырдан тыш тукландыру өчен кулланыла.

Органик гумин препараты җитештерү технологик процессы резонаторлы җайланманың табигый гумус каустоболитына физик-механик тәэсир итү юлы белән башкарыла, барлыкка килгән наноструктуралы продукт базардагы барлык башка гумус препаратларыннан аерылып тора. Алынган продукция – бик нәтиҗәле, туендырылган ашлама, ул үсемлекләрне авырулардан да саклый, туфракны да яңарта. Аны Татарстанның кайбер районнарында куллану авыл хуҗалыгы культураларының уңышын 22–39%, орлыклар тишелеп чыгуын 7–14% арттырырга, өлгерү вакытын 7 көнгә киметергә мөмкинлек биргән.

Икътисадый нәтиҗәлелек – язгы бодай өчен тотылган өстәмә чыгымның бер сумына 18,6 сум табыш.

Икътисадый нәтиҗәлелек – кишер өчен тотылган өстәмә чыгымның бер сумына 9,2–20,2 сум табыш.

Нанотехнологияләр кулланып уйлап табылган тагын бер нәтиҗәле продукциягә мисал – органик гуминопротеин концентраты, ул авыл хуҗалыгы хайваннары рационын оптимальләштерү өчен файдаланыла, сыер, дуңгыз, бройлер, тавыкларга һәм башка кош-хайваннарга өстәмә азык буларак бирелә.

Органик гуминопротеин концентраты җитештерү технологик процессы вакытында башта биорезонанслы җайланма ярдәмендә арыш полисахаридлары атом-молекуляр дәрәҗәдә шикәрләргә таркатыла, торфның биоген элементлары 80%ка кадәр экстракцияләнә. Концентратның өстәмә компонентлары бер-бер артлы фәнни нигезләнгән нормаларда кушыла. Әлеге концентратны ашату нормасы хайванның төренә, яшенә, нәтиҗәлелегенә, рацион стуктурасына һәм организмының туклыклы һәм биологик актив матдәләр белән ничек тәэмин ителешенә бәйле һәм комбиазык яки ашлык катнашмасы массасының 10–20% тәшкил итә. Ашатыр алдыннан, ул ваклана һәм «ДОЗА» тибындагы мини-комбиазык җайланмасында җентекләп болгатыла. Продуктны хайваннарга вакламыйча да ашатырга була.

Хайваннарга органик гуминопротеин концентраты ашату түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү мөмкинлеге биргән:

• авыл хуҗалыгы хайваннарының ашау рационын барлык кирәкле туклану элементлары белән оптимальләштерү;

• бозаулаганнан соң организмның резервларын торгызу һәм матдәләр алмашын активлаштыру;

• хайваннарның продуктивлыгын 12–18%ка арттыру һәм терлек азыгына чыгымнарны 8–10%ка киметү.

Тулаем алганда, «Агронаноиндустрия» консорциумы алдарак сөйләп кителгән продуктларны, шулай ук агронаноиндустрия сферасындагы Россия һәм чит ил галимнәре уйлап тапкан башка инновацион проектларны рекламалау һәм коммерциализацияләү өчен башлангыч мәйданчык булып тора.

Әйтик, Россия галимнәре терлекчелектә һәм кошчылыкта биналардагы микроклиматны формалаштыру өчен кирәкле технологик процессларда файдаланырлык нанотехнологияләр булдырган, бу энергия күп талап итә торган вентиляция системасын һаваны электрохимик чистарту системасына алыштыру мөмкинлеге бирә, анысы исә микроклиматның барлык норматив параметрларын – температура, дымлылык, газ составы, тузанлану, һава йөрү тизлеге, төрле исләрне бетерү – тәэмин итә.

Россиядә шулай ук яшел азык силос массасын электроактив консервант белән электроконсервлау экологик нанотехнологияләре булдырылган һәм практикада кулланыла. Бу бик кыйбатлы, куркынычсызлык кагыйдәләрен катгый үтәүне таләп итә торган органик кислоталарны алыштыра. Мондый яңа нанотехнология терлек азыгының сакланучанлыгын 95%ка җиткерә. Тимер һәм башка микроэлементларның нанокисәкчекләрен, хайваннарның яшәү сәләтен һәм продуктивлыгын арттыру өчен, премикслар составына кертәләр.

Гомумән алганда, экспертлар фикеренчә, авыл хуҗалыгында (ашлык, яшелчә, үсемлек һәм терлек үстергәндә) һәм азык-төлек җитештерүләрендә нанотехнологияләр куллану ашамлыкларның өр-яңа классы – «агронанопродуктлар» тууга китерәчәк, алар тора-бара базардан геннары үзгәртелгән продуктларны кысрыклап чыгарачак.

Гомум кабул ителгән фәнни терминология буенча, «агронанопродукт» дип аталыр өчен, продуктны үстергәндә, җитештергәндә, авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәрткәндә яки төргәндә нанотехнологияләр кулланылырга яки наноүзгәртелгән продукция алынырга тиеш.

Агронанопродуктларның перспектив эшләнмәләре туклану продуктларын җитештерү һәм төрү процессын тагын да камилләштерүне, аларның тәме яхшыртылуын, яңа туклыклы үзлекләре өстәлүен вәгъдә итә, шулай ук «функциональ» продуктлар (ризыкка дарулы яки өстәмә туклыклы матдәләр кушыла) җитештерү күздә тотыла. Шулай ук җитештерүчәнлекне арттыру һәм ашамлыкларга бәяләр төшү дә фаразлана. Якындагы 15–20 елда агронанопродуктлар инде бөтен җирдә кулланылачак.

Агротехнологик эшләнмәләрнең хәзерге актуальлеген һәм аларның Россиянең бүгенге һәм киләчәктәге авыл хуҗалыгы үсешенә йогынтысын исәпкә алып, аларны гамәлгә кертүгә инвестиция күләмнәрен өстенлекле тәртиптә арттыру зарур, шул исәптән:

• авыл хуҗалыгы җитештерүе үсешенең билгеләнгән күрсәткечләренә тиз арада ирешүгә юнәлтелгән фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре тармак стратегиясен эшләүгә;

• күпсанлы Россия һәм чит ил үзәкләре, шул исәптән «Агронаноиндустрия» консорциумы һәм аның төбәк үзәкләре белән үзара хезмәттәшлекне оештыруга;

• авыл хуҗалыгын үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен, шул исәптән агронанотехнологияләрне, гамәлгә кертүне исәпкә алып, кадрлар әзерләү системасына.

Реклама

PRESSA.RU

Хәлим Җәләлов 1940 елда Балык Бистәсе районының Олы Солтан авылында туа. 1965 елдан – Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты. 1992 елда Татарстан Республикасының халык артисты исеменә лаек була. 2015 елда «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнә.

КҮК КАПУСЫ **АЧЫЛГАНДА**

«Кыяфәтең белән Аполлон түгел инде син, буең да шулкадәр генә. Димәк, кыюрак булырга кирәк!» – Камал театрының күренекле артисты Хәлим Җәләловка яшьлегендә әнә шундый үгет-нәсихәт бирелә. Әлеге кыюлык нәтиҗәсе исә – сәхнәдә, кино сәнгатендә, телевидение һәм радиода дистәләгән якты образлар, классик әдипләрнең шигырьләре һәм тәрҗемәләр.



Әзерләде:
Ольга Туманская

СӘХНӘДӘГЕ СЫНАУЛАР

Бервакыт мине Мейерхольд театры артисты белән чагыштыруга лаек дип таптылар. Бу хәл исә шактый куркыныч хатирәләр белән бәйле. Бүген дә онытмыйм, бармагым кадакка эләккән иде. Берничә көннән ул шундый шешеп чыкты, табиб кисеп ташларга карар кылды. «Сез нәрсә? – дип үтенәм аннан. – Миңа бармаксыз һич тә ярамый бит!» Шуннан табиб скальпель алды да шешне кисеп җибәрде, яхшылап чистартты, бармакны саклап калды. Һәм менә шул калын бәйләвечле бармак белән мин театрга кердем. Ә анда Мәскәүдән театр тәнкыйтьчесе килгән чак. «Әйдәгез, без сезгә «Диләфрүз»не күрсәтик», – дип тәкъдим итте аңа ул чактагы театр директоры Рәшидә Җиһаншина. Миңа да уйнарга туры килде. Ә сценарий буенча мин турникта тартылган килеш җыр җырлыйм. Нишләргә? Тешемне кыстым да турникка ябыштым... Кыскасы, булдыра алганча уйнап чыктым. Тәнкыйтьче бик канәгать калды. Миңа барлык рольләрем дә якын, ләкин «Диләфрүз»дәге Шәкүр – нәкъ минеке, иң яраткан ролем. Мин аны 600 тапкыр уйнадым. Ә 50 яшьлегемне бәйрәм иткәндә, кемдер 601 нче тапкыр уйнарга тәкъдим ясады. Һәм уйнадык та! Мин әле шунда да җырладым, турникта да бөтерелдем.

АЛАР КАЙТМАДЫ...

Сугыш елларына карамастан, балачагым хәтергә кереп калырлык булды. Уйнаган-көлгән, бәхеткә тиенгән чаклар да бар иде. Җиде бертуган, җиде малай – чып-чын коллектив ул! Авылда өстәл янында утырабыз шулай, шаярабыз. Өлкәнебез Мәхмүт абый: «Тавышланмагыз», – дип усалланып, аш чүмечен күтәреп ала. 1944 елда аңа унсигез яшь тулды. Өй янында туктаган ат арбасыннан сикереп төшкәне әле дә хәтердә. Капка янына килеп, шуның баганасын кочаклады да бер мәл тын калды... Шулай итеп сугышка китте.

Ә эти абыйдан да алданрак киткән иде. Саубуллашканда, әнигә киңәш-нәсихәтен бирде: «Без җиңеп, берәр айдан кайтырбыз! Тик син, шулай да, сыерны сатарга ашыкма». Йортта сөт булса, димәк, балалар ачтан үлмәячәк. Үл мари урманнарындагы Суслонгер укыту-өйрәтү лагерена эләгә. Бик куркыныч җир! Әтинең хәлен белергә дип, кырык градус салкында ике буханка ипи һәм бер литр спирт күтәреп, әни юлга чыгып китте. Ничек шуңа йөрәге җиткәндер? Мин моны чын геройлык дип атыйм.

Күп еллар узгач, әтинең дәфтәрен таптым. Аларда бик матур хәрефләр белән бәетләр язылган иде. Эти белемле кеше иде, гарәп телен яхшы белгән, үзлегеннән кириллицаны өйрәнгән. Алты пот авырлыктагы гәүдәле һәм шулкадәр киң күңелле! Кышкы озын кичләрдә безнең өйгә җыелган яшь тол хатыннар әтинең дәфтәрен укып елыйлар иде. Әни аларга шул бәетләрне укый иде. Мин исә бу язуларны хәзер дә бик кадерләп саклыйм.

Эти бер айдан да, сугыш беткәч тә кайтмады. Ленинград тирәсендә һәлак булган ул. Мәхмүт абый танкта янып үл-

гән. Әни безне сөеп тә, шул ук вакытта таләпчән дә булып үстерде. Ул кыска буйлы, чибәр, ләкин бик кыю холыклы иде. Тәртибем аксаса да, мәктәптә начар укымадым – унынчы сыйныфны көмеш медальгә тәмамладым. Мәктәбебез бик зур иде: халык – сабан туе кебек! Бөтен Балык Бистәсе районына бердәнбер татар мәктәбе. Анда балалар да, сугыштан кайтканнар да укыды. Бүген исә безнең ул мәктәптә, тартып-сузып санаганда, унбиш укучы җыеладыр…

БУЙ БЕЛӘН ТҮГЕЛ, КЫЮЛЫК БЕЛӘН АЛДЫРДЫМ!

Киез итек комбинатында эш, мин сиңа әйтим, җиңелләрдән түгел иде. Ул ис, ул пар! Ләкин түләве яхшы. Авыл хуҗалыгы институтының читтән торып уку бүлегенә күчкәч, мин шунда эшкә урнаштым. Механиклыкка уку һич тә күңелемә ятмады! Комбинат карамагында Вахитов исемендәге клуб бар иде. Шунда үзешчән сәнгатьтә актив катнаштым. Клубның җитәкчесе Мәсгуть Имашев миңа бик булышлык күрсәтте.

Бервакыт курсташлар белән ике айга чирәм җирләрне күтәрергә чыгып киттек. Кайтуыма өйдә язу көтә: Казанда театр училищесы ачыла! Моны миңа Имашев тапшырырга кушкан. Кабул итү имтиханнары алдыннан киңәшләрен дә бирде: «Кыяфәтең белән Аполлон түгел инде син, буең да шулкадәр генә. Димәк, кыюрак булырга кирәк!»

Беренче турга соңга кала яздым. Эштән соң иң ахыргы булып чабып килеп җиттем. Озын өстәл артында Шәүкәт Биктимеров, Рәфкать Бикчәнтәев утыра… Жюри рәисе Ширияздан Сарымсаков инде әйберләрен җыя башлаган, миңа карамый да. «Нәрсә әзерләп килдең?» – дип сорап куйды ул сүз арасында гына. «Һади Такташ хикәясе», – дидем дә шундый итеп сөйләп җибәрдем! Шундый басым белән, нәкъ Мәсгуть абый кушканча. Хәтта Сарымсаков та бермәл катып калды.

Икенче турга да иң соңгы булып, йөгерә-чаба килеп җиттем. Инде башкача каршыладылар. Имтихан ахырында сораулар да бирә башладылар, янәсе, кайда эшлисең, күпме аласың. «Без ул хәтле түләмибез», – диде Сарымсаков. «Ширияздан абый, мин бит монда акчага дип килмәдем», – дип турыдан әйттем. Мине өченче турсыз гына алдылар.

Өйгә йөгереп кайттым да абыйга кычкырам: «Бәйрәмнән нәрсәләр калды анда, чыгар барысын да – мин театральныйга укырга кердем!» Ә ул исә миннән дә катырак тавыш белән: «Әни! Ул институттан киткән!» – дип ярып салды. Бөтен гаилә белән мине әрли-тирги башладылар. Ә мин көләм генә. «Файдасы юк, әни. Бетте безнең Хәлим», – дип кенә куйды абый.

ИКӘҮ УЙНЫЙК!

«Рәхим итегез!» спектаклендә Рәфкать Бикчәнтәев мине дублеры итеп билгеләде. Ул, мине хөрмәт итеп, һәрвакыт яхшы рольләр бирә иде. Тик сәхнәгә чыгарга гына җыенам, үтенеч белән килеп җитә: «Хәлим, бүген миңа Мәскәүдән туганнар килде. Әйдә, бу юлы мин уйныйм инде…» «Әлбәттә, дим, уйнагыз». Спектакль куелган чираттагы кичтә тагын сүзката бу: «Бүген әти белән әни залда. Әйдә, мин чыгыйм әле». Һәм шулай дәвам итә килде. Рәфкать абый бик яхшы артист һәм уйнарга ярата иде.

1967 елда ул «Күк капусы ачылса» спектаклен куйды. Бикчәнтәев режиссер булгач, димәк, миңа роль бар, дип йөрим. Карыйм, исемлектә фамилиям юк! Тик безнең арада сөйләшү булачагын сизеп торам. Бер-ике көннән миңа тәкъдим белән килә – башка артист нидидер сәбәп белән баш тарткан. Сезонны шул спектакль белән ачарга планлаштыралар. Аңлашыла ки, Рәфкать абый үзе уйнаячак. Тик мин барыбер көн дә килеп йөрим, ни дисәң дә, дублер бит. Менә шул вакыт, минем бәхеткә, Рәфкать абыйны Ленинградка «Моабит дәфтәре» фильмын төшерергә чакырдылар. Ул китте, ә шуннан соң мин көн саен сәхнәдә – һай, шәп! Менә Бикчәнтәев кайтып төште, мине дә карады. Канәгать калган булса кирәк. Аның чираты иде уйнарга, шул кичне мине чакырып алды да үзе үк тәкъдим ясады: «Бүген никтер кәефем юк. Әйдә, син чык инде». Ә мин шат кына! Өч айдан ул кучмә театрга китте, һәм Гайфи бабай роле тулысынча миңа калды. Озак уйнадым мин аны – 400 тапкыр!

ХАТЫН-КЫЗ ӨЛЕШЕНӘ

«Хәлим абый, ярый әле ир-ат булып тугансыз. Югыйсә мондый кыяфәтегез белән берәү дә хатынлыкка алмас иде», – дип шаяртты яшь артистлар, мин тәүге тапкыр Пернель ханым ролендә чыгыш ясагач. Эш болай булды. Безгә «Тартюф» спектаклен куярга Франциядән бер режиссер килде. Ул бер әсәрдә уенымны күргән дә: «Миңа бу артист белән сөйләшеп алырга кирәк», – дигән. Бардым мин аның янына, сораштыра башлады бу: «Хәлләр ничек, өйдә, гаиләдә нихәл…» Кыскасы, дежур сораулар. Мин инде шомарган таш, турыдан бәреп сорадым: «Сез миңа ни әйтергә телисез?» «Мин сезгә Пернель ролен тәкъдим итәргә телим», – диде ул. «Нәрсә?! Хатын-кызнымы? Миңа?» – бу тәкъдим мине шулкадәр гаҗәпкә калдырды. «Сез мине гафу итегез инде, зинһар, – ди режиссер. – Пьесаны укып карагыз әле, ә җавапны иртәгә бирерсез».

Юлда миңа Искәндәр Хәйруллин очрады. «Хәлим абый, баш тарта күрмәгез. Роль – супер!» Пьесаны укып карадым да ризалык бирдем. Әле тагын кызык ягы да бар – эш шунда: бу рольгә безнең бер актриса билгеләнгән иде инде. Менә без коллектив белән җыелып утырабыз, һәм ул актриса шул яңалыгын хәбәр итте. Шулчак мин әйтеп салдым: «Димәк, сез мине рольсез калдыра алырлык беренче хатын-кыз буласыз». Ул аңламады да, ә башкалар көлә башлады, янәсе, ничек инде ул Җәләловның ролен алсын, ди?

Мин уйнаган Пернель ханымны мактадылар. Сере шунда: гадәттә хатын-кыз ролен башкарган ир-атлар артык кыланчыклана башлый. Ә мин – юк! Ничек күрдем, ничек тойдым, шулай уйнадым, бераз вак-төяк элементлар гына өстәп җибәрдем. Спектакльдән соң баш игәндә, бер тамашачы ханым килеп сүз катты: «Мин сезне болай да ярата идем, ә инде бу рольдән соң тагын да ныграк яраттым». Сары май булып ятты ул сүзләр.

ГОМЕР БУЕ ШИГЫРЬ БЕЛӘН

Атаклы драматургыбыз Туфан Миңнуллин киңәше белән мин тәрҗемә эшенә алынырга булдым. Бу эшне башлап җибәрү өчен миңа Александр Вампилов әсәрләре канат куйды. Аның шигъри иҗек-калыплары яхшы иде. Бик талантлы зат иде, ни кызганыч, арабыздан иртә китте. Тәрҗемә эшен А.Вампиловның «Провинция мәзәкләр»еннән башладым. Ә аннары китте, китте – «Мин – өлкән улыгыз», «Июнь аенда саубуллашу»… Режиссер Марсель Сәлимҗанов бу хакта белеп, тәрҗемәләремне үзенә күрсәтеп алырга сорады. Һәм тиздән безнең сәхнәдә «Кем соң син, метранпаж?» һәм «Фәрештә белән 20 минут» пьесалары куелды. Ә бераз соңрак китап та басылып чыкты: Вампиловның дүрт пьесасы татар телендә минем тәрҗемә белән дөнья күрде.

Аннары тагын бер фикер килде: татар халык әкиятләрен шигъри калыпка салырга ниятләдем. Сынап та карадым – уңышлы гына килеп чыкты кебек. Үземнең иҗат җимешемне талантлы шагыйрьләребез Зөлфәт (Дөлфәт Маликов. – **Ред. иск.**) һәм Мөдәррис Әгъләмгә күрсәттем. Менә шунда Зөлфәт Мөдәррискә әйтеп салмасынмы: «Ә ул булдырган бит! Минем моңа кыюлыгым җитмәс иде». Тегесе җавап урынына: «Башта – газетага, аннары – китапка», – диде. Менә шулай итеп «Шәрә бүре», «Аю белән төлке» һәм башка шигъри әкиятләрем башта «Сабантуй» балалар газетасында (ул вакытта. – **Ред. иск.**), ә аннары аерым китап рәвешендә басылып чыкты.

Күптән түгел истәлекләр китабымны әзерләп бетердем. Анда тормышыбыздагы көлкеле хәлләр, елатырлык вакыйгалар – барысы да бар.

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

PRESSA.RU



АШАГАН БЕЛМИ, ТУРАГАН БЕЛӘ...

Агымдагы елның 1 июленнән яңа закон гамәлгә керә: кибетләр, сәүдә үзәкләре касса аппаратларын Интернетка тоташтырырга тиеш. «Онлайн-касса»ның бәясе 35 меңгә кадәр. Шуңа өстәп әле компьютер, башка җиһазлар сатып алырга кирәк. Авыл кибетләрен тотучылар бу яңалыкка аяк терәп каршы. Сәбәп нидә? Бу өлкәдә тагын нинди проблемалар бар?



Автор:
Руфия Фазылова

Фотолар Ната Смирновадан һәм Интернеттан алынды



ды. Ә яңа ел башыннан авыл кибетләренә дә яңа системага күчәргә туры килде.

– 2017 ел башында спиртлы эчемлекләрне сату өчен лицензия алырга баргач, ЕГАИСка күчүне мәҗбүр итеп куйдылар, – дип сөйләде Апас районы Шәмбалыкчы авылында яшәүче шәхси эшмәкәр Фердинат Хәйруллин. – Барлык техникасын да сатып алсаң, 80 меңнән дә ким түгел икән. Бу бик кыйммәткә төшә дип, без бер ай аракы сатмадык. Әле бит лицензия алу өчен дә 50 мең сум түләргә кирәк. Ләкин бер ай эчендә болай эшләп булмаячагын аңладык: халык кибеткә йөрми башлады. Аракы алырга дип күрше авылга яки Каратунга китәләр дә бөтен товарны шуннан алып кайталар. Ничек кенә сәер яңгырамасын, аракы – халыкны кибеткә тарту җае. Шуннан ЕГАИСка кушылып, спиртлы эчемлекләр сату өчен лицензия алдык. «Онлайн-касса»ны әлегә бер елга арендага алдык. Сигез мең сумга басты. Казандагы бер оешма белән килешү төзедек. Техниканы килеп куеп киттеләр, карап торалар. Аның өчен аена ике мең сум түләп барабыз. Инде, ярар, чыгымнарына күз йомар идек, авылда Интернет начар эшли. Теләгән вакытта аракы сатып булмый. Хәзер аптырагач, кибетчеләр, Интернет тотканда, берьюлы ун шешәне «онлайн-касса» аша уздырып куялар. Ә барлык товарны да «онлайн-касса» аша уздырырга кирәк булса, нишләп бетәргә кирәк?! Апас районындагы башка шәхси эшмәкәрләр белән дә аралашабыз, аларның да Интернет белән проблемалары еш була.

Фердинат Хәйруллинның Апас районында дүрт кибете бар. Тормыш иптәше Гөлнур белән бу бизнеска кереп киткәннәренә ун еллап вакыт узган. Гөлнур апа башта райпо сәүдә үзәгендә эшләгән, ул ябылгач, ире Фердинат белән туган авыллары Шәмбалыкчыда шәхси кибет ачканнар. Дәртләнеп китеп, санаулы еллар эчендә кибет санын дүрткә җиткергәннәр. Артык баемасалар да, тормышларын алып барырга җитәрлек акча керә икән. Хәер, аның бит авылда эше дә юк, сайланып торыр чак түгел. Кем ничек булдыра ала, шулай яши.

– Безнең кибетләр зур авылларда түгел, – дип сүзгә кушылды Гөлнур Хәйруллина. – Мисал өчен Тәүгелде авылында апрельдә айлык товар әйләнеше – 140 мең сум, Югары Балтайда 120 мең сум булды. Кибетчегә түләгән хезмәт хакын, ай саен пенсия фондына күчереп бара торган акчаны, салымнар, коммуналь түләүләрне санаганнан соң, бер кибеттән чиста табыш 10 мең сумнар тирәсе кала. Кайбер айларда күбрәк тә чыга. Ул акчаларны чын мәгънәсендә эшләп аласың. ЕГАИСка кушылгач, күпме борчылганымны үзем генә беләм. Керем белән чыгым туры килми, тагын башка проблемалар. Мин менә тагын нәрсәгә гаҗәпләнәм: дәүләт барлык чыгымнарны да ни өчен эшмәкәрләр өстенә өеп калдыра? Ә ни өчен шул ук «Татспиртпром» оешмасы бу эшкә үз өлешен кертми? Без бит нигездә аларның аракысын сатабыз. Республика хөкүмәтенә бу чыгымнарны шәхси эшмәкәрләр һәм аракы җитештерүчеләр арасында тигез итеп бүлергә кирәк дип саныйм мин...

Хәйруллиннар бер мәлне чын мәгънәсендә төшенкелеккә бирелгән. Әллә эшне ташлыйк микән дип тә уйлашканнар, аннан янә түзәргә булганнар:

«ОНЛАЙН-КАССА БЕЛӘН ЭШЛИБЕЗ»

Хәер, республиканың зур сәүдә үзәкләре, кибетләр, узган елдан башлап «онлайн-режим»да эшли. Сүз ЕГАИС системасы турында бара. Хәрефләр җыелмасын татарчага тәрҗемә иткәндә болайрак яңгырый: алкоголь продукциясе базарында дәүләт контролен көчәйтүче бердәм автоматлаштырылган мәгълүмат системасы. Ягъни алкогольнең сатылган һәр шешәсе Интернет аша үзәк базага китеп бара. Узган ел кабул ителгән Федераль закон нигезендә, ЕГАИСка барлык кибетләр 2017 елның 1 июленнән күчеп бетәргә тиеш. Ләкин Татарстан, пилот төбәк буларак, инде узган ел ук спиртлы эчемлекләрне «онлайн-режим»да сата башлады. ЕГАИСка, нигездә, шәһәр, район үзәкләрендәге зур кибетләр кушыл-

PRESSA.RU

– Физик хезмәттән тыш (товарга барган көнне әйбер ташып җилкәләр, аяклар калмый), әнә шундый яңа карарлар кабул итә торалар, – ди Фердинат абый. – Мәскәү депутатлары авыл кибетләренең хәлен күрми, аңламый шул. Зур кибетләр масштабыннан фикер йөртәләр. Болай барса, ничек эшләрбез? Әлегә пенсиягә күп калмады дип түзәбез, балаларга дә ярдәм итәсе килә бит. Авыл кешесе эшсез торырга өйрәнмәгән...

«СЫЕР АСРАУ КУЛАЙРАК»

Авылда кибет тотучы тагын берничә эшмәкәр белән аралаштым, яңа тәртипләрдән барысы да зарлана. Югыйсә, закон кабул иткән депутатларның максатлары изге иде: ЕГАИСка тоташкач, кибет киштәләреннән ялган аракы юкка чыгачак. Заводта җитештерелгән һәр шешә спиртлы эчемлек базага кертелә бит. Аның кайсы кибеткә китүе, кайчан сатылуы турындагы мәгълүматны «онлайн-касса» тиешле оешмаларга (җитештерүчегә, салым инспекциясенә) җиткереп тора.

Алда әйтелгәнчә, 2017 елның 1 июленнән, Федераль закон нигезендә, Россиядә «онлайн-касса»лар файдалану барлык сату-алу өлкәләренә дә кагылачак. Азык-төлек продуктлары, көнкүреш товарлары белән сәүдә итүчеләр, җәмәгать туклану нокталары, интернет-кибетләр, халыкка хезмәт күрсәтүчеләр, исәп-хисап ясаганда яңа аппаратлардан файдаланырга тиеш булачак. Бу очракта да Дәүләт Думасы депутатлары законны бары тик яхшы нияттән кабул иткән: кибет киштәләреннән читтән кергән товарлар бетереләчәк. Үзебездә җитештерелгән сыйфатлы продукт кына ашарга тиешбез. Тик менә авыл кибетен тотучылар, бу яхшы ниятнең яман ягын күрә:

– Әгәр ике кибетемә «онлайн-касса» аппартлары сатып алып урнаштырсам, 150 мең сум чамасы акча түгәчәкмен, – ди Әтнә районында ике кибет тотучы шәхси эшмәкәр Рамил. (Аерым сәбәпләр аркасында тулы исемен күрсәтмәвемне үтенде. – **Авт.**) – Димәк, ким дигәндә, мин бер ел бушка эшләргә тиеш булам. Моның тагын икенче ягы да бар: кибетчеләрне компьютерда эшләтергә өйрәтергә кирәк. Мисал өчен бер авылдагы кибетчемә 67 яшь. «Миңа эштән китү хәерлерәк, Интернетны өйрәнеп утыра алмыйм», – ди ул.

Шуннан Рамил кулындагы дәфтәрне ачып күрсәтте:

– Менә, күз салыгыз, әҗәткә товар алган кешеләр исемлеге. Араларында 10 мең сум бурычлы кешеләр дә бар. «Онлайн-касса» булган очракта мин бу «әҗәт дәфтәре» белән нишләргә тиеш? Товар киткән, ә аның акчасы алынмаган бит әле. Кайберәүләр бурычларын еллар буе түләми. Бу мәсьәләне азагына кадәр уйлап бетерергә кирәк.

Мәсьәләгә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов ачыклык кертте: ТР Президенты каршындагы Эшкурлык буенча советның дүртенче җыенында «онлайн-касса»лар турында да сүз булды. «Шәһәр кибете белән авылныкын чагыштырып булмый. Халык саны 1 меңгә кадәр булган сала кибетләре элеккечә эшләсен. Аннан өч елдан соң күз күрер», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Бу карар шәхси кибет тотучы авыл эшмәкәрләрен җанландырып җибәрде. Республикада халык саны меңнән арткан авыллар әллә ни күп түгел. Димәк, Президентның «онлайн-касса»сыз эшләргә биргән хәер-фатихасы, нигездә, күпчелек авыл кибетләренә кагылачак. Әтнәнең шәхси эшмәкәре Рамил дә әлеге яңалыктан хәбәрдар булып чыкты:

– Бик сөендем, – диде ул. – Инде без хатыным Рузалия белән фермер булыйкмы әллә дип уйлана башлаган идек. Биш сыер асрасаң, авылда тормышны алып барырга була. Безнең болай да ике сыер бар инде. Сөт сатасың, ел саен биш бозау үстерәсең...

Кибет тоту да бер дә җиңел түгел. Алайса кайберәүләр: «Эшләмичә генә акча эшлисез», – диләр. Товарга Казанга барабыз. Хатын белән дүрттә торып китәбез. Бер ноктадан икенчесенә йөри-йөри, кайтып җиткәнче кич җитә. Икенче көнне иртүк торып шул товарларны кибетләр буенча таратасың. Әле шул арада кибетче авырып китә яки аның берәр җиргә барасы булса, эшкә үзебезгә чыгарга кирәк. Ә салымнары күпме?! Алдашмасаң бер тиен файда калмый. Дүрт кибетчем бар, шуларның икесе генә рәсми рәвештә эшли булып күренә. Төрле фондларга азрак акча түләр өчен шулай эшлим. Товар әйләнешен дә азайтып күрсәтәм. Әйтәм бит, гадел генә эшләсәң, кибетеңне ябу файдалырак...

РАЙПО КИБЕТЛӘРЕ ИСӘН

Балтач районында кибетләр саны – 150ләп. ЕГАИСка тоташу мәҗбүри булганчы район буенча 118 кибетнең спиртлы эчемлекләр сатарга лицензиясе булган. Бер ел эчендә бу сан 106 га калган. Чынлап та, бүген кечкенә авылда кибете булган шәхси эшмәкәргә аракы сату бик кыйммәткә төшә, чыгымнар керемгә караганда әллә ничә тапкырга зуррак.

– Районда 77 авыл бар, шуларның 28дә аракы сатылмый, – дип сөйләде Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Илшат Галимуллин. – Дөрес аңлагыз, мин авылларда аракы сату яклы түгел. Тик эчәм дигән кеше барыбер таба ул. Ә менә кибет хуҗасы өчен аракы сатмау табышны югалту дигән сүз. Ни өчен супермаркетлар барлыкка килде? Кеше бер кибеткә кергәч, бер җирдән бар товарны да алып чыга, психология белән бәйле бу. Сәүдә нокталары «онлайн-касса» белән эшли башлаган булса, кечкенә авыл кибетләренең күбесе ябылыр иде. Әле ярый вазгыятьне Рөстәм Нургалиевич аңлап алды. Дәүләт Думасы депутатлары зур кибетләр буенча, масштаблы фикер йөртә. Шуңа күрә алар кабул иткән карарлар авыл тормышына туры килеп бетми.

Балтач районының 16 авылында бүген кибет юк икән. Андый торак пунктларга район кулланучылар җәмгыятенең күчмә кибете (халык телендә аны «автолавка» диләр) хезмәт күрсәтә. 2014 елда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән «Татпотребсоюз» оешмасы, районнардагы кулланучылар җәмгыятьләренә 100 машина – автолавка биргән иде. Балтач районына шул вакыт 3 машина кайткан.

– Автолавкалар авылларга атнасына ике тапкыр килә, – ди Илшат Галимуллин. – Көндәлек кирәк товарлар, башка төрле ризыклар була анда. Шулай ук кибетсез авылларда шәхси эшмәкәрләр дә сату оештыра. Районда үз кибетләрен тоткан 50 гә якын эшмәкәр яши.

Районда 9 райпо кибете бар, алар нигездә «Чепья кулланучылар җәмгыяте»нә карый. Кайбер авылларда икешәр сәүдә ноктасы бар, берсе шәхси, икенчесе райпо кибете. Ә Балтачның үзендә, зуррак авылларда шәхси кибетләр әллә ничә. Ассортимент бай, бөтен нәрсә бар. Акчаң гына җитсен...

Альберт Кәримов, ТР Премьер-министры урынбасары – ТР сәнәгать һәм сәүдә министры:

– 2016 елның 15 июленнән «Акчалата һәм (яки) түләү карталары ярдәмендә исәп-хисап ясаганда контроль-касса техникасын куллану турында» 2003 елның 22 маендагы 54 номерлы Федераль Законга (алга таба – Закон) кертелгән төзәтмәләр үз көченә керде. 2017 елның 1 февраленнән ККТ теркәү яңа тәртип буенча башкарыла, ә искесе 1 июльдән гамәлдән чыгарыла. Гади итеп әйткәндә, эшмәкәрләргә сатуалу аппаратларын яңартырга туры киләчәк. Яңа законда әйтелгәнчә, ККТ теркәү, аны куллану мәсьәләләре буенча документлар әйләнешен Россия Федераль салым хезмәте сайтында шәхси кабинет аша гамәлгә ашырырга мөмкин. Җитештерелгән касса техникасының һәр экземплярын Россия ФСХ реестры исәпкә алып бара.

Шулай ук үзгәрешләр алкоголь продукциясен сатуга да кагыла. 2017 елның 31 мартыннан составында спирт булган, шул исәптән сыра, сидр, пуаре, медовуха кебек эчемлекләрне җәмәгать туклануы урыннарында ваклап сатканда да ККТ куллану мәҗбүри. Россия Федераль салым хезмәтенең ТР Идарәсе мәгълүматларына караганда, 2017 елның 1 гыйнварына 25 мең 282 салым түләүче исәпләнә. Аларда 48 мең 700 ККТ теркәлгән. Һәм бу техниканың барысы да алмаштырылырга яки модернизацияләнергә тиеш.

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе нигезендә, ТР Министрлар Кабинеты тарафыннан 2005 елның 29 декабрендә расланган 648 номерлы Карарына үзгәрешләр керә: халык саны меңнән аз булган авыл кибетләрендә ККТ кулланылмаячак. Әлегә бу проект ТР Министрлар Кабинетында ведомствоара килешү уза, аннан соң раслауга биреләчәк.

2017 елның 1 апреленә республикада 1003 торак пунктта стационар сату объекты юк. Аларга көндәлек көнкүреш товарларын 394 транспорт тәэмин итә, автомашиналарның 353е Татпотребсоюз җитештерү-сәүдә оешмасына карый.

КАИ ПЛАНЕТАСЫНА 85 ЕЛ

Безнең төп «космик» конструкторларыбыз – Сергей Королёв һәм Валентин Глушко, «Энергия» ракета йөртүчесен булдыручы Борис Губанов, Сухой Тәҗрибә-конструкторлык бюросының генераль конструкторы Михаил Симонов, РФ Хөкүмәте Рәисе (90нчы еллар башында) Иван Силаев... Алар барысы да кайчандыр КАИда укыганнар йә эшләгәннәр. Әйтергә кирәк: Казанның бу уку йорты елъязмасына исемнәре теркәлгән башка меңләгән талантлы инженерлар, конструкторлар, галимнәр кебек үк.

Быел А.Н. Туполев исемендәге Казан милли-тикшеренү техник университеты – КАИ (КМТТУ-КАИ) үзенең 85 еллыгын билгеләп үтә. Аэродинамика һәм самолёт төзү бүлекләре һәм нибары 200 студент – кайчандыр, 1932 елда, бу данлыклы вузның тарихы әнә шулай башланган. Әмма аннан соң, бездәге авиация белән ракета төзү сәнәгате кебек үк, КАИ да күз иярмәс тизлек белән үсеп китә. Нәкъ менә КАИда, Сталин «иттарткычыннан» котылган, пилотлы очышлар һәм галәмгә күтәрелү турында хыялланган Сергей Павлович Королёв эшли. Биредә Валентин Петрович Глушко илдәге беренче ракета двигательләре кафедрасына нигез сала. Ә Су-27 дип аталган күпмаксатлы дүртенче буын истребителен төзегән Михаил Петрович Симонов, КАИ дипломына ия булгач, туган вузында спорт авиациясенең конструкторлык бюросын оештырып җибәрә. Әлеге ТКБнда бөтен Советлар Союзында рекорд куйган тоташ металлдан гыйбарәт планерларны проектлыйлар.

Бүген КАИ – Россиядәге иң яхшы техник вузларның берсе. А.Н. Туполев исемендәге КМТТУ милли-тикшеренү университеты дәрәҗәсе бирелгән вузлар исемлегенә керә. Тиз арада үсеп-үзгәреп торган технологияләр вузга даими рәвештә уку программаларын камилләштерергә һәм яңа белгечлекләр ачарга мөмкинлек бирә. Лазер технологияләре, 3D-бастыру, композит материаллар белән эшләү – болар вузда актив үсеш кичерә торган замана тармакларының кайберләре генә.

КМТТУ-КАИ – ул әле суднолар төзү һәм технологияләрнең аддитив үзәге дә, шулай ук инженер модельләштерү, Siemens Инженерлык, «Тюрингия» машина төзү үзәкләре дә. Бу шулай ук «КАИ-Лазер», «КАИ-Композит», «КАИ-Квант», «КАИ-Ресурс» кебек гаҗәеп заманча технологик үзәкләр дә. Техниканың соңгы мөмкинлекләрен күздә тотып ачылган үзәкләрдә сәләтле һәм амбициоз яшьләр эшли. Алар инде бүген үк иртәгәге көннең конструкторлык һәм технологик бурычларын чишәләр.

Бүгенге эш базарында әлеге вуз чыгарылышына ихтыяҗ барлыкны исәптә тотып, шундый нәтиҗәгә килә алабыз: КАИның аудиторияләрендә һәм лабораторияләрендә бүген фән «кимерүчеләр» арасыннан, һичшиксез, яңа Королёвлар, Глушко, Симоновлар чыгар.

СҮЗ УҢАЕННАН:
2017 елда Round University Ranking (RUR)* халыкара университетлар рейтингы нәтиҗәләре буенча, КМТТУ-КАИ Россия вузлары арасында 31нче урынны биләсә, дөнья классификациясендә 639нчы булып табылды. Университетлар белем бирү һәм фәнни тикшеренүләрнең сыйфаты, интернационализация, шулай ук финанс тотрыклылыгы буенча бәяләнде. RUR-2017 рейтингында 74 илдән 763 университет катнашты.

* Раунд Юниверсити Рэнкинг.

КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК ҺӘМ УҢАЙЛЫЛЫК **СТИЛЕ**



«Техноавиа» җитештерү базасы бүгенге көндә бер аяк киеме фабрикасы һәм җиде кием тегү фабрикасыннан тора. Компаниянең филиаллары Россиянең 80нән артык шәһәрендә эшли, Казахстанда, Азәрбайҗанда, Белоруссиядә, Чехиядә, БГӘндә вәкиллекләре бар. Логистика комплекслары 9 мең кв. метр мәйданлы складны һәм автотранспорт паркын үз эченә алган.

«Техноавиа»да тегелгән «Пилот» комбинезоны.

Ә эш 1992 елда махсус авиация киемнәрен әзерләү заказын үтәүдән башланып китә. «Техноавиа» дигән исем дә әнә шуннан килеп чыга. Казан филиалы – Россиядә авиация тармагы белән эшләүчеләр арасында әйдәп баручыларның берсе. Бу, беренче чиратта, Казанда шактый күп авиация предприятиеләре тупланган булу белән дә аңлатыла: Казан вертолёт заводы, «Туполев» ГАҖ филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы, «М.П.Симонов исемендәге тәҗрибә-конструкторлык бюросы» Фәнни-җитештерү берләшмәсе АҖ, «Казан моторлар җитештерү берләшмәсе» ААҖ. Бүгенге көндә «Техноавиа» – гражданн авиациясе һәм авиапредприятиеләр персоналына очыш өчен һәм техник киемнәр җитештерүче бердәнбер сертификацияле тәэминатчы.

Авиациядә хезмәт итү кешенең сәламәтлегенә төрле производство факторлары: һава торышы (суык, кар, җил, яңгыр), күз күременең начарлыгы, агрессив мохитнең тискәре йогынтысы янау белән бәйле. Шуңа күрә кием җитештерүдә «Техноавиа» бары тик югары технологияле, су һәм май-бензин үткәрми торган, антистатик, утка бирешмәүчән, уникаль сыйфатларга ия тукымалардан гына файдалана. Һәм бу авиация киеменә генә кагылмый. Әле бит станок янындагы эшчеләр, нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәрләре, операторлар, машина йөртүчеләр, механиклар, төзүчеләр дә бар... «Техноавиа» кеше эшчәнлегенең теләсә кайсы өлкәсе өчен махсус өс һәм аяк киемнәре җитештерә. Бүгенге көндә ТРның якынча 2500 предприятиесе хезмәткәрләре компания чыгарган уңайлы һәм куркынычсыз кием белән тәэмин ителгән. Алар арасында – «Татнефть» ГАҖ, «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ, «Оргсинтез» ГАҖ, «ТАИФ-НК» ААҖ, «Ак Барс» холдинг компаниясе, «Алабуга» Махсус икътисадый зонасы һәм башкалар бар.

«Техноавиа» производствосының форма киеме.

Роман Суров, «Техноавиа-Казан» ҖЧҖнең генераль директоры:

– А.Н. Туполев ис. КНИТУ – КАИ – республикадагы иң өлкән вузларның берсе – быел ул үзенең 85 еллыгын билгеләп үтә. Хаклы рәвештә иң дәрәҗәле университетларның берсе санала, һәм безнең компаниядә, мөгаен, аның белән ничек тә булса бәйле булмаган хезмәткәр табылмастыр. Кемдер үзе шунда укыган, кемнеңдер – әти-әнисе, балалары. КАИ – ул марка, бренд, күп талантлы кешеләр һәм үз эшләренең чын профессионаллары өчен альма-матер. Һәм «Техноавиа» компаниясе коллективы бу күркәм вузны юбилее белән котларга бик шат. «Мин КАИ тәмамладым» дигән горур исем тагын күп еллар буе яңгырап торсын.

«Техноавиа»га шәхси саклану чараларын эшләү һәм кертү буенча методик үзәк вазыйфалары йөкләнгән, компания гражданн авиациясенең «Аэропорт» Ассоциациясе әгъзасы һәм Шәхси саклану чараларын эшләүчеләр, әзерләүчеләр һәм тәэминатчылар ассоциациясе (Ассоциация «СИЗ») әгъзасы булып тора. Компаниянең продукциясе гражданн авиациясе өлкәсендә махсус вәкаләтле орган тарафыннан авиапредприятие персоналларына кулланырга тәкъдим ителгән. Компания авиация-техник милек, шул исәптән һава судносы бортына да чыгарыла торган милек белән тәэмин итүче буларак сертификацияләнгән.

Казан ш., Декабристлар ур.,
203 йорт.
тел.: (843) 555-66-88, 555-61-61
e-mail: kazan@technoavia.ru

Реклама

Традицияләргә тугры калып

Владимир Гинсбург,
«Казан электротехника заводы» ГАЖ генераль директоры

2017 елда безнең предприятиегә 75 яшь тулды. Заводтагы инженер-техник хезмәткәрләрнең 80 процентка якыны данлыклы КМТТУ – КАИны тәмамлаган. Ихтимал, җиңел булмаган чорларны кичерергә нәкъ менә шул ярдәм иткәндер дә. Элеккеге кебек үк, завод хезмәтчәннәренең даими үсешкә омтылуы аның уңышлы киләчәгенә шик калдырмый.

Бүген без диңгез, җир һәм авиация билгеләнешендәге югары технологияле радиоэлектрон аппаратура һәм граждан секторы өчен югары сыйфатлы продукция чыгарабыз. Бу – «Дозор» күп зоналы стационар металл детекторлары, энергетика һәм энергия белән тәэмин итү өлкәсендәге комплекслы чишелешләр, басма платалар, металл кисү инструментлары, «Робот» мехатрон хирургия комплексы өчен модульләр. Порошок белән буяу, агач эшкәртү, өлгеләп кисү, каркаслар әзерләү, металл детекторларга сервис хезмәтләре күрсәтәбез. Заводның продукциясе күп тапкырлар федераль һәм халыкара күргәзмәләрдә билгеләп үтелде һәм ул эшлекле партнёрларыбыз арасында танылу алды.

Безнең завод өчен кадрлар үзләре һәм аларның квалификациясе һәрвакыт өстенлекле урында. 2014 елда махсуслаштырылган заманча Укыту үзәге ачтык, анда заводның иң тәҗрибәле хезмәткәрләре укыта. Ел саен бередә 700 гә якын кеше белем һәм күнекмәләр ала.

Коллективыбыз сизелерлек яшәрде, һәм без вуз чыгарылышлары, аерым алганда, КМТТУ–КАИ тәмамлаучыларга һәрвакыт ачык. Кабул итәргә һәрчак әзербез. Бүген заводта алар 200 ләп, вуз студентларының тагын бер төркеме киләчәктә эшләү өчен контракт әзерлеге үтә.

Уку йорты белән берлектә кайбер фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләрен тормышка ашырдык, эшләнмәләр тематикасы буенча уртак киңәшләшүләр алып барабыз.

КМТТУ–КАИның киләчәк чыгарылышлары да, үзләренең искиткеч соклангыч элгәрләре кебек үк, үз исемнәрен данлыклы фәнни-техник фикер казанышлары тарихына язарлар, дип ышанабыз.

«Казан электротехника заводы» ГАЖ
420054, РФ, Татарстан Республикасы,
Казан ш., Модельная ур., 19 йорт.
Тел.: (843) 278-49-25 (кабул итү бүлмәсе)
(843) 278-45-51 (кадрлар бүлеге)
office@ketz.su, market@ketz.su
office@ketz.su, market@ketz.su

Реклама

ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:
тел.: (843) 222-09-76

Махсус проектлар бүлеге:
тел.: (843) 222-06-05

Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татар язучыларыннан **КЕМ** өч сугышны кичкән

НИ ӨЧЕН без бүген дә сугыш җырларын җырлыйбыз

Озак яшәүнең сере **НИДӘ**

Кычыткан ашы **НИЧЕК** тәмле була

КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ

ӨЧ СУГЫШНЫ КИЧКӘН КАПИТАН

Автор:
Әлфия Шамова

«Алга, дошман өстенә!». Хәрби гимнастеркалы бу «егет»ләр чыгарган фронт газетасы әнә шулай аталган. Военкор «егет»ләрнең берсе – өч сугышны кичкән бердәнбер татар язучысы Афзал Шамов. «Татарстан» журналы Җиңү бәйрәме уңаеннан капитан Шамов һәм аның фронтовик дуслары узган сугыш сукмаклары буйлап йөреп кайтырга булды.

СОВЕТ ЯШЬЛӘРЕНЕҢ ЯҢАЧА ТОРМЫШЫ

Күренекле прозаик, публицист, тәрҗемәче һәм җәмәгать эшлеклесе Афзал Шамов 1901 елның 4 мартында элеккеге Казан губернасының Зөя өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Яшел Үзән районы) Татар Танае авылында дөньяга килә. Афзал исеме «иң яхшы, хөрмәткә лаек зат» дигән мәгънәгә ия. Афзал Шамов әлеге исемнең мәгънәсен гомере буена аклап яши. Эшендә дә, иҗатында да.

Кечкенәдән кул арасына кереп, хезмәтнең ни икәнен татып үсә әлеге буын балалары. Бәләкәй Афзал да, бераз исәя төшүгә, апалары, җиңгиләре белән уракка, абыйлары белән тырмага йөри. Ә тагын да үсә төшкәч, йорттагы хуҗалык эшләрендә катнаша башлый.

Алты яшендә аны авылдагы мөәзингә укырга бирәләр. Ике ел мөәзин өенә йөреп, укырга-язарга өйрәнә малай. 1914-1915 елларда ул Колабирде (хәзерге Апас районына керә) исемле рус авылында өч класслы земство мәктәбендә укый, аннары Акъегет авылындагы русча-татарча мәктәптә татарча дүрт сыйныф һәм русча өч класс тәмамлый. Бу мәктәптә шул чорның күренекле педагогларыннан берсе Фатих Сәйфи-Уфалы белем бирә. Киң карашлы мөгаллим кечкенә Афзалга зур йогынты ясый, әдәбиятка булган мәхәббәтне дә малайда ул тәрбияли.

Бөек Октябрь вакыйгаларын Афзал Шамов Казандагы «Касыймия» («Апанай») мәдрәсәсендә каршылый. Революция бу чор яшьләренә яңа тормыш вәгъдә итә. Яңа киләчәк төзергә ниятләгән Афзал Шамов та, мәдрәсәдәге укуын калдырып, совет укытучыларын әзерли торган ике айлык курсларда укый, аннары, 1918–1919 елларда Яшел Үзән районына кергән Татар Исламы һәм Апас районындагы Кошман авылларында балалар укыта. Өяздәге җәмәгать, мәдәни-агарту эшләрендә актив катнаша, әдәбият-сәнгать түгәрәкләре эшен алып бара, спектакльләр, концертлар куя. Кулына каләм алуы да әнә шул чакка туры килә. Шигырьләр, хикәяләр яза башлый ул, өяздәге тормышны яктырткан хәбәрләре «Эш» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасында даими басылып тора. Шушы басмада беренче хикәяләре дә дөнья күрә.

ҮЗ ТЕЛӘГЕ БЕЛӘН – ЯУГА

Афзал Шамовның хәрби биографиясе 1919 елда 18 яшендә башланып китә. Ул үз теләге белән Кызыл Армия сафларына баса. Башта Казандагы 15нче укчы бригадасында

Фотолар Афзал Шамовның шәхси архивыннан

кызылармеец, аннары шунда ук татар кызылармеецлары арасында укый-яза белмәүне бетерү буенча укытучы-кызылармеец булып эшли. 1920 елның башыннан Үзәк Мөселман хәрби коллегиясе сәяси бүлек мөдире Шамил Усманов тәкъдиме белән Беренче Казан мөселман пехота командалары курсларында укый. Ләкин аңа аларны тәмамларга туры килми, чөнки В.И.Ленинның «Социалистик Ватан куркыныч астында» дигән чакыруын ишетү белән үк, ул 1920 елның августында, үзе теләп, Гражданнар сугышына китә. 3 нче Киев курсант бригадасы белән башта ак поляклардан Киев шәһәрен азат итә, аннары барон фон Врангель гаскәрләренә каршы сугыша, мәшһүр Перекоп сугышларында катнаша. Фронт бетерелгәч, 1921 елның мартына чаклы Украина далаларында Махно бандаларын тар-мар итүчеләр белән бер сафта көрәшә.

Махнолыларга каршы сугышканда, курсант Афзал башта атлы разведкада хезмәт итә. Бервакыт, разведкага баргач, сугышчан иптәше украин егете Охраменко белән бергә берьюлы өч бандитны коралсызландырып тотып алып кайта. Аннары бер отрядның старшинасы булып та хезмәт итә.

ТЫНЫЧ КӨННӘР ҖЫРЧЫСЫ

1921 елның мартыннан 1922 елның августына кадәр Афзал Шамов – Татарстан Үзәк башкарма комитетының һәм Совет Халык комиссарлары советының саклау ротасы кызылармеецы. 1922–1925 елларда ул Казан дәүләт университеты рабфагында укый. Бер үк вакытта ятим балалар йортында ике ел клуб мөдире булып эшли. Шулай ук Татарстан Мәгариф комиссариаты каршындагы зурлар мәктәбендә укыта да.

1926 елда Афзал Шамов Беренче Мәскәү дәүләт университетының әдәбият һәм сәнгать факультетына укырга керә. Университетта укып кына калмый, ә педагоглык һәм иҗат эшен дә дәвам итә. РСФСР Мәгариф комиссариаты каршындагы Төрки халыклар бүлегенең укый-яза белмәүне бетерү комиссиясе әгъзасы буларак, зурлар өчен эш китаплары, мәктәп дәреслекләре, методик кулланмалар язу һәм төзүдә актив катнаша. Хикәяләр, повестьлар яза һәм Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Эшче» газетасында публицистик мәкаләләрен, очеркларын, фельетоннарын, рецензияләрен бастыра.

Мәскәүдән кайткач, Афзал Шамов 1931 елның мартыннан 1943 елның февраленә кадәр Казанда Татар дәүләт нәшриятының матур әдәбият секторында җаваплы редактор һәм өлкән редактор булып эшли.


Немец оккупантларына үлем!
АЛГА дошман өстенә
„Вперед на врага" на татарском языке
Калинин фронты кызылармеецлары газетасы
Иптәш И. В. Сталинның Т. Черчилль әфәндегә һәм Ф. Рузвельт әфәндегә, Төньяк Африкада Англия-Америка гаскәрләренең җиңүе уңае белән, тәбрик телеграммалары
Премьер-Министр ЧЕРЧИЛЛЬГӘ
Президент РУЗВЕЛЬТКА
И. СТАЛИН

Немец оккупантларына үлем!
АЛГА дошман өстенә
„Вперед на врага" на татарском языке
Калинин фронты кызылармеецлары газетасы
ССР Союзы Наркомфинының белдерүе
СССР Наркомфины А. ЗВЕРЕВ.
13 июнь, 1943 ел.
УРАМ СУГЫШЫНА ӨЙРӘНЕГЕЗ

Немец оккупантларына үлем!
Сишәмбе
15
февраль 1944 ел
№ 13 (376)
БЕЗНЕҢ ФРОНТ БАТЫРЛАРЫ
Алга дошман өстенә
„Вперед на врага" на татарском языке
Верховный Баш Командующий
ПРИКАЗЫ
Армия генералы ВАТУТИНГА

«Алга, дошман өстенә!» газетасы,
өстән аска: 1943 елның 12 мае, 1943 елның 15 июне, 1944 елның 15 феврале чыгарылышлары.



Неман елгасын кичу.

КАПИТАН ШАМОВ, ЯКИ А.ТӘҮГИЛДЕ

1943 елның 9 февралендә ул янә үзе теләп фронтка китә. Башта Калинин, аннары Беренче Балтыйк буе фронтлардагы «Алга, дошман өстенә!» газетасының хәрби корреспондент-оештыручысы булып хезмәт итә. Әйтергә кирәк, фидакарь совет язучыларының нәкъ менә шушы фронттагы язмалары сугышчыларның хәрби рухын ныгытып торган, нинди генә авыр шартларга эләкмәсеннәр, алга таба көрәшергә көч табарга булышкан.

Менә газетаның 1943 ел, 22 май саны. Бу санда Афзал Шамовның «Нәфрәт көче» исемле очеркы басыла. Ул миномёт командиры орденлы гвардия капитаны Зөфәр Асадуллин турында. Афзал Шамов турыдан-туры сугышчыларга мөрәҗәгать итә һәм аларны дошманга карата аяусыз булырга өнди, фашистларны юк итәргә чакыра: «Безнең күңелләрдә, – дип яза капитан Шамов, – бер үк вакыт нәфрәт тә, мәхәббәт тә ята. Без, искиткеч көчле сөя белгән кебек, искиткеч явыз һәм зәһәр итеп нәфрәтләнә дә беләбез. Нәфрәт көче – дошман бөҗрасын җимерә, нәфрәт көче үтә алмаслык сазлыкларны үткәрә һәм нәфрәт көче иң соңгы минутта да яшәү чишмәләрен таба. Менә совет кешесенең, совет сугышчысының йөрәгендә, аның канында шундый изге нәфрәт көче яши. Бу көч булганда, дошманны һәрвакыт җиңеп чыгып була».

Капитан А. Тәүгилденең очерклары һәм мәкаләләре газетада даими басылып бара. Язучының бу газетада чыккан материаллары болардан тыш башка имзалар белән дә бирелә. Бу хакта ул: «Фронт газеталарында басылган хәбәрләр, мәкаләләр башка имзалар белән басылган булса да, башыннан алып ахырына чаклы минем кулым белән язылган», – дип искә ала.

А. Шамов, Калинин фронтындагы орденлы татар егетләренең альбомын төзеп, фронтның сәяси идарәсенә илтеп тапшыра. Әнвәр Мамаев, Зиннәт Шәрәфетдинов һ.б. турында листовкалар да бастырып чыгара.

Беренче Балтыйк буе фронты сугышчыларының Татарстан халкына җавап хаты 1944 елның декабрендә язучы Афзал Шамов кулы белән языла.

«Алга, дошман өстенә!» газетасының татар редакциясе соңрак тулысынча Байкал – Амур хәрби округына күчерелә. Анда Чита шәһәрендә «Суворовча кысрыклау» исемле газета чыга башлый. Бу газетаның корреспондентлары Читадан башлап, Монголия далалары, соңыннан каты сугышлар белән Зур Хинган тауларын һәм Маньчжурия кырларын үтеп, Сунгари елгасының суын эчеп, Маньчжуриянең башкаласы Чанчуньга кадәр барып җиткәләр. Кытай җирләрен япон самурайларыннан азат иткәч, бу газета Хабаровск шәһәрендә 1947 елның азагына кадәр басыла.

Ватан сугышы чорындагы батырлыклары һәм әдәби иҗат өлкәсендәге фидакарь хезмәтләре өчен, А. Шамов Кызыл Йолдыз ордены, II дәрәҗә Ватан сугышы ордены Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Октябрь Революциясе ордены һәм 16 медаль белән бүләкләнә.

Сугыштан кайткач, язучы «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының редакторы, 1958–1962 елларда Язучылар берлеге идарәсе рәисе булып эшли. 1962 елның март аеннан профессиональ язучы сыйфатында әдәби иҗат белән генә шөгыльләнә.



«ФРОНТТАГЫ БЕР МАҖАРА»

«Афзал аганың хәзер дә хәтерендә: 1944 ел июньнең 30ында була бу хәл. Чалт аяз җылы көн. Шамов алгы линиядә булып, газета өчен материаллар туплагач, редакциягә кайтырга ашыга. Күңеле шат, күтәренке.

Корреспондент Шамов яңа гына азат ителгән кечкенә бер авылдан бер чакрым чамасы ераклашырга да өлгерми, кинәт аның барыр юлында, каршыда, атышлар башлана, пулемётлар тыкылдый, автомат тавышлары ишетелә, гранаталар шартлап ярыла, баш очыннан пуляләр сызгырып уза.

Капитан аптырап кала. Бу ни хәл? Нигә тылда сугышлар дәвам итә? Әллә күрше полк бераз артка калган микән? Бик ихтимал...

Ул, пулялар астында юлны дәвам иттермәскә теләп, атышларны шәбәреп үсеп торган арышлар арасында ятып үткәрмәкче була. Шундагы бер снаряд чокырыннан әйләнә-тирәне күзәтергә керешә.

Күп тә үтми, Афзал Шамов бер фрицның, арышлар арасыннан поса-поса, аңа таба йөгереп килгәнен күреп ала. Аралары ун метр чамасы калгач, капитан снаряд чокырыннан сикереп чыгып, фашистка һөҗүм итә:

– Hände hoх!* – дип кычкыра ул, гранатасын баш очында тотып.

Көтмәгәндә каршысына яшен ташыдай атылып килеп баскан совет офицерын күреп, илбасар калтырап төшә, коралын җиргә ташлап, кулларын күтәрә.

Ләкин капитан Шамов үзе дә бер мәлгә аптырап кала. Ни күзе белән күрсен, аның каршысында бер генә түгел, ә җиде немец басып тора!

Капитан засададагы иптәшләренә ут ачарга команда биргәндәй, пистолетын изәп, ярым русчалап, ярым татарчалап кычкырып җибәрә. Фашистларның барысы да кулларын күтәрәләр. Илбасарлар аңнарына килгәнче, Афзал Шамов белгән чаклы немецча аларга юлга чыгарга, әлеге кечкенә авылга таба атларга команда бирә:

– Кулларыгызны төшермәгез! Борылып карамагыз! Командамны үтәмәсәгез, шунда ук атып үтерәм.

Шулчак немецларның берсе:

– Мин русча беләм, – ди һәм совет офицерының командасын немецча төгәл кабатлый.

Илбасарлар кузгалып киткәч кенә бер төрле дә засаданың булмавын, совет офицерының ялгыз гына икәнен төшенеп алалар. Ләкин инде эш узган, кораллар ташланган, куллар күтәрелгән. Барыннан да бигрәк, бер кулына пистолетын, икенче кулына гранатасын тоткан озын буйлы, кара бөдрә чәчле офицер аларны үкчәләренә басардай булып авылга ашыктырып куып алып бара...

Журналист Касыйм Тәхауның «Әдип, хәрби журналист» исемле очеркыннан.

* Кулыңны күтәр!

ЖУРНАЛИСТ КАСЫЙМ ТӘХАУНЫҢ «ӘДИП, ХӘРБИ ЖУРНАЛИСТ» ИСЕМЛЕ ОЧЕРКЫННАН.

ИБРАЙ ДУС!

Бер ай чамасы фронтта йөреп кайттым. Бик күп кешеләр һәм вакыйгалар күрдем. Газетага шактый гына «очерклар» да яздым. «Очерк» дигән сүзне аңлы рәвештә тырнаклар эченә алам, чөнки аларның берсе дә мине канәгатьләндерми...

Дусларча сагынып, сәлам һәм хөрмәт белән, А.Шамов.
16 июль, 1943 ел.

ИБРАЙ ДУС!

Озак хат язмый торуым өчен карт капитанны гафу ит. Соңгы көннәрдә һич тә бушый алмадым. Командировкаларда булдым. Ә кайткач, үзең беләсең инде, материалларны тизрәк язып чыгарырга кирәк. Барсы да кеше имзасы белән. Үзеңнекен язарга яисә имзаңны куярлык итеп язарга вакыт та юк. Кемнәр өчен генә язмыйбыз без! Еллар үтәр, без чыгарган газета битләре саргаерлар һәм алар кыйммәтле тарихи документлар булып калырлар. Аны актарып караучылар андагы имзаларның күплегенә, аларның авыр сугыш шартларында да газетага язып торуларына гаҗәпләнерләр. Ул материалларны журналистның яисә язучының ут астыннан ничек алып чыкканын, кайвакытларда, утның басылуын көтеп, аның сәгатьләр буенча җиргә сыенып ятканны белмәсләр. Дүрт юллы хәбәр өчен, дүрт-биш мәртәбә снарядка баш игәнен, аны сәламләп түгел, ә ләгънәтләп баш игәнен уйларына да китермәсләр.
Кайчагында иркенләп үзең өчен язасы килә. Булмый. Тагын киләчәктә язармын әле, бәлки, дип, күңелеңне юатасың. Синең белән без шундый юанычларга бай идек лә соң! Аллага шөкер, хәзер дә әле мин ул юанычны капчыклап саклыйм...

Кулыңны каты итеп кысып, А.Шамов.
24 июнь, 1944 ел.

ИБРАЙ!

Син торган шәһәрне алдык без, егет. Рәхмәтеңне әйтергә онытма. Хәтта ул районда сугышларның берсендә миңа да катнашырга туры килде. Шулай килеп чыкты. Шул ук көннәрдә, икенче бер урында, хәтта җиде немецны плен алдым. Гаҗәпләнәм, Ибрай, шундый хәл булып алды. Соңыннан үзем дә гаҗәпләндем. Илтеп тапшыргач, редакциядәге иптәшләр ышанмаслар дип, справкасын да алып кайттым. Шулай булгач инде, безнең фронтка әйтә торган рәхмәтеңнең бер өлеше миңа да тия...

Кулыңны кысып, Афзал.
P.S. Торган урыныбызны бүген тагын 650 километрга алга күчерәбез. Аякларыбыз һаман саздан чыкмый инде.
8 июль, 1944 ел.

ДУСТЫМ!

Мин Германияне дә күрдем инде. Ә бу хатымны алгы кырыйда, юлбашчы әйткән дивизияләрне тукмаклап бетерү районында язам.
Орден белән котлавың өчен рәхмәт. Кызыл Йолдыз. Аны алганга шактый вакыт узып китте инде. Әгәр сине бүләкләгән булсалар, мин дә сине чын күңелдән котлыйм. Бүләкләнмәгән булсаң, бөтен күңелем белән бүләкләнүеңне телим.
Баян кем булып хезмәт итә? Яз әле аның турында. Аның күкрәге орденнар белән тулгандыр инде.
Гарифка, Кутуйга, Ярмәкигә минем иң җылы сәламнәремне тапшыр.
Кем инде син? Бик зур офицер булдыңмы? Әй, бер күрәсе иде сине! Мин шулай капитан булып килеп, карт капитан булып кайтып китәрмен дип торам. Кайту көне генә якынлашсын иде инде.
Бик җылы һәм сагынычлы сәлам белән, Афзал.
Дустым һәм дусларым, үзегезне саклагыз, газета өчен генә түгел, әдәбиятыбыз өчен дә кирәклекне исегездән чыгармагыз! Бу сезгә икенче тапкыр сугышта булучы, күпне күргән солдат киңәше.

20 декабрь, 1944 ел.

ИБРАЙ ДУС!

Өйдә 9 көн кунак булдык. Бала-чагаларны күрдек, җанкайны кочакладык. Көннәрнең үткәне сизелми дә калды. Менә хәзер яңадан юлда. Бу хатымны мин «Азат Себер» газетасы чыккан шәһәрдән (Омск. – Ред.) язам. Поезд кузгалды. Батыршин (Советлар Союзы Герое, 1938 елда Хәсән күле янындагы япон илбасарлары белән сугышта батырлык күрсәтә. – Ред.) геройлык алгына яккарак юл тотабыз...
Калу мөмкинлеге дә бар иде шикелле. Әллә ничек шунда хәрби тормыш лямкасын ахырына кадәр күтәрергә булдым. Аннары ул якларны да күрәсе килде дисәм дә ялган булмас. Кайчан күрер идек соң без аны.
Иптәшләргә – Кутуйга, Гарифка, Ярмәкигә сәлам, диген.

Кулыңны каты итеп кысып, Афзал.
24 июнь, 1945 ел.

ДУСКАЙ!

Бу юлларны мин яңа гына алынган Маньчжурия шәһәренең берсеннән язам. Бу шәһәргә без кичә төнлә килеп кердек...
Без – барлыгы бер машинада алты корреспондент. Машинабыз әлегә элемтә узелы янында туктады. Мин шуннан файдаланып, ашыгып-ашыгып кына сызгалыйм.
Мин аркасына автоматын һәм барлык кирәк-яракларын асып, ватылып, җимерелеп беткән Маньчжурия юлы буенча атлаучы, йә чәче агара-агара башлаган, йә мыегы әле сызылып кына чыгып килә торган, җил һәм кояштан янган йөзле рус содатына карыйм да таңга калам. Ул әле кичә генә Германиядә иде, ә бүген ул Тын океанга якынлашып бара. Ул ачлыкка да, сусауга да, дөньядагы барлык мохтаҗлыкларга һәм газапларга да түзә һәм аны батырларча күтәрә...
Гафу ит, мин бераз нечкәреп киттем шикелле. Нишлисең бит, дускай, картлык, картлык. Чәч инде чынлап агарып килә... Бәлки әле кайткач танымассың да...

Афзал.
19 август, 1945 ел.

PRESSA.RU

ҖАНГА ГАЗИЗ

НИ ӨЧЕН БҮГЕН ДӘ СУГЫШ ТУРЫНДАГЫ **ҖЫРЛАРНЫ ҖЫРЛЫЙБЫЗ?**

Россиялеләр репертуарында сугыш җырлары үзенчәлекле урын алып тора. Алар бөтенләй җырламый мөмкин булмаган 9 Май көнне генә җырланмый. Кайгырганда да, шатланганда да, гомумән күңел җыр-моң сораганда җырлыйлар аларны. Дуслар-туганнар табын артына җыелганда, корпоративларда, туйларда, чит илләргә сәяхәткә чыгып, кинәт кенә туган ягыңны сагынып җибәргәндә җырлыйлар.

Чит ил кешеләренең дә Бөек Ватан сугышы җырларына карата үзенчәлекле мөнәсәбәте бар: кытайлар хоры «Священная война» җырын җырлаганда каз тәннәре чыга. Ә немецларга килгәндә, алар 9 Майга гомумән җылы якларга ялга чыкмаска тырышалар, чөнки Җиңү көне уңаеннан ватандашларыбыз тарафыннан җырланган җырлар ватанпәрвәрлек хисләрен шулкадәр уяталар ки, җырчылар 70 ел эчендә дөньяның инде үзгәргәнлеген оныталар, ерак 40нчы елларга кайткандай булалар. Бер сүз белән әйткәндә, «Смуглянка», «Тёмная ночь», «Катюша» һәм башка җырлар бүгенге көнгә кадәр яши: аларны хәтерлиләр, тыңлыйлар һәм җырлыйлар.

«Татарстан» казанлылар репертуарыннан үз концертын тәзеде. Аны **protatarstan.ru** сайтында тыңларга, ә инде әлеге җырларның ни өчен безгә кадерле булулары турында журналыбызның бүгенге санында укырга була.

Фото: Виктор Бриг

«Жди меня, и я вернусь»

Эльмир Низамов, композитор:

– Музыка үзе язылган вакыт рухын чагылдыра. **Ә сугыш чоры җырлары күңелебезнең иң нечкә кылларына кагыла.** Еллар уза, кешеләр китәләр, ләкин безнең белән фотографияләр, кинохроника, сугыш турында истәлекләр һәм китаплар кала... Ләкин чорның рухын, кешеләрнең тойгыларын – ничек яшәгәнлекләрен, күңелләрендә нинди хисләр кайнаганлыгын иң тирән иттереп җырлар гына тапшыра ала. «Жди меня, и я вернусь» – минем иң яраткан җырларымның берсе.

ҖЫРНЫҢ ТАРИХЫ:

Константин Симонов «Жди меня, и я вернусь» шигырен сөйгәненә багышлап фронттан яза. Һәм башта аны бастырырга да уйламый – бик шәхси, дип уйлый. Шулай да 1941 елның 9 декабрендә аны радиоэфирда укый. Аннан соң «На штурм» һәм «Красная звезда» газеталарында бастырырга тырышып карый: икесендә баш тарталар: «интим-лирик түгел, героик шигырь кирәк». Ә менә «Правда» газетасы редакциясендә икенче төрле уйлыйлар һәм 1942 елның 14 гыйнварында өченче полосада бастыралар. Мәскәүгә каршы һөҗүм вакытында. Һәм ул солдатлар арасында шунда ук популярга әйләнә. Сугыш вакытында госпитальләрдә табиб булып эшләгән Слава Менделеевна Бескина яралары аеруча каты сызлаганда солдатларның әфсен кебек «Жди меня» шигырен яттан сөйләүләрен искә алып сөйли. Сызлауларны басарга, яраларны онытып торырга ярдәм итә әлеге шигырь аларга.

«Жди меня» шигыренә көйне профессиональ композиторлар да, һәвәскәрләр дә яза. Иң киң таралганы Блантер көе. 1943 елда шигырь Авраам Шлёнский тарафыннан яһүд теленә тәрҗемә ителә, Соломон Дойчер аны музыкага сала. Шулай ук украин телендәге вариант һәм төрек теленә өч тәрҗемәсе бар.

Фото: Ната Смирнова

«За дальнею околицей»

Венера Ганеева, җырчы:

– Мин сугыштан соң туган кеше, әмма минем буын югалтуларның, җиңүнең нәрсә икәнлеген һәм нинди корбаннар хисабына яулануын белә. Без Туган илгә мәхәббәт рухында тәрбияләндек. Сугыш җырларын яратып җырлыйбыз, чөнки сугышта булганнарга дөньяга килүебез белән бурычлы. **Бу көйләр һәм сүзләр безне игелеклерәк һәм сабыррак итә.** Әлеге җырларыбыз аша геройларга – әби-бабайларыбызга үзебезнең ихтирамыбызны да белдерәбез. Сугыш җырлары иҗатымда лейтмотив булып бара. Репертуарымда Будашкинның «За дальнею околицей» кебек яраткан җырым бар. Нинди матур көй һәм сүзләр. Хатыннар һәм кызлар сөйгәннәрен басу капкасына кадәр озатканнар, шунда вәгъдәләр бирешкәннәр... Әлеге җыр беренче мәртәбә 1942 елның кышында фашист камалышында калган Ленинградта яңгырый.

Мин укыта торган мәдәният институтының җыр кафедрасы сугыш җырлары тупланган «С песней победили» дип аталган хрестоматия төзеп, март аенда үткәрелгән «Сандугач» конкурсы кысаларында һәр студентка әлеге китапны тапшырды. Бу җырларда халкыбызның күңел халәте чагылыш таба.

ҖЫРНЫҢ ТАРИХЫ:

Җыр 1940 елда, әле сугыш башланганчы ук языла. Ләкин сугыш башлангач кына популярлашып китә: шигырь авторы Глеб Акулов инде һәлак була (1941 елның июнендә, фронтта). 1942 елда композитор Николай Будашкин әлеге җырны, үзенең башка җырлары белән бергә, камалыштагы Ленинградны саклаган моряклар һәм солдатлар каршында чыгыш ясаучы Балтыйк фронты оркестрына тәкъдим итә. Һәм беренче чыгышлардан соң ук, сөйгәне белән саубуллашу, тиздән очрашуга өметләнү турындагы әлеге лирик җыр кешеләргә бик тансык булып чыга. Җыр тиз арада бөтен җиргә тарала, бигрәк тә Ленинград эстрада җырчысы Зоя Рождественская тарафыннан грампластинкага яздырылганнан соң.

PRESSA.RU

ҖАНГА ГАЗИЗ

«КАТЮША»

Фәнис Җиһаншин,
Г. Камал исемендәге театр актёры:

– Сугыш җырлары – ул хәтер. Аларда тарих яши – хәтта безгә туганнарыбыз сөйләмәгән тарих та.

«Мөхәммәтша, Мөхәммәтша, синең аягың юк бит!» – дип кычкырганнар минем бабама аягын снаряд өзгәнен күргән иптәшләре. Һәм мин бүген аның шушы хәлендә немецларга каршы атакага күтәрелгәнен күз алдына да китерә алмыйм. Ә аннан соң – госпиталь, туган авылга әйләнеп кайту. Ләкин мин аның кайчан да булса сугыш һәм үзенең батырлыклары турында сөйләгәнен хәтерләмим. Шулай берни сөйләмичә арабыздан китеп тә барды.

Сугыш җырлары мәңгелек – кешелек дөньясы яшәгәндә алар яшәячәк. Ә ул яшәсен өчен, тыныч вакытларда да сугышның нәрсә икәнлеген онытмаска кирәк. Без бу җырларны тыңлыйбыз, алар туган илгә карата горурлык хисләре уята, яхшылыкның яманлыкны җиңүен исбатлый.

ЖЫРНЫҢ ТАРИХЫ:

Атаклы «Катюша» 1938 елда языла. Шагыйрь Михаил Исаковский һәм композитор Матвей Блантерның иҗади көчләре нәтиҗәсендә гасырларга җитәрлек хит туа. Җырны беренче тапкыр джаз-оркестр солисткасы Валентина Батищева башкара. Җиңел, тиз истә кала торган көй халык арасында бик тиз тарала. Берничә елдан соң, әлеге матур хатын-кыз исеме белән Бөек Ватан сугышы вакытында гитлерчыларның котын алган сугышчан установкаларны атап йөртәчәкләр. Аларга шулай ук әлеге исемне соңрак бирәләр.

«Катюша» сугышчан рухны күтәргән, солдатларда җиңүгә өмет һәм ышаныч уяткан. Хәтта дошманнар да тыңлап, «рухланганнар», дип сөйлиләр. Тикшеренүчеләрнең исәпләүләренә караганда, «Катюша»ның ике дистәдән дә ким булмаган сандагы фронт, цензурага туры килеп бетмәгән вариантлары бар.

«СИНИЙ ПЛАТОЧЕК»

Лидия Әхмәтова,
ТР Филармония
джаз-оркестры җитәкчесе:

– Сугыш турындагы җырларны җырлаганда, без ул вакытларда барган вакыйгаларда катнашкандай булабыз. Әлеге җырларда дәһшәтле һәм бөек вакыйгалар турындагы хәтер, чын батырлык каһарманнары, авыр бәрелешләр һәм көтеп алган җиңү турындагы истәлекләр мәңгеләштерелгән. Әлеге җырлар тарихыбыз битләренә канлы юллар белән язылган, аларны җырлаганда патриотик хисләр уяна. **Алар безне Ватаныбызга, Туган илебезгә мәхәббәт аша берләштерәләр.** Бу бөек җырлар. Аларны җырларга кирәк!

ЖЫРНЫҢ ТАРИХЫ:

Әлеге җыр ике тапкыр языла. 1939 елда Советлар Союзына Польшадан «Голубой джаз» дип аталган популяр эстрада коллективы килә. Концертларның берсенә шагыйрь Я.М.Галицкий да бара. Бер импровизация аңа бигрәк тә ошый. Һәм ул шунда ук көйгә зәңгәр яулык турындагы сүзләр иҗат итә. Концерттан соң шагыйрь композиторга үзе язган шигырь юлларын күрсәтә, һәм берничә көннән «Голубой джаз» башкаруында беренче мәртәбә «Синий платочек» җыры яңгырый. Җыр-

«НА СОЛНЕЧНОЙ ПОЛЯНОЧКЕ»

Артём Силкин,
«Свияжск утрау-шәһәре»
музей-тыюлыгы директоры:

– Сугыш – халык язмышында аның холкын, тарихын ярып салган, кешенең чын йөзен ачкан вакыйгаларның берсе. Кеше күңеленең кристаллашуы, Ватанга мәхәббәт һәм, киресенчә, бәлки, кемдәдер – аны яратмау кебек тәшенчәләр калкып чыга. Әлбәттә, алар барысы да шул чорда иң заманча булган фольклор җырларында да, сугыш җырларында да чагылыш таба. **Әлеге җырларда халык күңелен биләгән борчу-газаплар, күпмилләтле Россия халкының характерын сыйфатлаган кичерешләр күренә. Аларны җырламый мөмкин түгел!**



ЖЫРНЫҢ ТАРИХЫ:

1942 елның җәендә композитор Василий Соловьёв-Седой шагыйрь Алексей Фатьянов белән таныша. «Ул вакытта әлеге егетнең минем язмышыма мәңгегә килеп керәсе турында бөтенләй башыма килмәде, – дип яза соңрак Соловьёв-Седой. – Икенче көнне үк ул миңа инидидер амбар кенәгәсеннән ертып алынган кәгазь битенә бик тырышып язылган шигырен китерде. Ул шунда ук минем бөтен күңелемне биләп алды. Шигырь җырлап тора, аңа көй салынган иде». Тиздән Фатьяновның «На солнечной поляночке» шигыре «За Родину!» армия өлкә газетасында дөнья күрә. Композиторның соклануына битараф кал-

Фото: Ната Смирнова

ның фронттагы вариантын Клавдия Шульженко башкара. Сүзләрнең фронт варианты 1942 елда Волхов фронты 54нче армиянең «В решающий бой!» газетасының әдәби хезмәткәре Михаил Максимов тарафыннан языла.

«Әле дә исемдә, газетабыз мөхәррире әлеге шигырьне Шульженко концерты турындагы отчет белән бергә бастыру турындагы тәкъдимемә каршы сүз әйтмәслек катгый тон белән болай диде: «Сез нәрсә, лейтенант? Нинди зәңгәр яулыклар турында сүз булырга мөмкин? Тирә-юньдә – сугыш, үлем, хәрабәләр...», – дип искә ала күп еллар узгач Михаил Александрович. – Бу сөйләшү турында яңа гына «За Родину! дип аталган дивизия газетасына мөхәррир итеп билгеләнү алган җаваплы секретаребыз Александр Львович Плющ ишеткән. «Әйдә, – ди ул миңа саубуллашканда, – бир шигыреңне. Мин аны үз газетамда бастырам... Аның өчен төшермәсләр әле...»

Җыр басылып чыга, бигрәк тә пулемётчылар ярата аны: «Строчит пулемётчик за синий платочек...»

ган цензура әсәрне кире кага. Фронтлардагы гаять авыр хәлләр фонында Фатьяновның шигырен артык лирик һәм җиңел дип табалар. 1943 елда Соловьёв-Седой «Тальяночка» (сугыш вакытында җыр шулай дип атала) өчен вальс көен яза, ләкин ул композиторның үзенә ошап бетми, һәм без белгән яңа музыка иҗат ителә. Ленинград җырчысы Ефрем Флак башкаруында җыр халык арасына тиз тарала. Кайбер фронт газеталарына «На солнечной поляночке» дигән рубрикалар пәйда була. Анда сугышчыларның кыска ял сәгатьләрен ничек үткәрүләре, сөйгәннәреннән алынган хатлар турында мәкаләләр урнаштырыла.

Әлеге җырларда халык күңелен биләгән борчу-газаплар, күпмилләтле Россия халкының характерын сыйфатлаган кичерешләр күренә. Аларны җырламый мөмкин түгел!

«Татарстан» казанлылар репертуарыннан үз концертын тәкъдим итә. Аны **protatarstan.ru** сайтында тыңларга була.

«В ЛЕСУ ПРИФРОНТОВОМ»

Александр Латышев, «Республика Татарстан» газетасының баш мөхәррире:

– Сугыш җырлары арасында иң яратканнарымның берсе – «В лесу прифронтовом». Кайчандыр андагы бер юл мине тетрәндерде: «Если придётся в землю лечь, так это ж только раз». Җиңел вальс мотивы һәм бу сүзләр – могаен, алар үлем белән бер генә мәртәбә очрашмаган сугышчыларны тынычландырганнардыр, үлемнән курыкмаска өйрәткәннәрдер.

Бу сүзләр минем күңелемә кереп калдылар. **Фронт җырлары хисләр иң кискен, тормышны, тынычлыкны яисә сугышны кабул итү иң югары дәрәҗәдә булган вакытта – экстремаль шартларда язылган булып чыга. Шуңа күрә аларны тыңлаганда күңелләр айкала да.** Сугыш елларында куелган планкага тыныч вакытта ирешеп булмыйдыр. Ул җырлар әле бүген дә бик эмоциональ, җылы кабул ителәләр. Әгәр инде сугыш вакытында пычрак окопларда якты тормыш турында җырлар иҗат ителгән икән, алар чын йөрәктән, ихлас күңелдән чыккан, формаль булмаган, шуңа да бар кешегә ошаган. Шуңа күрә без аларны бүген дә яратабыз.

ҖЫРНЫҢ ТАРИХЫ:

«Әлеге җырга сүзләр Кама буенда, Чистай шәһәрендә, сугышның икенче елында язылды, – дип сөйли шагыйрь Исаковский. – Язганда күз алдыма аз гына көзге төсләр иңә башлаган урманны, әле генә яудан чыккан солдат өчен гадәти булмаган, хәтта гармун тавышы да бозарга җөрьәт итмәгән тынлыкны күз алдына китердем... Шигыремне күптәнге иптәшем – композитор Михаил Блантерга юлладым, берничә ай үткәннән соң, җырны радиодан Ефрем Флак башкаруындагы ишеттем».

Блантер җыр өчен вальс көен сайлый. «Без сугыш вакытында язган лирик җырларда, – дип искә төшерә Блантер, – солдатка әллә ничә чакрым ераклыкта, тирән тылда яшәгән якыннары белән «аралашырга», иң яшерен хисләрен белдерергә, аларны сөйгән кызына, хәләшенә, хатынына җиткерергә мөмкинлек бирергә тели идек».

PRESSA.RU

ОНЫТЫРЛЫК ТҮГЕЛ БЕР ГОМЕР

Яшел Үзән районы Юынчы авылында яшәүче Төхвәтуллина Хәлимә әбигә март аенда 100 яшь тулган. Язмыш йомгагын сүткәндә кызыклы да, кызганыч та хикәятләре күп аның. Ә иң аянычлысы – Бөек Ватан сугышы белән бәйле. Ирен сугышка озатып, күкрәк баласы белән санаулы айлар эчендә тол кала. Дөньялар тынычланганнан соң, янәдән сугыштан исән-имин кайткан егеткә кияүгә чыга.

Автор:
Руфия Фазылова

«САБЫР БУЛДЫ»

Юынчы – зур авыл түгел, 170 кеше яши, 66 хуҗалык бар биредә. Хәлимә әбинең йорты гаҗәеп гүзәл җиргә урнашкан. Тәрәзәләре биек тауга карап тора, һәм алар кул сузымында гына. Тау итәгендә кечкенә елга ага. Бу сихри матурлыкка сокланып шактый басып тордык: әбинең озак яшәү серендә шушы биниһая тауларның да өлеше бардыр сыман тоелды.

– Әни бик көтә, күптән киенеп куйды, әйдәгез өйгә, – дип, капка төбенә үк чыгып каршы алды безне Хәлимә әбинең килене Сания апа.

Йөзьяшәр әбиләр турында шактый язарга туры килде. Хәлимә апа алар арасыннан иң яшедер, мөгаен. Җыйнак гәүдәле, якты йөзле. Иң мөһиме – колагы бик яхшы ишетә, күзе күрә, сөйләме анык.

– Юлның ни икәнен беләм, башта чәй эчеп алыгыз, – дип, Хәлимә әби безне өстәл янына чакырды.

Табын артына килеп утыргач, кайдан килүебез белән кызыксынды: «Казанда яшәп минем турында каян белдегез?» – дип тә гаҗәпләнеп куйды. Аннан, сорау биргәнне дә көтмичә, сөйләп китте:

– Бәхетле яшәдем мин. Кызларым гына түгел, ир малайларым да яхшы булды. Кешенекеләр белән чагыштырам да шулай дип нәтиҗә ясыйм. Киленем белән яшибез. Күп инде. Акыллы булды Сания, Аллага шөкер. Исән генә булсын.

Шулай диде дә Хәлимә әби килененең иң башыннан сөеп куйды. Бер түбә астында килен белән каенана булып гомер итүләренә 44 ел тулган икән. Бүген алар төп нигездә икәү генә яшиләр. Сания апаның ире 2012 елда кинәт кенә йөрәге туктап вафат булган.

– Ирем Рифкать 1949 елгы, каенанамның икенче иреннән беренче улы, – дип сөйләде Сания апа. – Әни күп вакыт Рифкатьнең үлгәнлеген оныта. Күрәсең, баш мие начар мәгълүматны истә калдырмый. Мин елый башласам: «Әллә кайчан үлгәннәргә елап утырма», – дип куя. Югыйсә, иремне югалткан вакытларда әни бик зур юаныч булды. «Сабыр бул, дин дә шулай куша», – дип әйтә иде. Шулай ук чәчәк кебек кызыбыз Алинәбезне җирләгәч тә, тормышка кайтаручыбыз ул булды. Төпчек кызыбыз 2003 елда, институтның 4нче курсын тәмамлагач вафат булды, кан тамырлары шартлаган, диделәр. Ул көннәрдә ниләр кичергәнебезне сөйләп аңлата торган гына түгел. Ирем дә шул хәсрәттән бакыйлыкка күчте, дип уйлыйм. Аны искә алмаган көне, сәгате юк иде. Ә әни кайгырганын безгә бик сиздермәде. Юкса аның да елап утырганын еш күрә идек. Балаларны ул үстерде бит. Алинәбезгә багышлап әни бәет чыгарган, ул аны безгә соңрак күрсәтте. Шуны азагына кадәр һаман да укып чыга алмыйм, күз яшьләренә буылам. Каенанам авылда шактый еллар остабикә булып йөрде. Күрәсең, дин гыйлемен белгәнгә, Алинә вафатыннан соң безнең кебек бәргәләнмәде, сабыр булды.

«ИРЛӘР ЙОРТКА КЕРДЕ»

Сугыш бик күп язмышларны үзенчә хәл итә, йөзьяшәр әбинең дә тормышын астын-өскә китерә. Хәлимә апа да 1939 елда Юынчы авылы егете Мөхәммәтханга кияүгә чыга. Яшь пар Мәскәү шәһәренә яшәргә китә. 1940 елда аларның кызлары туа, Сания дип исем кушалар. Тик яшьләрнең бәхетләре озакка бармый, сугыш башлана. Хәлимә әбинең тормыш иптәшен сугышка алалар, ә үзе сигез айлык кызчыгын бишмәт эченә кыстырып, туган авылына кайтып китә. Хәлимә әби йөрәгенә мәңге уелып калган аерым вакыйгаларны сөйләүне дәвам итте:

– Юынчыга товар поездында өч тәүлек кайттык. Салкын иде, Санияне куенымнан чыгармадым. Мәскәүдә калсак, ачка үләсе идек. Кемгә кирәк без анда? Авылда ичмаса әти-әни, туганнар бар. Әле ярый кайтылган. Сугыш озак барды бит. Безнекеләр тиз арада җиңәр, дип уйлаган идек, булмады. Никадәр кеше кырылды. Минем ике абыем сугышта һәлак булды. Мөхәммәтхан да кайтмады. Берничә хаты килде дә бетте. Билгесез югалган, диделәр.

Хәлимә апа туган авылына кайткач, яшелчә бригадиры булып эшли. Ул якларда күп итеп кәбестә үстерәләр, шунда хезмәт куя. Күкрәк баласы булгач, аны окоп казырга җибәрмиләр. Ул елларда Юынчының яшь кызлары, хатыннары Кайбыч районының Подберезье авылына окоп казырга китә.

Шулай итеп, Хәлимә апа сугыш елларын әти-әнисе янында уздыра. Ә аннан янә кияүгә чыга:

– Әни каенатам Мөхәммәткә 1948 елда кияүгә чыга, – дип сөйләде Сания апа. – Әти дә Юынчы авылы егете була, иң кызыгы – алар сугышка кадәр очрашып йөргән. Ләкин ни өчендер әни Мөхәммәтхан исемле икенче егеткә кияүгә чыккан. Язмыштан узмыш юк шул, әти сугыштан исән-имин әйләнеп кайткач, баласы булуга карамастан, әнине кияүгә ала. Элегрәк сөйли торган иде: әти, әллә әнине эзләп, әллә эшкә дип, Мәскәүгә барган: «Ни өчен мине калдырып кияүгә чыктың? Мин сине һаман да яратам бит», – дигән. Әти әнине бик хөрмәтләп яшәде, алты балага җан биреп, олы тормышка аяк бастырдылар.

Килене сөйләгәннәрне Хәлимә әби елмаеп тыңлап торды. Аннан:

– Мөхәммәт мине гомере буе яратты. Яратып яшәргә кирәк, тормыш матур була, – дип өстәп тә куйды.

– Чынлап та яраткандыр, сугыштан соң баласыз, кияүгә чыкмаган хатын-кызлар да күп булган. Мөхәммәт абый Хәлимә апаны сайлаган, – дим.

– Безнең авылда ул чорда сугыштан кайткан шактый ир-атлар тол хатыннарга йортка кергән, – диде Сания апа. – Өчәр баласы белән кияүгә алганнар. Тормышлар авыр, ир-атлар-

Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU

Хәлимә әби килене Сания, оныгы Рузилә белән.

ның сәламәтлекләре дә шулкадәр генә булган. Күрәсең, көйләнгән тормышка барып керүе җиңелрәк тоелгандыр.

Мөхәммәт абый сугышка 1942 елның 13 мартында китә. Атучы булып Керзон линияләрендә хезмәт итә. Берничә тапкыр яралана да. Тәнендәге ядрә кыйпылчыклары гомере буе үзен сиздерә. Мөхәммәт Төхвәтуллин батырлыклары өчен «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнә. Туган ягына исә сугыш тәмамлангач кына кайта. Башта колхозда эшли, бригадир да була.

Болар турында күбрәк Сания апа сөйләде, чөнки Хәлимә әби кайбер истәлекләрне инде онытткан. Йөзьяшәр әбинең хәтере әле соңгы бер-ике елда гына шулай начарланган. Гомер-гомергә ул авылның «аяклы» энциклопедиясе саналган. Әллә ничә газет-журналга язылып, бер хәрефен дә калдырмыйча укып барган.

«БЕЗ АННАН КУРКА ИДЕК»

– Әти белән әни бик аңлашып яшәде, – дип, сүзен дәвам итте Сания апа. – Сугыш тәмамлангач, әни 25 ел авыл кибетендә эшләде. Товарны ат белән ташыган. Әнигә булышырга дип, әти дә гел кибеткә барган. Әле мин белгәндә дә шулай булды.

Сүзнең ире турында барганлыгын ишетеп, Хәлимә әби җыр сузып җибәрде:

«Онытырлык ярым түгел,
Утларга салсалар да...
Януларым, көюләрем,
Гел синең өчен генә...»

– Әни җырларга ярата, – дип елмайды Сания апа. – Клуб сәхнәләрендә дә чыгыш ясады. Кая барса да, мәҗлес күрке иде. Үзен дә гел тәртиптә тотты, матур, пөхтә киенеп йөрде. Әле остабикә булып йөргәндә, ашларга барганда, бер кесәсендә – иннек, икенчесендә хушбуй йөртте.

Хәлимә әби килене сөйләгәннәрне канәгать бер елмаю белән тыңлап утырды. Аннан:

– Рузилә дә килә дидең, күренми, – дип куйды.

Рузилә – Сания апаның олы кызы. Гаиләсе белән күрше Бакырчы авылында яши. Көн саен диярлек әбисе белән әнисенең хәлен белә икән. Чынлап та, онык озак көттермәде, елмаеп-балкып Рузилә килеп керде. Хәлимә әбинең йөзе тагын да яктырып китте:

– Безне әби үстерде, – диде Рузилә. – Безне генә түгел, минем өч баламны да карады ул. Әбигә сиксән яшь вакытта, мин алты айлык улымны аңа калдырып, укырга киттем. Читтән торып Казан дәүләт педагогика университетында белем алдым. Әбиебез өч атна буе баланы карады. Ул вакытта әти-әни эшли иде әле.

– Хәлимә әби сезгә карата нинди булды: таләпчәнме, юашмы?

– Әти-әнигә караганда, без әбидән курка идек. Шул ук вакытта иң яшерен серләрне дә аның белән бүлештек. Акыллы усал булды ул. Әнидәй күреп яратабыз үзен.

– Кызлар клубта озаграк торса, төнлә урамга чыгып китә иде, – дип сүзгә кушылды Сания апа. – Кирәк икән, клубына да бара. Әле безне әрли: «Кызлар кайтмаган, сез йоклап ятасыз». Әни булгач, без ышанган: балалар да тәрбиядә, өйдә дә барысы тәртип.

– Хәзерге дәү әни, дәү әтиләрдә кырыслык юк, – ди Рузилә. – Мин үзем дә балалар белән эшлим, Бакырчы мәктәбендә рус теле, әдәбияты укытам. Өлкәннәр бүген оныкларын күбрәк иркәли. Нәтиҗәдә, дәү әни белән дәү әтигә хөрмәт бик булмый. Безнең әби исә кирәк чагында иркәли дә, кирәк чагында сүгә дә белде.

СЕБЕР ЮЛЫ

Хәлимә әбинең акылы камил, тик хәтере генә ялгышып куя. Менә без сораштыра башлагач та, мәрхүм Мөхәммәт абый, сугыш башлангач, Мәскәүдән күчеп кайтулары турында әйбәт кенә бәян итте. Ә Юынчы авылы турында сораштыра башлагач:

– Онытылган инде, балалар. Әллә кайчан булган, – дип куйды.

Сания апа телефоннан Гөлсинә апа Борһанованы чакырып алды. 2010 елга кадәр Юынчы төп белем бирү мәктәбенең директоры булган бу ханым авыл турында шактый мәгълүмат җиткерде:

– Юынчының тагын бер исеме – Сөнчәле. Тирә-якта чуваш авыллары күп. Безнең авылга да чуваш кешеләре нигез салган диләр. Сөнчәле – «чунь-чуле» чуваш теленнән «богау юлы» дигәнне аңлата. Рәсми чыганакларга караганда, безнең авылдан ерак түгел Себер юлы узган. Бу турыда Каюм Насыйри да истәлекләрендә яза. Шушы юлдан төрле кешеләр йөргән, араларында угрылар, юлбасарлар да булган. Күрәсең, алар начар ниятле әлеге адәмнәрдән качып, авылны ташлап киткән. 17нче йөз урталарында авылга татарлар килеп утырган. Мәрхүм әтием шулай сөйли иде. Ул авылга беренче мәчет салдырган кеше.

Акрын-акрын авыл бетеп бара. Үзебез артыннан йөри торгач, тугызъеллык мәктәп ачтырган идек. 2011 елда ябылды ул, хәтта башлангыч сыйныфлар да калмады. Ә безнең балалар Акъегет мәктәбенә йөреп белем ала.

– Әйе, мәктәп бетте, –дип көрсенеп куйды Хәлимә әби. – Сания дә укытучы иде бит, авылда мәктәптә укытты.

– Без пенсиядә инде, ярар, – диде Сания апа. – Ә менә авылда мәктәп ябылу кызганыч. Оптимизация дигән әйбер авылларны бетерүгә тагын бер сәбәп. Мәктәбе дә булмагач, яшьләр нишләсен монда?

Гөлсинә апа әңгәмәне җанландырып җибәрде:

– Хәлимә апа, син бер өер бүреләрне җиңгән кеше бит, сөйлә әле, – диде.

– Тимәде алар. Күзгә озак кына карап тордылар да китеп бардылар.

Баксаң, күп еллар элек йөзьяшәр әбигә бүре өере очраган. Кичке якта ат белән товар алып кайта торган чагы булган. Ат, бүреләрне күргәч, туктап калып, урыныннан китмичә, кешнәп торган. Хәлимә әби үзе бу турыда: «Бүреләр: «Өйдә кечкенә алты баласы кала, тимик без бу хатынга», – дип уйлаштылар ахры, алар кайбер кешеләргә караганда мәрхәмәтлерәк», – дип сөйләгән.

Хәлимә әбинең йөз яшьлек юбилеена, район администрациясеннән котлаулар килмәсә дә, үзенең исән 5 баласы (ике улы мәрхүм булган инде), 14 оныгы, 20 оныкчыгы, оныкчыкның 1 баласы (бишенче буын була!) җыелышып кайткан. Гөр килеп мәҗлес ясаганнар, видеосын да карап алдык. Мин менә нәрсәгә игътибар иттем: әби һәрчак изге теләк теле – һәркемгә дә. Йөз яшенә җитеп, саф акыл, сәламәтлек белән матур картлык кичерүенең сере менә шунда түгелме икән?!



Юынчыдан Бөек Ватан сугышына 200 кеше киткән. Шуларның 98е яу кырында һәлак булган.



«ТАТАРСТАН»
МАХСУС
журналы өчен
Журнал
ТАТАРСТАН
Обращение
к народам всего мира
Татарстан

ҮЛӘННӘР
ПАТШАСЫННАН АШ

Бу кадәр файдалы матдәләр башка бер үсемлектә дә юк. Анда кишергә караганда бета-каротин – ике, ә С витамины лимонга караганда өч тапкырга күбрәк. Шулай ук К витамины чыганагы да булып тора. Ул бик сирәк яшелчәләрдә генә бар. Әлеге тылсымлы үсемлекнең исеме – кычыткан, дөресрәге, май кычытканы. Табиблар сезон вакытында аны, кимендә, өч-дүрт тапкыр ашарга киңәш итә. Шулай итеп, бу юлы файдалы, «үләннәр патшасы» булган кычытканнан аш пешерәбез.

Автор:
Руфия Фазылова

«ЯКШӘМБЕНЕ КӨТЕП АЛАЛАР»

Кычыткан ашы пешерергә дип Казан шәһәренең 4 нче интернат-мәктәбенә юл тоттык. Билгеле сәбәпләр аркасында мәктәп менюсында кычыткан ашы юк, әлбәттә, шулай да баш пешекче Хәтимә Вәлитова бу ризыкны май аенда кайбер балаларга пешергәли икән.

4нче интернат-мәктәптә физик мөмкинлекләре чикле, төгәлрәк әйтсәм, церебраль паралич диагнозы куелган малай-кызлар укый. Ашханәгә кергәнче, Хәтимә апа ак халат белән башлык бирде. Мәктәп ашханәсе бит, пешерү ягына теләсә кем керергә тиеш түгел.

– Сез килгәнче тавык шулпасын әзерләп куйдым, – дип елмайды ул. – Сезгә бүген ике төрле кычыткан ашы пешерәм, кайсын ошатырсыз. Мин үзем һәрвакыт май аенда кычыткан ашы пешерәм. Элек «Геркулес» белән әзерли идем, соңгы вакытта кычытканга кузгалак та салам. Кайсыннан башлыйбыз?

Гел елмаеп кына, йомшак кына эндәшүче Хәтимә апага карап онытылып киткәнмен. Балаларга ризык пешерүче ханым нәкъ менә шундый сыйфатларга ия булырга тиештер дә кебек...

– Кайсы да ярый, Хәтимә апа, – дим. – Үзегез ничек телисез. Беркайчан да кычыткан ашы пешергәнем юк, тегесе дә, монысы да минем өчен яңалык булачак.

– Менә моннан соң пешерә торган бул, сеңлем. Сиңа ошарга тиеш ул. Әзерләве кыен түгел, ә иң мөһиме – организм өчен бик файдалы. Кычыткан – матдәләр алмашын көйли, инсулин эшләп чыгара, шуның белән кандагы шикәрне киметә. Шикәр чиреннән интегүчеләр өчен дә бик файдалы. Кычыткан шулай ук тән тиресе һәм кан тамырларына да бик яхшы. Әйдә, башта, кузгалак белән әзерлибез, яңа ысулны. «Геркулес» белән аннан соң пешерермен.

Хәтимә апа тавык итен шулпадан алды да вак итеп туралган бәрәңгене салып җибәрде. «Пешә торсын», – дип куйды. Ә аннан яшь кычыткан белән кузгалакны турарга кереште:

– Үләннәрне авылдан җыеп алып килдем, – диде ул. – Шәһәрдә үскән кычытканнан аш пешерергә ярамый. Базарда сатылган кычытканга да ышанмыйм, аны кайдан җыйганнарын каян беләсең?!

– Кайсы авыл үләннәрен авыз итәчәкбез бүген? – дим.

– Питрәч районы Чыты авылыннан мин. Якын булгач атна саен диярлек кайтабыз. Авылдан киткәнгә 35 ел инде. Казан шәһәренең 17 нче һөнәр училищесын тәмамлап, студентлар ашханәсенә пешекче булып урнашкан идем. Соңрак тагын бер-ике эш урыны алыштырдым. Ә 4 нче интернат-мәктәпкә килгәнемә 10 ел булды.

Хәтимә апа кайвакыт укучыларга да кычыткан ашы пешерә дигән идем. Баксаң, мондый бәхет һәр балага да тәтеми икән. Интернат булгач, ерак районнардан килгән укучылар ял көннәрендә дә мәктәптә кала. Ул көннәрдә Хәтимә Вәлитова мәктәпкә килеп, балаларга үзенчәлекле, тәмле ризыклар пешерә. Шул исәптән – кычыткан ашы да.

– Ял көннәрендә балалар белән өстәлне бергә әзерлибез, – дип елмайды Хәтимә апа. – Өй мохите тудырырга тырышабыз, бәйрәм булсын, дибез. Айлар буе туган нигезләренә кайтмаучы малай-кызлар да, ятим балалар да бар. Без, пешекче, тәрбиячеләр, ял көннәрендә аларга әниләрен алыштырабыз. «Кайчан ял җитә», – дип, балалар якшәмбене көтеп алалар.

ӘЧКЕЛТЕМ АШ

Кычыткан белән кузгалакны турап бетергәч, пешекче апа, яшел үләннәрне сөзгечкә салып, өстенә кайнар су агызды:

– Бер-ике минут кайнар суда тотасы, – дип аңлатты. – Ләкин озакка калдырырга ярамый, алайса витаминнары бетә.

Ул арада Хәтимә апа кишер белән суганны табада кыздырып тавык шулпасына салды:

– Монысы матурлык өчен генә, тавыкны пешергәндә үк тәм өчен дип, шулпага бөтен бер кишер белән суган салган идем. Шулпаны сөзгәндә бөтен кишер белән суган кала ул. Кузгалаклы кычыткан шулпасы үтә күренмәле булырга тиеш.

Бәрәңге белән кишер, суган кайный торган арада Хәтимә апа пешкән күкәйләрне кабыгыннан чистартты. Тавыкның ак итен зур булмаган кисәкләргә бүлеп куйды. Һәм сүзен дәвам итте:

– Шулпа пешкәнче һәр тәлинкәгә бер күкәй белән бер кисәк ит куеп чыгам. Күкәйне урталай бүлеп куярга кирәк, матур да була, ашарга да җайлы.

Ул да түгел бәрәңге, кишер пешеп җитте. Хәтимә апа кайнап торган шулпага туралган, пешекләнгән кычыткан белән кузгалакны салып җибәрде. Бер-ике минуттан ашны уттан аласы икән, үләннәр озак кайнарга тиеш түгел, файдалы матдәләре калмый. Һәм тагын бер сере бар: кузгалак һәм кычытканны салгач, кәстрүл капкачын ябасы түгел. Шул чакта үләннәр матур яшел төсен саклый.

Ашханәгә әче-төче бер хуш ис таралды. Уттан алып, бер-ике минут торкач, Хәтимә апа, тәлинкәдәге йомырка, ит өстенә кычыткан шулпасы

Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU

ХӘТИМӘ ВӘЛИТОВАДАН КЫЧЫТКАН АШЫ РЕЦЕПТЛАРЫ:

Кузгалак белән: (якынча 8 порция)
1. Тавык шулпасы – 2,5 л
2. Йомырка – 8 данә
3. Бәрәңге – 3-4 данә
4. Суган – 1 баш
5. Кишер – 1 баш
6. Тавык ите – 400 г
7. Кычыткан белән кузгалак – 250 г (бергә-бер)
8. Укроп – чама белән
9. Сыек май – 10 г
10. Тоз – чама белән

Солы («Геркулес») белән: (якынча 8 порция)
1. Тавык шулпасы – 2,5 л
2. Йомырка – 5-6 данә
3. Геркулес – 150 г
4. Бәрәңге – 3 данә
5. Суган – 1 баш
6. Кишер – 1 баш
7. 8 шакмак гөмбәле сыр
8. Тавык ите – 400 г
9. Укроп – бер бәйләм
10. Тоз – чама белән

салды. Аннан укроп, бер бал кашыгы каймак өстәп, безне өстәл янына чакырды.

Менә ул кычыткан ашы! Аш-су китапларындагы сурәт кебек матур: гүя тәлинкә төбендәге сарылы-аклы йомырка болыт артындагы кояш кебек күренеп тора, кызгылт кишер, каймак, яшел тәмләткечләр бу композицияне тулыландыра... Тыштa май ае булуга карамастан яңгыр, салкын. Шушы төрле төсле кычыткан ашы кәефләрне күтәреп, күңелгә бер ямь өстәде.

Әйткәнемчә, кычыткан шулпасын әзерләгәнем юк, элегрәк үзе әни пешерә иде. Шуңа да Хәтимә апаның ашына бик үк дөрес бәя бирә алмам да кебек. Әмма... гаҗәп тәмле тоелды ул миңа. Кузгалак белән булгангамы, кычыткан тәме сизелми дә. Әллә матур бизәлгәнгә, аппетит уяндымы, бер тәлинкә кычыткан ашын мактый-мактый ашап бетердек.

– Ашның бәрәкәте кунак белән. Ризыкны яратып ашагач, күңелле шул, – дип канәгать елмайды пешекче апабыз да. – Балаларның да яннарына барып: «Тәмлеме?» – дип сорап йөрим.

– «Балалар биш әбәт ашый», – дигән идегез. Шулкадәр ризык әзерләп әле яннарына барып йөрергә дә вакытыгыз каламы? – дим.

– Мин бит үзем генә түгел, тагын ике пешекче, ике савыт-саба юучы бар, өлгерәбез. Иртән бишенче яртыда торам. Алты тулганчы эшкә килеп җитәм. Шулпаларны куеп, кирәк әйберләрне әзерләп куям.

«ӘБИДӘН КАЛГАН РЕЦЕПТ»

– Тамак туйды, кычыткан ашын «Геркулес» белән пешереп тә тормыйкмы әллә, – дигән идем, Хәтимә апа ризалашмады:

– Инде әйберләрне әзерләп куйдым, кемгәдер «Геркулес» белән ошар, туклыклырак ул, – диде. Һәм янәдән кызлар җитезлеге белән икенче төрле ашны пешерергә кереште.

Башта ул тавык шулпасын сөзде:

– Кишер белән суганны тәм өчен ит янына салган идем, бу юлы аны кузгалаклы ашка салган сыман янәдан кыздырып утырмыйбыз, – диде Хәтимә апа. – «Геркулес» кушкан кычыткан ашы икенче төрле, аксыл була.

Шуннан сөзелгән шулпага вак итеп туралган бәрәңгене салды. Ә ул кайный торган арада кычытканны вак итеп турап, сөзгечкә салып, бер-ике минут пешекләп алды. Аннан 6 йомырканы савытка сытып туглады. Кычыткан белән йомырканы соңыннан бергә саласы икән.

– Кычыткан ашы йомшак, составында гөмбә булган сыр белән тәмле була дип, – сырларны ялтыравыклы кәгазеннән чистартып, аш тәлинкәләренә куеп чыкты Хәтимә апа. – Бер тәлинкәгә бер бүлем сыр белән бер телем тавык ите әзерләп куярга кирәк. Шулпа әзер булгач шулар өстенә салабыз гына.

Бәрәңге кайнап чыккач, пешекче апа ярдырылган солыны салып җибәрде. Барысы бергә бер биш минут кайнагач, аерым тәлинкәгә болгаткан йомыркаларны салды. Һәм аннан кычытканны өстәде.

– Йомырканы салгач, болгатып торырга кирәк, – ди Хәтимә апа. – Безнең әни дә шулай итә иде. Әбием дә бу рецепт белән пешергән. Дөрес, алар ашка сыр салмаган. Ул чагында каян алсыннар инде аны. Ә менә йомырка белән солы һәр йортта бар. Ит булмаганда, майда суган белән кишерне кыздырып әзерлиләр иде. Ләкин, әлбәттә, кычыткан ашы тавык шулпасында тәмлерәк була. Ә гөмбәле сыр аңа үзенчәлекле бер тәмле тәм өсти.

Шул арада ашыбыз әзер булды да. Аны Хәтимә апа сыр, ит салынган тәлинкәләргә бүлде. Күп итеп укроп салды. Бу беренче әзерләгән кычыткан ашыннан бөтенләй аерыла. Соңгысы куерак, кычытканы да күбрәк. Әллә

тамак туйган иде, әллә нәрсә, миңа беренче рецепт күбрәк ошады. Гәрчә икенчесе, чынлап та, туклыклырак. Гөмбәле сыр шулпаны төрек ашларына охшатып җибәрде кебек тоелды миңа. Ләкин, кем әйтмешли, бу очракта бәхәсләшеп булмый: кемгә нәрсә ошый бит. Шуңа күрә, хөрмәтле укучыларыбыз, ашның икесен дә әзерләп карарга киңәш итәбез.

«БЕРНЕ БИРСӘМ, БИШНЕ ЧЫГАРЫП КУЯ»

«Геркулес»лы кычыткан ашын авыз итәргә интернат-мәктәпнең директоры Люция Саматованы да чакырдык.

– Хәтимә пешергән һәр ризык тәмле була, кычыткан ашы да тел йотарлыктыр, – дип, безнең янга килеп утырды Люция ханым. – Безнең Хәтимә тәмле телле, уңган булуы өстенә, балаларны бик ярата, кыстый-кыстый ашата ул аларны.

Люция апа Саматова белән интернат-мәктәп турында да сөйләшеп алдык. Республиканың 17 районыннан мөмкинлекләре чикле булган 171 укучы белем ала икән. Биредә махсус программа нигезендә уникә ел укыйлар.

– Безнең балалар да камералар астында ТДИ, БДИ бирәләр, – дип сөйләде директор ханым. – Укучыларыбызның белемнәре тигез булмаган кебек, сәламәтлекләре дә төрле. Күп бала унынчы сыйныфтан китә, унберенчегә күчелләре генә кала. Мисал өчен, быелгы уникелэрдә 5 бала, шуның икесе мәктәпне «5» билгеләренә генә тәмамлый. Югары уку йортларына керен, тормышта үз урыннарын тапсын иде балаларыбыз.

Интернат-мәктәптә коляска белән йөрүчеләр дә шактый. Монда сәламәтлекләре чикле балалар өчен барысы да бар: бассейн, ЛФК залы, тренажерлар залы һ.б. Укытучылардан кала, табиб, шәфкать туташлары, логопед, психологлар эшли.

– Монда эшли башлагач, шуны аңладым: мәрхәмәтле, эчке дөньясы бай кешеләр күп бездә, – диде Люция Саматова. – Интернат-мәктәпкә өр-яңадан ремонт ясап чыктык. Күреп торасыз: йокы бүлмәләре, башка заллар, сыйныфлар – барысы да бер дигән. Һәм монда аерым иганәчеләрнең роле бик зур. «Авыру балаларга булышасыбыз килә», – дип үзләре киләләр. Мин исә акча алмыйм, кирәк әйберләрнең исемлеген генә бирәм. Үзләре эшләтеп китереп үк куялар. Укучыларны төрле кичәләргә чакыралар, бүләкләр бирәләр. Күптәннән килеп йөри торган бер иганәчебез бар. Тормышта үз урыныңны ничек табарга дигән темага балаларга лекцияләр дә укый. Менә ул әйтә: «Мохтаҗ, авыру кешеләргә берне бирсәм, Аллаһ Тәгалә минем юлга бишне чыгарып куя», – ди. Чынлап та, дөрес ул.

1. Бәрәңге салабыз!

2. Суган белән кишерне кыздырып өстибез!

3. Ит белән йомырканы бүлеп куябыз!

4. Кычыткан белән кузгалак өстибез!

5. Каймак салабыз!

6. Ашыбыз әзер!

Гадәттә, физик мөмкинлекләре чикле балаларны күргәч, күңелдә бер авыр тойгы уяна. 4 нче интернат-мәктәпкә баргач, андый авыр уйлар барлыкка килмәде. Сәбәбе – авыру булсалар да, шат елмайган балалармы, ә бәлки якты төсләргә буялган, гөлләргә күмелгән мәктәптер, әллә тәмле ашлар пешереп ашатучы сөйкемле Хәтимә апамы, төгәл генә әйтә алмыйм. Хәер, барысы да бардыр.

Ә мин оптимистик рухтагы бу кешеләр белән саубуллашкач, тизрәк өйгә ашыктым. Хәтимә ападан алган дәресләрне тизрәк гамәлдә кулланып карыйсы килә. Киттек, витаминлы аш пешерергә, май кычытканыннан!

Хәтимә Вәлитова киңәшләре:

- Ашның өресен алырга өлгермәсәгез, бераз салкын су өстәгез: өре кире өскә җыелыр.
- Шулпа тәмле булсын дисәгез, итне – салкын, ә ит сусыл булып пешсен өчен, аны кайнап торган суга салырга кирәк.
- Арпа ярмасын майда кыздырып салсагыз, «рассольник» тәмлерәк булыр.
- Фасоль, борчак тизрәк пешсен өчен, һәр 5–10 минут саен суына бер аш кашыгы салкын су өстәп торыгыз.

PRESSA.RU

Реклама 16+

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Болгарлар Урта Иделгә **КАЙЧАН** күчкән

Татар джазы **НИНДИ** ул

Татар лаләсе **КАЙЧАН** чәчәк ата

«Ел китабы» бәйгесендә **КАЙСЫ** китап җиңде

Күгәрчен авылында **НӘРСӘ** белән мавыгалар

УРТА ИДЕЛГӘ КҮЧЕШ

Борынгы болгарлар, дөресрәге, аларның элгәрләре булган оногурлар, сарагурлар, кутригурлар, утригурлар һәм дә савирлар Көнчыгыш Европа далаларына һуннар дулкыны белән III–IV гасырлар тирәсендә килеп чыгалар, әмма язма чыганакларда болгар исеме белән беренче мәртәбә V гасырда гына телгә алыналар. Кубрат ханның Бөек Болгар дәүләте таркалганнан соң, VII гасыр ахырларында болгарлар, әкренләп, Урта Идел һәм Кама буйларына күчеп утыра башлыйлар.

Автор:
Фаяз Хужин

БОЛГАРЛАРНЫҢ КҮЧЕШ ДУЛКЫННАРЫ

Бер халык та сәбәпсез генә яшәү урынын алыштырмый, гасырлар буена яшәп күнегелгән, җангa якын туган җирен ташлап, бөтенләй дә билгесез башка бер урынга күчеп утырмый. Болгарлар – дала халкы, Азов, Каспий, Кара диңгез буе далалары аларның табигатенә, яшәү рәвешенә бик тә туры килә иде. Әмма салмак кына агып яткан тормыш дәрьясы көтмәгәндә күтәрелеп киткән сәяси дулкыннарга тиз бирешүчән. Болгарлар тормышында да шулай була: Кубрат хан үлеменнән соң аның уллары-варислары арасында килеп чыккан низаг ахыр чиктә дәүләтнең таркалуына китерә. Бөек Болгар җирләре күтәрелеп килүче Хәзәр каганаты биләмәләренә кушыла. Бу вакыйгалар, аңлашыла ки, тыныч кына, сугышларсыз гына үтмәгән. Менә шушы шартларда болгарларның бер өлеше көнбатышка, Дунай буйларына юнәлгән, икенче өлеше исә төньякка, Урта Идел буйларына килеп төпләнгән.

Элгәреге болгарларның Урта Идел төбәгендәге эзләре Самара һәм Ульян өлкәләрендә таралган Новинково археологик культурасы истәлекләрендә чагылыш тапкан. Бу культурага караган каберлекләр, борынгы зиратлар – хәзерге көндә аларның саны ике дистәдән артык – беренче мәртәбә 1980нче елларда Новинково авылы янында казып тикшерелгән. Әлеге истәлекләр VII гасыр ахырына һәм VIII гасырның беренче яртысына карыйлар.

Болгарларның Урта Иделгә икенче күчешләре Хәзәр каганатындагы 737 ел вакыйгалары белән бәйле. Бу елда хәзәрләр атаклы полководец Мәрван җитәкчелегендәге гарәп армиясе тарафыннан тар-мар ителә. Күп кенә шәһәравыллар җимерелә, каганлыкның башкаласы Төньяк Кавказдагы Сәмәндәрдән тынычрак җиргә – Түбән Иделдә урнашкан Итилгә күчерелә. Гарәпләр хәзәр каганын мәҗбүриләп ислам диненә күндерәләр. Яңа дин әкренләп гади халык, шул исәптән болгарлар арасында да тарала башлый. Хәзәр каганлыгы территориясендә казып тикшерелгән мөселман зиратлары башлыча IX гасырда барлыкка килгәннәр.

Болгарларның әлеге күчеш чорына караган археологик истәлекләре арасында иң атаклысы – Татарстанның Тәтеш районы Олы Тархан авылы янында урнашкан борынгы зират. Биредә әле 1950нче еллар ахырында ук VIII гасыр уртасы һәм IX гасырның беренче яртысы аралыгында күмелгән 358 кешенең кабере казып тикшерелгән иде. Аларның барысы да диярлек мәҗүсиләр йоласы белән күмелгән, арада берничә мөселман кабере булырга мөмкин дип фаразлана.

Өченче мәртәбә болгарлар безнең якларга IX гасырның икенче яртысында күчеп утырганнар. Бу күчешнең сәбәбе Хәзәр илендә рәсми рәвештә яңа дин – яһүд дине кабул итү белән бәйле. Каганның әлеге карарына кискен төстә каршы чыккан болгарлар фетнә оештыралар. Илдә чуалышлар, аннан соң инде, гадәттәгечә, анда катнашучыларны төрлечә эзәрлекләүләр башланып китә. Шушы болганчык заманнарда болгарларның бер өлеше гаиләләре белән Идел-Кама төбәкләренә китеп котыла.

Әлеге миграциянең археологиядәге чагылышын республикабызның Спас районында, Болгар шәһәрлегеннән 20 чакрым ераклыкта урнашкан атаклы Танкеевка каберлегеннән эзләргә кирәктер,

Кылычлар. Зур Тархан каберлеге.

Фотолар автордан алынды







Асма бизәкләр. Зур Тархан каберлеге.

минемчә. Танкеевка – Көнчыгыш Европаның урта гасырлар чорындагы иң эре некрополе. Биредә 5–6 мең чамасы кабер исәпләнә, бүгенге көндә Казан археологлары тарафыннан шуларның 1200 гә якыны казып тикшерелгән. Биредә башлыча хәзерге Пермь, Удмуртия якларыннан килеп утырган фин-угыр халкы вәкилләре һәм болгарлар күмелгән. Танкеевкада ачылган каберләрдәге затларның Х гасырга караган бер өлеше мөселман канунарына туры китереп күмелгән.

Болгарларның Урта Иделгә соңгы күчешләре IX гасыр ахырына – Х гасыр башларына туры килә. Бу күчеш – көнчыгыштан килгән сугышчан бәҗәнәкләрнең (печенегларның) Хәзәр каганатына көчле һөҗүмнәре нәтиҗәсе. Авыллар һәм калалар яндырыла, сугышларда бик күп кеше һәлак була. Халык яңадан урыныннан куба, инде күптән таныш юллар буйлап Дунай якларына, Идел-Кама буйларына юнәлә. Бу вакытта Идел болгарларында яңа дәүләт оешу процессы бара. Көньяктан, Дон, Азов, Кара диңгез буйларыннан күчеп утырган болгарлар оешып килүче дәүләттәге фин-угыр һәм төрки халыкларның нисбәтен соңгылары ягына арттырып, тиз арада яңа, утрак тормыш рәвешенә күчәләр.

ТӨП ВАТАН, ЯКИ АБОРИГЕНЛЫК МӘСЬӘЛӘСЕ

Билгеле булганча, Идел–Урал төбәкләре – фин-угыр, ягъни хәзерге удмурт, коми, мари, мордва һәм аларга тугандаш башка халыкларның, шул исәптән финнарның да, ана ватаннары. Аларның иң борынгы бабалары шушы төбәктә яшәгән, күршеләреннән үзгә аерым этнос, кабилә/халык булып шушында формалашкан. Идел Болгарстаны җирләрендә, бигрәк тә аның үзәк районнарында, фин-угыр кабиләләре яшәмәгән диярлек. Күрәсең алар, безнең якларга килеп чыккан сугышчан болгарлардан куркып, ә бәлки әле тагын да элегрәк, имәнкискә кабиләләре күчеп утырган чорда ук, бу җирләрне калдырып китәргә мәҗбүр ителгәннәрдер. Әлбәттә, Идел Болгары барлыкка килгәч, фин-угыр халыклары күршеләре белән дустанә мөнәсәбәткә керәләр, антропология материаллары күрсәткәнчә, болгарларның этнос буларак формалашуында зур роль уйныйлар.

Төрле тарихи чорларда безнең якларга иран телле кабиләләр дә үтеп кергәләгән. Кайбер галимнәрнең, Идел-Кама төбәгендә төркиләр килмешәк түгел, бәлки меңнәрчә ел шушы җирләрдә яшәгән абориген халыктыр, дигән кыю фикерләре дә археология материаллары белән расланмый. Төрки телле кабиләләрнең аз санлы төркемнәре безнең якларга һуннар чорында, IV–V гасырларда килеп чыгалар (һун казаннары, Турай каберлеге), әмма биредәге фин-угырларга аларның этник яктан тәэсире бөтенләй диярлек сизелми.

Төрки каганлыгы чорында, ягъни VI–VII гасырларда, Көнчыгыш Европа, шул исәптән Урта Идел халыклары арасында да, этник үзгәрешләр ачыграк күзәтелә. Бу чорга караган археологик культуралар арасында иң серлесе, галимнәр арасында кайнар бәхәсләр тудырганы, әлбәттә, имәнкискә культурасы. Искәртеп үтик: археологик культураның һәм аны калдырган халыкның исеме республикабызның Лаеш районы Имәнкискә авылыннан алынган. Бу авыл янында әле 1950нче елларда ук көчле ныгытмалары сакланып калган шәһәрлек казып тикшерелгән иде. Әлеге культурага нисбәтле истәлекләрнең саны инде 600дән артып китте, әллә никадәр авыл, крепость урыннары, каберлекләр казып өйрәнелгән, әмма «Кемнәр соң алар, имәнкискәлеләр?» дигән

Идел буендагы VIII–X гасырларга караган каберлекләрнең таралыш картасы.

сорауга төгәл җавап бирүче юк әле. Озак еллар буена имәнкискәлеләрне Көньяк Себер далаларыннан күчеп килгән төрки телле кабиләләр исәбенә кертеп йөрттеләр. Аларны «бортаслар, фин-угырлар, балтлар» дип атаучы галимнәр дә булды. Бүген исә имәнкискәлеләрне борынгы славяннар белән тиңләштерергә омтылучылар күп. Алай гына да түгел, фәндә шул фикер өстенлек итә. Элгәреге болгарлар археологиясен җентекләп өйрәнгән аксакал галимебез, Татарстан Фәннәр академиясе Археология институтының баш гыйльми хезмәткәре Евгений Казаков кына, бу фикер белән килешмичә, Имәнкискә культурасының килеп чыгышын IV гасырда һуннар тарафыннан тар-мар ителгән иран телле сарматлар белән бәйләп аңлатырга тырыша. Бу темага караган бәхәсләр әле дә дәвам итә.

Имәнкискәлеләр Идел-Кама төбәгендә VII гасыр ахырларына кадәр яшиләр. Аларны бу җирләрдән элгәреге болгарларның беренче дулкыны көнбатышка, борынгы славяннар (северяннар) җиренә куып җибәргән, дип саныйлар. Калган өлеше исә болгарлар белән кушылып беткәндер, дип фаразлана.

Болгарлар килер алдыннан һәм алар килеп төпләнгәч тә әле Идел белән Урал арасында мадьяр-

PRESSA.RU

Профессионал чүлмәк осталары эшләгән табылдык чүлмәкләр.

Амфора. Балчык. Самара өлкәсе. VII гасыр.

Фляга. Кызыл балчык. Волгоград өлкәсе. VIII гасырның икенче яртысы.

Алтын алка. II Брусян каберлеге. Самара өлкәсе. VII-VIII гасырлар.

Алтын алка. I Шәләхмәт каберлеге. Самара өлкәсе. VII–VIII гасырлар.

Кургаш мөһер-пломба. 1нче номерлы курган. Кече Рязань каберлеге. Самара өлкәсе.

лар – борынгы венгрлар яшәгән. Алар күчмә тормыш алып барганнар. Элгәреге мадьярларның эзләрен (кушнаренково тибындагы чүлмәкләр рәвешендә) археологлар әле Имәнкискә истәлекләрен өйрәнгәндә үк табып алганнар. IX гасырда исә бер төркем мадьярлар Кама белән Кече Чирмешән арасында яшәгәннәр (Зур Тигәнәле каберлеге). Аларның каберләре Танкеевка некрополендә дә бар. Венгрларның урта гасырлар чорына караган язма документларында Идел белән Урал арасындагы җирләр Magna Hungaria (Бөек Венгрия) дип йөртелгән. IX гасыр урталарында мадьярлар көнбатыш тарафларга күченеп китәләр, әмма аларның бер өлеше безнең якларда кала (Юлиан исемле миссионер сәяхәтче аларны 1235 елда Бөек шәһәр/Биләр тирәсендә очрата) һәм биредә болгарлар белән катнашып бетәләр.

Күргәнегезчә, Идел Болгары баштан ук күпмилләтле дәүләт буларак оешкан икән.

КАЛАЛАР ТОРГЫЗГАН ХАЛЫК

Урта Идел һәм Түбән Кама буйларына күчеп утырган болгарлар IX–X гасырлар чигендә дәүләтләре барлыкка килгәнче, алай гына да түгел, хәтта X гасыр ахырларына кадәр күчмә тормыш алып барганнар (димәк, шәһәр-авыллары булмаган), мәҗүси аллаларына табынганнар, дигән фикер фәндә киң таралган. Минемчә, ул чынбарлыкка һич тә туры килми.

Күчмә тормыш ул башлыча дала халыкларына хас, чөнки далада игенчелек белән шөгыльләнү өчен шартлар юк дәрәҗәсендә, ә ат, сыер, сарык, дөя ише маллар асрау өчен үләнгә бай көтүлекләр тулып ята. Әле анда да аз гына мөмкинлекләр килеп чыгуга күчмәннәр, киез юрталарын калдырып, утрак тормышка күчәргә омтыла. Классик күчмәннәрдән саналган һуннарны алып карагыз. Аларның тормышы борынгы кытай язмаларында шактый тулы чагылыш тапкан. Сыма Цянь исемле тарихчы хезмәтләрендә һуннарның яхшы ныгытылган шәһәрләре, металлургия һәм тимер эшкәртү кебек нык үскән һөнәрчелек тармаклары, игенчелек өлкәсендәге уңышлары турында бай гына белешмә бирелгән. Һәм боларның барысы да археология материаллары белән раслана. Халкының күп өлешен болгарлар һәм аланнар тәшкил иткән Хәзәр каганлыгы да күчмәннәр дәүләте түгел. Башкаласы – чит мәмләкәтләрдә дә мәгълүм атаклы Итил. Киң һәм биек таш диварлар белән ныгытылган калалары бар. Уңайлыклары булган җирләрдә иген игәләр, бакчаларында йөзем үстерәләр. Хезмәт халкының сизелерлек өлешен һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр тәшкил итә. Хөкүмәт көмеш дирһәмнәр сугу эшен оештырган. Византия һәм башка Шәрык илләре белән тыгыз сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырылган.

Менә шундый дәүләттән чыккан болгарлар, безнең якларга килеп төпләнгәч, бабаларының элеккеге традицияләренә тугры калып, күчмә тормышны өстен санарлар микәнни? Бик шикле, чөнки телгән очракта да безнең табигать шартларында ел әйләнә күчмә терлекчелек белән шөгыльләнергә мөмкинлекләр юк: кышын болыннар тирән кар катламы астында кала, ә күчмәннәр маллары өчен кышка азык әзерләп калырга өйрәнмәгән. Аның каравы, тирә-юньдә менә дигән уңдырышлы җирләр – сөр, чәч, уңышын җыеп ал. Шулай эшлиләр дә. Кыскасы, болгарларның яңа җирләрдә утрак тормышка күчү процессы чагыштырмача аз вакыт эчендә тәгәлләнгән. Кайбер галимнәрнең, Болгар илендә иң элгәреге авыллар һәм шәһәрләр (Болгар белән Сувардан калганнары) X гасырның икенче яртысында гына барлыкка килә, дигән фикерләре белән һич тә килешәсе килми. Идел Болгары күчмәннәр дәүләте буларак оешкан булып чыга инде алайса. Бу фикер бернинди мантыйкка да сыймый,

Яңгыравык асма бизәк. Бронза. Танкеевка каберлеге.



Өзәңгеләр. Кече Рязань каберлеге. Самара өлкәсе. VII-VIII гасырлар азагы.

Авызлыклар. Самара өлкәсе җирлегендәге IV курганлы Брусян каберлеге. VII-VIII гасырлар азагы.

Каеш эшләнмәләре. I курганлы-грунтлы Новинков каберлеге. Самара өлкәсе. VII–VIII гасырлар азагы.

археология материаллары белән дә ярашмый.

Археология материаллары дигәннән: Самара һәм Ульяновск археологлары соңгы елларда болгарларның VIII–IX гасырларда барлыкка килгән авыл һәм хәтта ныгытылган торак пунктларын казып тикшерделәр. Казылмаларда сабан төрәне, кәтмән, урак ише игенчелек өлкәсенә караган табылдыклар да очраган. IX гасыр ахырында нигезләнгән Әҗмер сәүдә-һөнәрчелек поселогында 814, 994, 895 елларда сугылган гарәп акчалары табылды. 902–908 еллар аралыгында Болгар дәүләте үзенең көмеш акчаларын суга башлый.

Гарәп тарихчысы Ибн Рөстәнең IX гасыр ахырларында яшәгән болгарлар турында: «Алар – игенче халык, күбесе ислам дине тота, авылларында мәчетләр, ә мәчет каршында башлангыч мәктәпләре бар» – дигән сүзләре чынбарлыкка туры килә һәм археология материаллары белән раслана.

Табылдыклар. Танкеевка каберлеге.

PRESSA.RU

КАЗАН... ҺӘМ ТАТАР ДЖАЗЫ

«Татарча джаз» төшенчәсен кайберәүләр нонсенс дип исәпли. Ә икенче берәүләр, киресенчә, Лундстрем, Дерингларда соң, аның нәкъ менә бүген икенче сулышы ачылып килә, дигән фикердә тора. Яңарыш идеясен куәтләгәндәй, узып баручы сезонда Татар дәүләт филармониясе дә джазга өр-яңадан канатлар куярга омтылыш ясады. «Казан джазы» – башкалабызда яшәүчеләр, татарстанлылар һәм килгән кунаклар өчен анык, аңлаешлы төшенчә, әлбәттә. Сандецкий утарын да, һәртөрле фестивальләрне дә, «Үзгәреш җиле» проектын да искә алырга була бу уңайдан. Ә менә джазның татарчасы... Әйдәгез, татар джазы төшенчәсенә дә мөмкин булганча ачыклык кертеп карыйк әле?

Авторлар:
Олеся Бондаревская

Луиза Янсуар

КОШНЫ КОТКАРЫРГА КИРӘК!

Оркестрның репетициясе безгә, гади тамашачыга, җайга салынган сәгать механизмын хәтерләтә: менә, ноталар язылган кәгазь битләре кыштырдый, алтынсу аһәңен коеп, тынлы кораллар «телгә килә», кыллы инструментлар тирбәлешә башлый, аларга клавишалар кушыла... Шушы синхрон хәрәкәттән ритм ярала, һәм ул колакларны музыка булып иркәләргә керешә.

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе сәхнәсе. Татарстан Республикасының джаз-оркестры – 19 музыкант, дирижёр, оркестр җитәкчесе һәм чакырылган башкаручылар – алда көтеләчәк тамашаның ахыргы версиясен әзерли. Берничә көннән Мәскәүдә «Зур концерт» узачак, шуңа әзерләнәләр. Ә аның премьерасын Казан тамашачысы инде 2017 елның февраль аенда башкалабызда тыңлаган иде.

«Зур концерт» – оркестрның джаз юнәлешендә иҗат ителгән элеккеге композицияләрдән торган, шулай ук әлеге программа өчен махсус язылган әсәрләрдән гыйбарәт беренче зур мөстәкыйль проекты ул.

Менә сәхнәгә Рушания Мөшәрәпова күтәрелә. Ул «Татлы хыял» әсәрен башкара. Оркестрның җитәкчесе, концерт программасының идея авторы һәм композитор Лидия Әхмәтова чираттагы башкаручыны сәхнәгә дәшә. Оркестрның әле нәкъ дәртләнгән генә чагы. Татар сәхнәсендә инде үз урынын яулап килгән Зарина Вилданова «Кара төндә»не башкара, бу җыр, әйтерсең, тамырлар буйлап ага. Оркестрны бар матурлыгында, затлылыгында тоя башлыйсың.

Тәнәфес игълан итәләр. Форсаттан файдаланып, сәхнә артына юл тотабыз. Джаз телендә «сөйләшүчеләр» мохитенә күмелер өчен. Гастрольләрдә нинди маҗараларга юлыгуларын сөйләп китәләр музыкантлар һәм җырчылар.

– Менә күптән түгел генә Анатолий Александрович бер кошны коткарды...

Хәер, джаз үзе дә кулга тотып булмастай, хәрәкәт-очышын туктаусыз үзгәртеп торучан җилфер канатлы кошны хәтерләтә ләбаса. Ул да коткаруга мохтаҗ бугай, ялгышмасак... Асылда, сәяхәтләре вакытында кошларны коткарып йөргән каһарманыбыз – оркестрның дирижёры Анатолий Василевский үз гомеренең күпчелек өлешен нәкъ менә Казан джазына багышлый. Әле Архангельск музыка училищесы студенты булган чагында ук аңарга гастрольгә килгән легендар Лундстремның «шанхай бэнд»ын тыңлау насыйп була. Училищеда укуын тәмамлый да, консерваториягә укырга керер һәм кумирының оркестрында уйнар өчен, Татариягә юл тота егет. Әмма ул чакта инде Лундстрем Мәскәүгә күченеп өлгергән була. Анатолий Александрович исә Казанда төпләнеп кала һәм башкалабызда джаз юнәлешенә нигез салган шәхеснең традицияләрен дәвам итә. Ул КАИның джаз-бэнды белән җитәкчелек итә, аннары – легендар «Синтез-бэнд», Казан консерваториясенең биг-бэнды белән. Һәм менә хәзер, инде 5 елга якын, Филармониянең джаз-оркестры – аның карамагында. Сүз уңаеннан, әлеге оркестр, нинди генә метаморфозалар кичермәсен, барыбер дә Лундстремның «шанхай» мирасын саклаучы булып кала бирә. Бу фактны аның тарихыннан берничек тә сызып ташлап булмый. Мэтр үзе Казаннан китеп баргач, аны озак еллар дәвамында икенче бер легендар джазмен Виктор Деринг җитәкли.

Асылда, без Казан джазын совет чорында һәм аннан соң да әле нәкъ менә аларның исемнәре белән бәйләп күзаллый идек тә. Ә хәзер инде башкалабызга дөньяның кайсы гына кыйтгаларыннан агылмый мәртәбәле джаз осталары. Шулай да алар безнең өчен экзотика булып калуын дәвам итә. Ә Лундстрем традицияләре, «татарча джаз» төшенчәсенә орынырга омтылуы беләнме икән, ностальгия уятучы бер алтын балкыш булып үткәнебездәге офыкларда алтынсу аһәңнәрен сибеп, тибрәлеп тора. Рәшә генәме ул? Чынбарлыкмы?

НӘРСӘ УЛ ДЖАЗ?

Йә, ярый, артык хискә бирелмик. Оркестрда уйнаучы музыкантлар джаз турында ни уйлыйлар икән – шуны белешик. Эшме бу алар өчен? Хоббимы? Әллә тормыш рәвешеме?

Беренче булып торбачы телгә килде:

– Джаз ул – ирек, – дип елмайды. – Джазда, классик музыкадан аермалы буларак, импровизациягә мул урын калдырыла. Әлбәттә, син аранжировка кысаларыннан әллә кайда читкә чыгып китә алмыйсың, әмма бит аның эчендә импровизация өчен күпме мөмкинлекләр бар. Бормалардан, нәкыш-бизәкләрдән торган тоташ бер дөнья...

Һәм менә без бу бизәкләрне тыңлыйбыз. Кайчандыр Чарли Паркер белән Диззи Гиллепсиның Ирек



ТАТАРСТАНДА
ЖЫРЛЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ
УКЫ!

мәйданындагы фонотекада саклаучы тәлинкәдәге язмаларын сөртелеп беткәнче тыңлаган бу егетләр бүген филармониянең көндезге тынлыгында «кара музыка»ны уйныйлар. Ә бу музыка үзе инде күптән Америка барлары, Париж урамнары, совет чоры һәм аннары үзгәртеп кору елларының яшеренрәк клублары фоны булудан туктап, фестиваль мәйданнарына күтәрелде, классика белән беррәттән, виртуозлыкны сынау билгесенә әверелде. Ул хәзер беркем тарафыннан да тыелмый. Әмма барыбер дә мәгънәсе бер булып кала бирә: джаз ул – ирек. Джаз ул – дәрт. Джаз ул – хисләр өермәсе.

Төрле илләр, кыйтгалар өстеннән җилфердәп узган бу иректе музыка, канатларын җәеп, Казаныбызда да яңгырый. Әмма татарча пентатоника һәм башкару манерасы белән кануннарны җимерә торган джазны кушып буламы икән?

БАШТА «САМБА» БУЛГАН...

– Джаз ярату таләп итә, билгеле. Һәм – коточкыч зур хезмәт, – ди Анатолий Василевский. – Оркестрга кайчак торбада, тромбонда, саксофонда искиткеч шәп уйный торган егетләр-кызлар килә. Алар әйбәт уйнасак, шул җитә, дип исәплиләр һәм... ялгышалар.

– Ә импровизацияләргә урын мулдан булган бу музыканы уйнаганда ничек дирижерлык итәсез? – дип төпченәбез аңардан.

Баксаң, һәр импровизациясенең үз тәртипләре, кануннары, кагыйдәләре бар икән. Хәер, кайсы гына иҗат өлкәсен алма, импровизация – осталыкның иң югары билгесе булып тора бит. Бары чын осталыкка ирешкәннәр генә үзләренә мондый «ирек» бирә ала.

– Джазда иң куркынычы – дәрт булмау, җаның-тәнең белән бирелеп уйнамау, – ди Анатолий Александрович.

Ул арада Филармония директоры Кадыйм Нуруллин кабинетына юл тотабыз. Джаз турында аның фикерләре нindirәк икән?

– Оркестр безгә 5 ел элек «күченде». Без аны үзгәртү, үстерү юнәлешендә эш башлап җибәрдек. Һәм ул безгә менә хәзер яңа горизонтлар ача башлады. Грантлар отабыз, Россия буйлап гастрольләргә чыга башладык. Элек мондый хәл булмаган. Оркестрның репертуары бай, традицияләр турында әйтеп тору – анысы инде артык, мөгаен, үзегез дә беләсез. Безнең белән Анатолий Кролл эшли. «New York Voices», Мэнди Гейнс, Фернанда Норонья, Лоретта Холлоуэй, Фабрицио Боссо һәм башка дөньякүләм танылган шәхесләр филармония сәхнәсендә шушы оркестр белән бергә чыгышлар ясый. Мин аны киләчәктә Казанның визит карточкасы буларак фестивальләргә чыгардай коллектив итеп күрергә телим.

Әлбәттә, кыенлыклар турында да искәртте җитәкче. Татарстанда джаз юнәлешендә эшли ала торган музыкантлар һәм башкаручыларга – җитди дефицит.

Без кабат репетиция залына әйләнеп кайтканда, оркестрантлар инде үз урыннарына урнашкан иделәр. Һәм менә Александр Ключаревның «Татар самба»сын уйнап җибәрделәр алар. Лундстрем бер интервьюсында болай дигән була: «Халыкка джаз кирәк түгел, дип исәпләнгән елларда Ключарев джаз халыкка кирәк, дигән караштa торган бердәнбер кеше була». Нәкъ менә ул Лундстремга оркестрны саклап калырга ярдәм итә дә. Хәзер нәкъ менә шул самба «Зур концерт»ны ачып җибәрә һәм Казан джазындагы татарча сәхифәләрне тамашачыга инде яңа заман музыкантлары һәм башкаручылары белән бергә тоемларга ярдәм итә.

«ТАТАРЧА ДЖАЗ – КИЛӘЧӘК ЭШЕ»

Римма Шәйхелова,
«Караван песен. Кәрван җыры» проектының авторы, халыкара конкурслар лауреаты:

– Лундстрем традицияләре турында без Казанда сөйләргә яратабыз. Әйе, ул үз чорында татар музыка сәнгатенә джаз рухын кертеп җибәрү өчен гаять зур эш башкарган. Ләкин бит сүз барыбер дә интерпретация турында бара. Бу джазның үз эчке мантыйгыннан килеп чыккан варианты түгел. Ул, әйтик, Рөстәм Яхин, Алмаз Монасыйпов әсәрләренә менә дигән композицияләр әзерли. Ләкин бу җырлар барыбер дә, иң беренче чиратта, татар музыкасы стандартлары, пентатоника нигезендә эшләнгән була. Джазны башкару традициясе – монысы бөтенләй икенче мәсьәлә. Менә «Үзгәреш җиле» булып узды. Анда бик күркәм композицияләр эшләнгән иде. Арада, әлбәттә, отышсызлары да булды. Әмма бу джазны сәхнәгә кайтару, башкару юнәлешендә бик файдалы проект, дип әйтер идем.
Татар джазы бар, дип авыз тутырып игълан ясарга шикләнәм. Бигрәк тә башкару манерасына килгәндә. Джазга интерпретацияләр – алары, әйе, җитәрлек. Әмма чын джаз ул һәм тексты, һәм музыкаль «киеме» һәм җырчының башкару техникасы белән органик берлектә яши. «Караван песен. Кәрван җыры» дигән проектны әзерләгәндә, төп максатым халык яхшы белгән классик джаз үрнәкләренә татарча яңгыраш өреп карау булды. Джазны татарча «сөйләштереп» карау, дияргә дә була. Үзенә күрә бер шактый тәвәккәл эксперимент, чөнки «джаз теле» – ул шактый үзенчәлекле тел. Традицион татар шигыре кысаларында яши торган тел, дип әйтмәс идем мин аны. Метро-ритмика, фразировканы сакларга тырыштык. Текстларны турыдан-туры инглиз теленнән тәрҗемә итәргә Татарстан китап нәшрияты редакторы Әлфия Шәйдуллина алынды. Казандагы бер джаз-клубта шушы композицияләрне беренче тапкыр башкарганда, хәйран калдык: кешеләр, алларына китереп куйган ризыкны онытып, безгә кушылып җырлый башладылар. Җырларны яхшы беләләр, әмма аның татарча яңгырашына чын-чынлап гаҗәпләнделәр. Кайда гына чыгыш ясасак та, рәхмәт әйтәләр, соклану белдерәләр. Күрәмсең, татар тамашачысына яраткан композицияләре белән беррәттән, татарча яңгырашны да ишетү – икеләтә рәхәт.
Киләчәктә татар шагыйрьләре белән эшләргә теләк бар. Бу инде нәкъ менә джазның органик үстерелешенә бер адым булыр иде. Акрынлап без шуңа барабыз да, мөгаен. Моны эшләргә генә кирәк. Джаз ул татар музыкасы түгел диючеләр белән бәхәсләшә алам. Аны татарча да матур яңгырашлы итеп була. «Балкан джазы» дигән күренешкә беребез дә гаҗәпләнми бит, ә асылда безнең ситуация аларныкыннан әллә ни ерак тормый. Әлбәттә, свинг татар рухына туры килмидер, әмма андыйга китсә, безгә Европа костюмнарыннан да баш тартырга туры килә инде...

«АЛГА БЕРНИЧӘ АДЫМ»

Эльмир Низамов,
композитор:

– Татар музыка сәнгате джаздан башка да яши ала, дип утырырга ярамый, билгеле. Джазның тагын бер өстенлеге – ул тере башкару, һәм импровизация осталыгы, ә безнең сәнгать тере музыка юнәлешендә үсәргә тиеш киләчәктә. «Үзгәреш җиле» дә, «Зур концерт» та – берничә адымга алга китү. Джаз-бэндның үсеше татар эстрадасының язмышына бөтенләй башка борылыш бирә алыр иде, миңа калса. Катлаулы симфоник музыканы һәркем аңламый, кабул итми, дигән очракта, джаз бу ситуацияне хәл итәргә булышыр иде. Татар джазы – минемчә, татар сәнгатен дөнья күләмендә популярлаштыру өчен дә менә дигән инструмент. Мин аны киләчәктә шулай күрәм дә.



PRESSA.RU

ТАТАР ЛАЛӘСЕ
ЧӘЧӘК АТКАН МӘЛДӘ

Яз җитүгә, Татарстанда елның бу фасылына хас умырзаялар гына түгел, лаләләр, розалар, лотослар һәм хәтта пальметталар да чәчәк ата. Алар халыкның иң модалы катламы киемен аллы-гөлле чәчәккә күмә. Чөнки татар бизәге һәм колоритына мәхәббәт дөньяны яулап маташа.

Реклама

Реклама.

КЫЗЛАР КҮҢЕЛЕ
ГҮЗӘЛЛЕККӘ ТАРТЫЛА

Татар акценты булган мода чикләрне үтеп чыга. Дизайнерлар яңа коллекцияләр чыгара, ә мода артыннан куучылар чиратка тезелә. Алар киемнәрен генә яңартып калмыйча, үзләренең йә ислам диненә, йә миллләтенә, йә ватаннары Татарстанга мәхәббәтен дә күрсәтергә омтыла.

Барлык мотивлар стильләштерелгән һәм күптөрле трактовкага ия. Бизәк элементларының нинди тәртиптә урнашуы һәм үзара ничек ярашуы да мөһим роль уйный. Һәм татар халкының символлары, мәдәниятеннән хәбәрдар кеше татар бизәген рәхәтләнеп укый ала.

Бизәктәге **лалә** сакраль (изге) мәгънәгә ия, чөнки бу сүзнең гарәпчә язылышында «Аллаһ» сүзендәге хәрефләр кулланыла.

Татар бизәкләрендәге **роза (гөлчәчәк)** Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) символы булып тора.

Реклама.

Автор:
Ната Смирнова

– Ислам дине күзлегеннән караганда, анда мода юк, – ди мөселман киемнәре дизайнеры Зарина Бабаджанова. – Әмма, барлык хатын-кызлар кебек үк, мөслимәләр дә матурлыкка тартыла.

Яулык бәйләгән хатын-кыз кием сайлауда да чикләнгән бит. Яулык бәйли башлагач, мин моны үз җилкәмдә татыдым. Мөселман сәнәгате базарында үземне канәгатьләндерәчәк күлмәк таба алмаячагымны аңлагач, яраткан эшем – нәфис тә, мөселманча да киемнәр җитештерү белән шөгыльләнә башладым. Көндәлеккә кияргә, офис хезмәткәрләре өчен, өйдә кия торганнарны...

КАЗАДАН КОТЫЛУ

Шул вакытта тагын бер нәрсәне аңладым: мөслимә, кияүгә чыкканда, матур кием таба алмый. Стандарт туй күлмәген киеп булмый, чөнки ул ачык, ә гадәти киемнән гомердә бер генә тапкыр була торган бәйрәмне бозасы килми. Кәләшләргә туй күлмәген водолазка өстеннән кияргә туры килә иде. Һәм мин бу казадан ничек тә котылырга булдым. Уникаль күлмәкләр уйлап таптым. Билгеле, бу минем үземнең эчке дөньям, мин үзем кияргә теләгән фасондагы туй күлмәкләрен тегәм.

САКРАЛЬ МӘГЪНӘ

Зарина үзенең беренче коллекциясен 2014 елда Islamic Clothes* фестивалендә тәкъдим итүен исенә төшерә.

– Аңарда бер генә тамчы Европа акценты да юк иде, – ди дизайнер. – Бөтен киемнәр тулысынча ябык һәм искиткеч купшы. Һәм барысы да кулдан тегелгән. Татарстанда гына түгел, гомумән бөтен Россиядә дә мондый киемнәр юк иде. Мин нәкъ менә никах киемнәрен тукталырга булдым.

Аннары Зарина чигелгән күлмәкләрдә билгеле бер мәгънә дә булырга тиешлеген аңлый. Һәм татар костюмы тарихын өйрәнә башлый.

– Һәр костюм тагын да уникальрәк булсын өчен, мин бизәкләрне аларның милли мәгънәсенә яраштырып чигә башладым, барлык бизәкләргә дә билгеле бер мәгълүмат хас бит. Бу традицияләр миңа бик булыша һәм илһамландыра, – дип ышандыра Зарина.

КҮҢЕЛ ХАЛӘТЕ

– Исламда кемдер дөрес тенденцияләргә мода тудыра икән, бу бик шәп бит. Кызларны ниндидер күлмәкләрне киюдән тыялар. Син күзгә бәрелеп торасың, бик каты ялтырыйсың, ислам моны тыя, диләр. Ә ислам моны тыймый. Киресенчә, исламда барысы да гүзәл, затлы һәм нәфис, – дип, Зарина Бабаджанова үз күлмәкләрен күрсәтә. Алар күз явын алырлык матур да, шул ук вакытта тыйнак һәм оригиналь дә.

– Кызлар беренче тапкыр мин теккән киемнәрне кигәндә, кайвакыт

Фото: Ната Смирнова

* Islamic Clothes – «Ислам киеме» – мөселман киеме фестивале.

хәтта күзләре яшьләнә. Алар гади күлмәкнең үзләрен шундый гүзәл һәм нәфис күрсәтәчәген күз алдына да китерә алмаган була.

Моданы без үзебез тудырабыз. Бу һәр хатын-кызның күңел халәте. Һәм озын ябык күлмәкләрне мөселманнар гына түгел, башка халыклар да яратып кия, борынгы Русьта да хатын-кызлар яулык бәйләп, муен, беләзек һәм ашык сөякләрен каплап йөргән.

ОЗЫН КҮЛМӘК – ПРИНЦЕССАЛАР ӨЧЕН ГЕНӘ

– Безнең бинада өченче катта фитнес-клуб бар. Лифт көткәндә, спорт сумкалары күтәргән, мини-итәк, шорты кигән матур кызлар безнең күлмәкләрне карый, фотога төшерә. Кызлар күңеле гүзәллеккә тартыла. Һәм тренировкадан соң һәркайсы диярлек безнең кибеткә керми калмый. Бөтен кызларның да принцесса кебек матур буласы килә бит.

Зарина Бабаджанованы ел саен мөселман киносы фестиваленә чакыралар. Оештыручылар аның киемнәре аша кунакларга халкыбызның мәдәниятен күрсәтергә тели. Үз милләтенең кадерен белгән кешеләрне Зарина аеруча үз итә:

– Мода аша мин традицияләрне торгызуга үз өлешемне кертәм, – ди ул. – Хәзер милли мотивларның шулай популярлашуы миңа бик ошый. Бу футболкаларда, башлыкларда, сумкаларда булсын! Бик шәп бит бу! Хәзер Татарстанга бик күп кунак, туристлар килә, аларга үз мәдәниятебезне күрсәтү зарур. Кроссовкаларда да, бейсболкаларда да милли бизәк булсын, шундый обойлар ясасыннар. Әмма кешеләрнең, нәрсә икәнен дә белмичә, түбәтәй алып китүе генә кирәк түгел, алар безнең мәдәниятебез җәүһәрләре белән танышса һәм аның бер өлешен үзләренең күңелендә алып китсә, ничек яхшы булыр иде!

Реклама.



ТАТАР БИЗӘКЛӘРЕ КҮҢЕЛГӘ ЯКЫН

Роза Әдиятуллина, «Татарлар» тапшыруының алып баручысы:

– 2014 елда мин Islamic Clothes бәйгесен алып бардым, һәм мине Заринаның оригиналь киемнәре әсир итте. Бу озын күлмәкләр сине бик матур күрсәтеп кенә калмый, алар синең дөньяга мөнәсәбәтеңне дә үзгәртә бит – кешеләргә ихтирамлырак була башлыйсың. Үзеңне 100 процентка хатын-кыз итеп тоясың.

Хәзер мондый киемне көн саен киеп йөреп була, элегрәк исә намаз укыган мөслимәләр генә шулай киенә иде. Бүген исә бу трендта һәм күп кызларга ошый. Мин кайвакыт чалма киеп йөрим, бу мода да безнең Татарстанда гына түгел, бәлки бөтен дөньяда күзәтелә.

Мин мөселман, мәчеткә йөрим, әмма әлегә намаз укымыйм. Кайвакыт кыска итәк яки чалбар да кия алам. Тик мин озын күлмәк киюгә үк үземне бөтенләй башкача хис итә башлыйм.

Безнең Татарстанда пөхтәлек һәрвакыт макталган. Мөслимәләр дә ачык төстәге киемнәрдән йөрде, әмма бу күлмәкләр барысы да бер төслерәк иде. Шунлыктан хәзер дизайнерларның мөселман киемнәренә зур игътибар бирүе, татар бизәкләренә акцент ясавы бигрәк тә рәхәт. Һәр бизәкнең үз мәгънәсе бар бит. Һәм моның көннән-көн күбрәк таралуы без татарларны аеруча сөендерә. Минем гардеробта дизайнерларның татар символикалы, милли колоритлы жилетлары бар, алар бик оригиналь күренә. Аларга гашыйк булмый мөмкин түгел. Һәм мин мондый бизәк төшерелгән кием кигәнмен икән, милли бизәкләре безнең матурлыгын күрсәтер өчен генә кимим, бәлки үземнең татар булуымны күрсәтер, үз милләтем белән горурланыр өчен киям. Һәм мин мондый киемнәрне кигәндә, күбәләктәй очам, үз-үземә ышанычым күпкә арта. Үзеңдә газиз халкыңның күп гасырлык тарихын тоясың, ул сиңа үтеп керә, горурландыра. Тагын үзеңне модалы киенгән кеше итеп кенә түгел, гүзәллекнең, милләтнең бер кисәкчеге итеп тә тоясың.

PRESSA.RU

СӘНГАТЬ ӘСӘРЕ
БУЛАРАК ЧИТЕК

Милли колоритлы мода турында сүз башланган икән, биредә инде модельле туфлиләр белән генә булмый. Милли костюмга чәмчәле читекләр яки чүәкләр дә кирәк. Шуларны эзләп, күн мозаикасыннан уникаль аяк киеме тегүчеләр янына киттек. Илдус Гайнетдинов хатыны Әлфия Артемьева белән үзләренә шундый максат куйган – татар милли кәсебен саклап калу һәм торгызу.

Реклама.

Мозаик аяк киеме күн кисәкләреннән уникаль, башка халыклар сәнгатендә очрамый торган кул җөе техникасында ефәк, алтын һәм көмеш җепләр кулланып тегелә.

ҺӘР ПАРЫ БЕРДӘНБЕР

– Мин бу кәсеп белән 1977 елдан, Арча фабрикасында эшләгән чагымнан алып шөгыльләнәм, – дип исенә төшерә Илдус Гайнетдинов. – Әмма мондый аяк киеме конвейерда әзерләнергә тиеш түгел. Әгәр аны механик әзерләүгә кайтарып калдырсаң, мондый матурлык килеп чыкмый. Һәр пар – бердәнбер. Аңа чигүче үзенең күңелен куша. Чиккәнче дә әллә никадәр эш эшләргә кирәк: модель уйлап табу, бизәк, өлге, төрле төстәге күн сайлау. Һәр читек – сәнгать әсәре ул. Кызганычка, бик кыйммәтле әсәр түгел. Күлдан эшләнгән читекләр уртача 10 меңнән 27 мең сумга кадәр тора. Чүәк һәм туфлиләр исә – 1600 дән 4 мең сумга кадәр. Европада мондый аяк киемнәренең бәясе 500 евродан башлана.

ТАТАРЛАР ГЫНА КҮННЕ ВАК КИСӘКЛӘРГӘ ТУРЫЙ

– Башта күнне вак кисәкләргә турап, аннары кулдан тегү белән татарлардан кала башка беркем дә шөгыльләнми. Менталитет үзенчәлеге, – дип горурланып күрсәтә вак күн кисәкләрен Әлфия Артемьева. – Без барыбыз да бөтен нәрсәне эшли беләбез, әмма кемнең күңеленә нәрсә якынрак, шуның белән шөгыльләнәбез. Илдус Хаҗимулла улы – искиткеч бизәкче, белеме дә, үзенең эчтән тоемлавы да менә дигән. Мин күбрәк төсләр белән эшлим. Ниндидер сорау туса, бергәләп тикшерәбез, планлаштырабыз... Бик тиз кирәк булганда, без төн эчендә яңа аяк киеме тегеп өлгертә алабыз.

ИДЕЯЛӘР КОСМОСТАН КИЛӘ

– Һәр бизәккә мәгънә салынган, – ди Илдус. – Мәгънәсез берничек тә булмый. Мин күңелем теләгән рәсемне ясыйм. Идеяләр космостан килә...

Әлфия төрле төс, форма һәм үлчәмнәрдән күргәзмәгә дип ясаган беренче коллекцияләренең «мизгел эчендә сатылуын» искә төшерә.

Фото: Ната Смирнова



«ИҖАТЫМ БЕЛӘН БАЙМЫН»

Кәсепчеләр үз эшләреннән күргәзмә оештыру турында хыяллана. Әмма әлегә килеп чыкмый, «җитештерү бөтен нәрсәне йотып бара».

– Бөтен керемне үсешкә тотабыз. Олы улыбыз безгә кушылды инде, сумкалар белән шөгыльләнә. Кечесе дә әкренләп кул арасына керә. Бәлки, алар безнең кәсепне гөрләтеп эшләтә алыр, – дип хыяллана әти-әни.

– Миннән еш кына, син баймы, дип сорыйлар, – дип йомгаклый әңгәмәбезне Илдус. – Мин болай җавап бирәм: миңа бөтен нәрсә җитә. Минем күңелем бай, мин үземнең иҗатым белән баймын.

Реклама.

– Минем бурыч татар милли аяк киемен популярлаштыру иде, – ди ул. – Гәрчә күпләр миңа, үз тамырларыннан оялгандай, миллигә охшатып кына ясарга да киңәш биргәләде. Ә без үз бизәкләребезне бик матур, дип саныйбыз. Һәм әгәр дөрес калыпта, дөрес төстә һәм дөрес концепция белән тексәң, бу менә дигән модалы читекләр булып чыга. Мин әйбернең аутентик нигездә, әмма заманча булуын теләдем.

КӨНДӘШЛӘР ЮК

– Безнең эш уңышлы гына көйләнеп киткәч, халык уяна, бу бик җиңел, дип уйлый башлады. Әмма ничек уяндылар, аннары шулай йокыга да киттеләр, – дип елмая Илдус, ул вакыттагы көндәшләрне исенә төшереп. – Кешеләрнең түземлеге җитми. Бу бик катлаулы. Мин һәрвакыт авыл белән элемтәдә торам. Без читек торган урында бу – геннар дәрәҗәсендә – мондый эшне һәр йортта күп еллар буе башкарганнар. Бу бик керемле җитештерү түгел, тиз арада акча эшләп булмый. Без көнне төнгә ялгап, ялсыз эшлибез, аннан соң гына нәтиҗәсе күренә. Кешеләргә исә бик тиз арада һәм бик күп керем алу кирәк. Барысы да уйлый: менә, китаптан бизәк күчереп алган да, чиккән. Безнең бик җиңел һәм гади бизәкләребез дә, бик катлаулылары да була. Һәр чәчәкне, һәр төенне җентекләп эшләргә, гармонияле күренсен өчен, һәркайсының үз урынын табарга кирәк.

Бервакыт минем яныма булачак эшкуарларның берсе килде дә, читек торган бер машинаны сатуымны сорады. «Әлбәттә. Менә минем читекчеләремнең берсе пенсиягә чыгарга җыена, сөйләшсәң, бәлки ризалашыр,» – дим. Ул егылып китә язды. Ул боларның барысы да кулдан эшләнүен күз алдына да китерә алмаган. Аның бизнес-планы да әзер булган үзе, тик барып кына чыкмады.

АЯК КИЕМЕННӘН КҮЗЛЕК САВЫТЫНА КАДӘР

Үзенең барып чыкмаган көндәшләрен көлемсерәп искә алса да, Илдус заказларның көннән-көн арта баруын, үзләренең генә өлгерә алмауларын танырга мәҗбүр. Хәзер базарга охшаш брендларның чыгуы бер дә начар нәрсә түгел. Аяк киеме генә түгел, панно һәм җиһазлар да ясарга туры килә икән. Милли символикага ихтыяҗ бөтен тармакларда да үсә.

– Кол Шәриф мәчетендә без пуфиклар һәм банкеткаларны ясадык, – дип санап китә Илдус. – Камал театрында, «Туган авылым» комплексында... Татар бизәкле галантерея – сумкалар, күзлек савытлары, әйбер тышлары җитештерәбез. Мондый әйберләр уникаль, теләсә кемгә бүләк итеп була. Бу – VIP-бүләкләр. Алар бөтен дөньяга тарала.



PRESSA.RU

МИНИАТЮРАДАГЫ
МИЛЛИ МАТУРЛЫК

Шундый үзенчәлек күзәтелә: Казанның модалы кызлары бәләкәй түбәтәй кия башлады. Бу миниатюр матурлыкны Миләүшә Мусина ясый.

Миләүшәнең үз ательесы бар, аңа ул әбисенең әнисе Миңлениса исеменнән алып MISA дип кушкан. Миңлениcаның тегү машинасы гаиләдә хәзер дә саклана, ул ирсез калган әбисенә балаларын ачтан үтерми калырга булышкан. Миләүшә һәрвакыт замана кызларының гардеробында милли символикалы әйберләр булсын иде, дип хыялланган – һәм менә аның кәләпүшләре популярлык казанган инде. Кызлар таҗ кебек түбәтәй киеп төшкән фотоларын социаль челтәрләргә куярга ярата, шулай итеп оста дизайнерның клиентлары гел арта бара, татар модасы популярлаша.

Реклама.



САРМАН
ФУТБОЛКАЛАРЫ

Татар мотивлары – һәрвакытта да кыйммәтле киемнәр генә түгел. Аларның кайберләре гади халык алырлык арзан да, шул ук вакытта матур да. Мондый урынны без Сарманда таптык – Алия Нәфыйкованың яңа һәм яшьләрчә бренды үзендә гади көндәлек киемне һәм милли колоритны берләштерә.

– 2015 елның маенда, әле студент чагымда, мин практика үттем, – дип сөйли бу гади футболкаларның авторы Алия Нәфыйкова. – Анда мин татар бизәге белән кызыксына башладым. Үз халкымның мәдәнияте белән илһамланып, мин үзем дә нәрсәдер уйлап табарга булдым. Һәм татар милли бизәкле футболкаларда тукталдым. Минем һәрвакыт үземнең йөрәгемә якын, оригиналь эш белән шөгыльләнәсем килә иде, һәм татар бизәгенә мәхәббәт миңа хыялымны тормышка ашырырга булышты. Минем өчен болар барысы да – татар символикасы, бизәкләре, борынгы халык җырлары бик якын, алар мине дәртләндерә.

Яшь-яшь кенә булса да, Алиянең хыяллары бик зур. Ул үз бренды киемнәренең һәр гардеробта булуын тели. Идеяләре белән интернетта теләп уртаклаша. Анда аның иҗатына мөкиббәннәр дә, милли колоритлы футболка сатып алырга теләүчеләр дә байтак.

– Татар дизайнлы кием-салым һәм аксессуарларның трендта булуы бик шәп, – ди Алия. – Элегрәк масс-маркетлар бер типтагы киемнәр тәкъдим итә иде, ә кешеләрнең үз күңелләренә ятышлы әйбер киясе килә бит. Милли колоритлы кием, «үзебезнеке» булганга, җанны җылытырга сәләтле.

#МОЙТАТАРСТАН

Татар бизәге кием тегүгә генә илһамландырмый. Дизайнер Ринат Сәфәров, мәсәлән, аларны кружка, оекбаш, телефон чехолларына төшерә...

Аны релакс-буягычларга, блокнотларга, картиналарга «үреп кертә», аңардан хәрефләр һәм, безнең татарстанлылар йөрәгенә аеруча якын булганы, #МИНЕМ РЕСПУБЛИКАМ принтларын ясый – анда һәр шәһәр исеме милли бизәкләр белән язылган. Менә ул, гамәлдәге чын ватанпәрвәрлек! Ринат туган ягының мирасын социаль челтәрләрдә данлый һәм саклый бит – тамырлары белән горурлана, аның дизайнерлык миссиясе шунда.



Ләйсән Хаҗиева,
«Ләйсән сәйләннәре» милли татар киемнәре коллекциясе модельеры:

– Моннан 100 ел элек без үзебезнең милли костюмны югалтканбыз. Ул бары тик китапларда, әбиләр хәтерендә генә калган. Асылда, хәзер ул юк. Татар милли киеме стилендә эшләнгән костюмнарны, кызганыч ки, бүген без сәхнәдәге артистларда гына күрә алабыз. Һәм мин аны торгызырга, заманчалаштырырга, стильләштерергә маташам. Без аны, оялмыйча, көн саен киеп йөрерлек булсын иде.

Зөлфәт Зиннуров,
эстрада җырчысы, телевидение алып баручысы:

– Безнең олимпиячеләрнең спорт киемнәре коллекциясе моңа күрсәтмә иллюстрация була ала. Аны бүген президент, төбәк җитәкчесе, мэрлардан башлап гади кешеләргә кадәр барысы да кия. Минем фикеремчә, республика җитәкчеләре, танылган кешеләр популярлаштыруда катнашмаса, милли киемнең киләчәге өметле булмаячак. Шәхсән мин үзем милли киемне бик рәхәтләнеп киеп йөрер идем.

Разил Вәлиев, Татарстан
Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе:

– Атаклы татар мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗани, милләтне саклау өчен, аның телен, гореф-гадәтләрен, көйләрен, җырларын, ашларын һәм шул исәптән киемен дә саклау зарур, дип санаган. Һәм без боларның барысын да саклау өчен шартлар тудырырга тиеш. Безне дә, әйтемдәге кебек, татар киеме буенча каршы алсыннар, тик татар акылы буенча озатсыннар иде...
Милли кием көне булдыруны республика җитәкчелеге хуплый. Аны үткәрү көнен генә билгелисе калды. Ихтимал, бу 30 августта булыр. Республика бәйрәменә Татарстанда яшәүче барлык милләт вәкилләре үз милли киемнәреннән килсә ничек матур буласын күз алдына китерәсезме?!

Реклама.

PRESSA.RU



КИТАП МИННӘН КЕШЕ ЯСАДЫ

Язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе, ТР ФАнең Шәрәфле академигы Ягъсуф Шафиков исеме «Татарстан» журналы укучыларына яхшы таныш. 1998–2012 елларда ул бездә бүлек редакторы булып эшләде. Журнал битләрендә басылган хикәя, повестьлары укучылар тарафыннан һәрчак зур кызыксыну белән кабул ителде. Ягъсуф әфәнденең «Кто водрузил Знамя Победы над Рейхстагом?» китабы «Ел китабы» республика бәйгесендә җиңүен ишеткәч, редакциябез белән чын күңелдән шатландык. Шунда ук аңарга Татарстан Президентының Рәхмәт хаты да тапшырылды. Бу сандагы «Китап киштәсе»ндә сүзне Ягъсуф Шафиковка бирәбез.





«АК ТАПЛАР»НЫ ЮК ИТӘСЕМ КИЛДЕ

– Китапны язарга мине тарихтагы «ак таплар»ны юк итәсе килү теләге этәргәндер, мөгаен. Ә татар тарихында андыйлар җитәрлек. Борынгы түгел, әле яңарак кына тарихыбызда да хәтта.

Узган гасырның 80нче елларына кадәр нәшер ителгән барлык тарих дәреслекләрендә дә, белешмә, энциклопедияләрдә дә дөреслеккә бик үк туры килеп җитми торган факт күрсәтелеп килде: «1945 елның 30 апрелендә Гитлер цитаделе Рейхстаг өстендә, ниһаять, пулялар тишкәләп бетергән һәм дары исе аңкып торган Җиңү Байрагы җилферди башлады. Аны Рейхстаг түбәсенә сержант М.А. Егоров белән кече сержант М.В. Кантария алып менеп беркетте...»

Әлеге вакыйганың шаһитлары сөйләгәннәргә, сакланып калган документларга һәм хәрби архивлардагы фәрманнарга нигезләнеп, шуны әйтә алам: әйе, Михаил Егоров та, Мелитон Кантария да Рейхстаг түбәсенә байрак кадаганнар. Ләкин алар беренче булмаганнар.

Әйтергә кирәк, Егоров белән Кантария үзләре дә истәлекләрендә Рейхстагны штурмлаучылар арасында беренче рәтләрдә булмаулары хакында әйтәләр. Алар инде штурмланган бина эченә кергәннәр.

Ә аңлашылмаучанлык килеп чыгуга полковник В.Шатилов җитәкчелек иткән 150нче укчы дивизия командирыннан киткән хәбәр сәбәпче була. 30 апрельдә 14.25 сәгатьтә минем гаскәрем Рейхстагның көньяк өлешенә Җиңү Байрагын урнаштырды, диелгән ул хәбәрдә. Әмма бу доклад иртәрәк җибәрелгән булып чыга.

Шулай да хәбәр инде Г.Жуковка барып ирешә, ул аны Сталинга үзе хәбәр итә. Совинформбюро сводкаларына барып эләгә анна-

PRESSA.RU

ры сөенечле яңалык. 1945 елның 30 апреле кичендә инде радиотөеннәр аша бөтен совет халкына ук барып ирешә. Әмма чынлыкта әле Рейхстаг тирәсендә коточкыч авыр сугышлар бара. Аның түбәсенә солдатларның бер өлеше бары тик төнгә генә менеп җитә. Һәм, аңлашыла инде, солдатлар белән бергә – байраклар да.

136нчы артиллерия бригадасының хәрби журналында 1.05.1945 каршы төндә мондый язма теркәлгән: «Бригаданың разведчиклары, башында сержант Г.Заһитов торган хәлдә, беренчеләрдән булып Берлин өстенә безнең Кызыл Байракны беркетте». Шул ук 1 майда Газетдин Казыйхан улы Заһитовны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәргә әзерләүләре турында язалар. Сугышчан батырлыкны тасвирлый торган графада болай диелгән: «Безнең гаскәрләр Берлинга – Рейхстагка якынлашканда Заһитов иптәш Рейхстагны штурмлау һәм аның түбәсенә Җиңү Байрагын беркетүдә катнашырга үзе инициатива белдерде. 1945 елның 26 апрелендә сержант Минин, өлкән сержант Бобров, өлкән сержант Лисименко белән бергәләп сугышчан йөкләмәне үтәргә юнәлде ул».

Заһитов Рейхстагка иң беренче бәреп керүчеләрдән була. Сержант Минин белән алар Рейхстаг түбәсенә күтәреләләр һәм байракны беркетәләр. Төнлә байракны караганда, Заһитовның күкрәге җәрәхәтләнә, күкрәк кесәсендә йөргән партбилетын ядрә тишеп үтә. Әмма яралы килеш тә ул үз бурычын ахыргача үти.

«Рейхстагны штурмалаганда күрсәткән сугышчан батырлыгы, кыюлыгы һәм геройлыгы өчен Заһитов иптәш Советлар Союзы Герое исемен алырга лаеклы».

РАД 136 АПАРКВ
командиры майор Максимов.
1 май, 1945 ел, Берлин.

– Укыган китапларымның барысын да яратып укыдым һәм укыганнан соң да, гомер буена яратуымны дәвам итәм. Алар миннән кеше ясадылар, ничек яратмыйсың инде аларны, әй?! Минемчә, дусларга, туганнарга бүләк ясаганда, китап – иң шәп бүләк. Хәзерге буынның китапка салкын каравы күңелне тырный, билгеле. Интернет кешене үзенә йотты. Андагы «китаплар» чын китапны алыштыра аламыни?! Ул «китап»ларның бит исе, тәме юк. Битләре, күпме кеше тарафыннан укылганын күрсәтеп, бөтәрләнеп тормый. Типография исе турында әйтәсе дә юк инде...

Әмма Заһитовка да, Мининга да бу исемне алу насыйп булмый. Татар егетенең бу геройлыгы турында озак еллар телгә дә алынмады. Сугыштан соң, Заһитов туган якларына әйләнеп кайта. Гади колхозчы булып эшли. Аннары аны авыл советы председателе итеп сайлап куялар. Якташлары аның турындагы истәлекләрне кадерләп саклый.

Бу китап Бөек Ватан сугышында фидакарьләрчә катнашкан ир-егетләрнең һәм туташ-ханымнарның якты истәлегенә багышлап язылды. Тыл хезмәтчәннәре, сугыш чоры балалары истәлегенә дә. Бөек Җиңүнең 70 еллыгына әзер булып, басылып чыгуы да – күңелле хәл. Бөтендөнья Татар Конгрессы аны читтә яшәүче татарларга таратырга ярдәм итте. Хәзер китапны Россиядәге генә түгел, ә чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән Германиядәге татарлар да укый ала.

КИЛӘЛӘР ДӘ... ГАҖӘПЛӘНӘЛӘР!

Язу эше белән шөгыльләнүче кеше өчен китапханә ул – гаять әһәмиятле урын. Өйдә аны «иҗат, эш кабинеты» алмаштыра. Минем өйдәге 45 кв. метр мәйданы булган кабинетның өч як стенасын да китап шкафлары биләп тора. Китапларның олы бер өлешен совет язучыларының татар һәм рус телләрендәге классик әсәрләре тәшкил итә, икенче өлешен – чит ил язучыларының рус теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре. Тагын бер бик мөһим өлеше – ул белешмәләр һәм энциклопедияләр. Алардан башка һич мөмкин түгел.

Иң төп игътибарны алып утыручы, әлбәттә, 30 томлы «Зур совет энциклопедиясе». Минем зур горурлыгым булган басмалар: 15 томлы Бөтендөнья тарихы, 10 томлык Оксфорд энциклопедиясе, Н.М. Карамзинның 6 томлы «История государства российского» басмасы, 15 томлы «История династии Романовых», «Татар тарихы», «Татар энциклопедиясе»...

Эш кабинетыма кергән кешеләрне иң гаҗәпләндергәне – Брокгауз белән Ефронның 86 томлыгы. Бу хәзинәне хәтта зур шәһәрләрнең китапханәләрендә дә һәрчак очратып булмый. Сирәк басмаларның берсенә әверелеп бара ул.

АВЫЛНЫҢ «ПУШКИНЫ»

Әтиебез, яраланып, 1942 елның җәендә авылга әйләнеп кайтты. Бу – Актаныш районының Түбән Карач авылы. Чип-чиста татар авылы бит инде! Казанга кайтышлый, Питердан килүче бер гаиләне үзе белән ияртеп кәтте: Акулина исемле апаны һәм аның кызларын.

Бездә алар Ленинград блокадасы өзелгәнче, 1944 елга кадәр яшәделәр. Үзләре белән бердәнбер китаплары бар иде – Александр Пушкин җыентыгы. Кызлар мине шул китап буенча тырыша-тырыша рус теленә өйрәтергә керешә. Мин, алты яшьлек татар малае, берничә көн эчендә рус телендәге шигырьләрне шартлатып яттан сөйли башладым. Шуңа да беренче китабым дип Пушкинның «Избранное»сын атый алам.

Кичләрен безнең капка төбенә яшьләр җыела иде. Берсендә чыктым да, кулларымны болгый-болгый, аларга шигырь укып җибәрдем:

Я помню чудное мгновенье:
Передо мной явилась ты,
Как мимолетное виденье,
Как гений чистой красоты...

Болар башта аптырабрак калды. Аннары и көлделәр миннән: «Ни сөйләнә соң бу», янәсе. «Пушкин бит бу», – дим.

Шулай итеп авылда миңа «Пушкин» кушаматы тагылып калды. Акулина апа белән кызлары Ленинградка кайтып киткәнче, авылның Пушкины булып йөрдем.

Әнием бик укымышлы кеше иде, мәгърифәтле, дини гаиләдән. Кечкенәдән Изге Коръәнне өйрәндем, татарча китаплар укып үстем. «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары». – **Ред.**) журналын алдыралар иде өйгә. Тукайны шуннан укыдым, Габдрахман Әпсәләмовны...



– Дәү әнием Бибәсма Актаныш ягында бик танылган абыстай булган. Нәкъ менә ул мине Ягъсуф дип атаган. Бу исем Коръәндәге Йосыфка аваздаш, тамырдаш исем. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыфы» шуңа аеруча кадерле миңа.

КОЛЫМА, КОЛБАСА ҺӘМ ЧИТ ИЛ КЛАССИКАСЫ

1948 елда фронтовик әтиемне – авылның колхоз председателен – ачлыктан җәфаланган авылдашларына бер тонна бодай калдыгын бүлеп биргәне өчен 10 елга Колымага озаттылар. Мин ул чакта күрше авылда 7нче классны тәмамлап килә идем. Колхозда атка йөк төяүче булып урнаштым.

1952 елда мин, унбиш яшьлек «колхозчы», өч туганым һәм әниебез, 100 км ераклыктагы күрше Сарапулга күченергә мәҗбүр булдык. Җәен ит комбинатында атка йөк төяүче булып эшли идем, кышларын – колбаса цехында ыслаучы ярдәмчесе булып. Төннәрен элеккеге фронтовик Яковлев белән колбаса ыслыйбыз. Мин зирек утыны ташып, ыслар өчен махсус учаклар тергезәм.

Шулай берсендә, төнге икеләр тирәсендә, ял итеп алырга булдык. Яңа гына ысланган исниткеч тәмле колбасадан авыз итәбез. Шулчак Яковлев әйтә: «Яша, – ди, – әйбәт малай син, нишләп кичке мәктәпкә йөрмисең?»

– Оялам, – дим.

Нәрсәдән ояласың, – ди Яковлев, гаҗәпләнеп.

Русча начар сөйләшәм…

Ә син русча китапларны кычкырып укы, шулай итсәң, бик тиз өйрәнерсең, – ди бу миңа.

Рус китаплары юк бит миндә. Татарчалары да авылда калды, – дим.

Шунда минем «шеф» уйга калды. «Ярар, иртәгә мин сиңа алып килермен», – диде үзе.

Икенче көнне ул миңа Вячеслав Шишковның «Угрюм-река» дигән гаҗәеп калын китабын алып килде. Беренче томын. Мин аны бөтен колбаса цехын янгыратып, атна эчендә укып чыктым. Аннары Яковлев икенче томын да китерде…

Көзен мин кичке мәктәпнең 8нче классына укырга бардым. Ике айдан армиягә алдылар. Ә минем язуым бик матур иде. Шулай итеп штабка писарь булып эләктем. Штабның иң зур байлыгы – рус телендәге бик шәп китапханә иде. Җитәкчем генерал-майор Коломийц юк чакта мин ул китапларны йотлыга-йотлыга укыйм. Чак кына бушасам, эш өстәленең ящигына яшереп куелган китап дөньясына чумам. Ике ел эчендә шулай, кача-поса, рус телендәге бөтен чит ил классикасын диярлек укып чыктым.

Шулай да берсендә тотылдым. Генерал штабта түгел чакта Ги де Мопассанны укый башладым да, онытылып киткәнмен. Кинәт кемдер алдымнан китабымны тартып ала. Карасам – генерал!

Ул рәсемнәр белән бизәлгән Мопассанны актарып чыкты да, миңа әйтә:

– Ай-һай, сержант, көпә-көндез, эш вакытында бозык романнар укып утыру килешә торган эш түгел…

Русча күп уку телемне генә шомартып калмады, ә грамоталы итеп рус телендә язарга да өйрәтте. Бу исә миңа киләчәктә тормышта югалмаска булышты.

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ



«Татарстан» журналының әдәби премиясе

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм «Татарстан» журналы әдәби премиягә бәйге игълан итә

«Татарстан» журналы әдәби премиясе Татарстан матур әдәбиятына сизелерлек өлеш керткән әдәби әсәрләр иҗат итүче авторларны барлау һәм иҗатларына игътибарны арттыру максатыннан игълан ителде.

Премиягә түбәндәге жанрларда иҗат ителгән кульязмалар дәгъва итә ала: роман, повесть, хикәяләр циклы. **Әсәрләрнең Татарстан турында яки Татарстан авторы тарафыннан иҗат ителгән һәм моңарчы беркайда да басылмаган булуы – бәйгенең төп шарты!**

Кульязмалар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә – русча һәм татарча – кабул ителә.

2017 ел дәвамында «Татарстан» журналы Экспертлар советы тарафыннан сайлап алынган текстларны журнал битләрендә һәм журнал сайтында protatarstan.ru басылып барачак.

Гран-при – китабыгызның басылып чыгуы.

2017 елның декабрендә бәйгенең жюрие ике телдә иҗат ителгән әсәрләр арасыннан җиңүчеләрне сайлап алачак – татар телендә бер әсәр һәм рус телендә бер әсәр. Икесе дә китап булып басылып чыгачаклар.

Бәйгенең шартлары:

1. Кульязманың электрон версиясе.
2. Номинант турында мәгълүмат – әсәр авторының фамилиясе, исеме, атасының исеме, контактлары – белешмә өчен телефоны, адресы).
3. Авторның кыскача иҗади биографиясе (әгәр әдәби әсәр берничә автор тарафыннан иҗат ителгән булса, һәрберсенеке).
4. Әсәрнең синопсисы.

Кульязма таләп ителгән материалларның тулы пакеты белән килмәгән очракта, жюри рәисе әсәрне кабул итмәскә хокуклы.

Кульязмалар tatarstan@tatmedia.com электрон тартмасына «КОНКУРСКА» тамгасы белән кабул ителә.

Конкурсны уткәрү вакыты 2017 елның 19 гыйнварыннан 2017 елның 15 декабренә кадәр.

Тулырак мәгълүмат protatarstan.ru сайтында.

Педагог-журналист, тәрҗемәче, Татарстан журналистлар берлеге әгъзасы, «Синең хакка гына түзелгән» дип исемләнгән шигырь китабы, йөзгә якын хикәя һәм дистәдән артык повесть авторы Хәмидә Гарипова Казанда яши, лаеклы ялда булса да, вакытлы матбугатта активлыгын югалтмый, әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Сезнең игътибарга аның яңа әсәрен тәкъдим итәбез.

Хәмидә Гарипова

АЛПАР
(ХИКӘЯ)

Борын астына яңа гына кара мыек төртеп чыккан чибәр-чая үсмернең, үз яшьтәшләренә хас чиктән тыш максимализм хисе белән януы өстенә, тумыштан гаярь һәм куркусыз Алпар нәселе дәвамчысы булуы үз эшен эшләде. Уналты яшьлек Гарәфетдин, газиз Ватанына ябырылган фашистларны аяусыз кырырга ашкынып, 1942 елның ноябрендә үзе теләп фронтка китте. Дөресрәге, шул ниятенә буйсынып, бүген төнлә яшертен генә ФЗӨ тулай торагыннан чыгып сызды. Төн карасына ышыкланып, фронтка юл тоткан хәрби составның соңгы вагоны түбәсенә үрмәләп менеп, җайлап урнашкач, колак өшеткеч салкын ачы җилгә аркан борылып утырды. Әтисеннән калган тирән эчле малахай бүрегенең колакчыннарын төшереп, киң маңгаена батырып киде, муенын җыерып, такыр башын, күптәннән вафат булган Алпар бабасының чабулары тузып чукланган, аркасы сизрәгән иске чикмәнен тарайтып, кыскартып, әнисе әмәлләп биргән юка бишмәтe эченә яшерде. Яшүсмернең ыжгырып алга томырылган паровоз җиленә исе китмәве, авырлыкларга бирешергә теләмәве әллә каян күренеп тора, салкыннан сыны катып, тешләре тешкә тиеп барабан какса да, ныгытып кысылган калын иреннәрендә, кара тутлы кырыс йөзендә тәвәккәллек төсмере шәйләнә иде.

– Барып кына җитим! Фрицларның бугазына тешем-тырнагым белән ябышам. Ата арысланнан ким сугышмам, – дип үзалдына сөйләнде ул. – Кансыз килмешәкләрнең оясын пыр туздырырмын!

Бераздан алҗуы җиткән Гарәфетдинне йокы баса башлады. Төшендә фашистларны җиңеп, туган авылы Кылчыклыга кайтып төшкәнен күрде. Калкандай киң күкрәген бизәп, күпсанлы орден-медальләре чыңлый, имеш. Аны каршыларга бөтен авыл халкы чыккан. Араларында аның йөрәген җилкендерүче башбирмәс Чыпчык Гайшәсе дә бар түгелме соң?! Һи, кыланчык көязбикә! Эре кыңгырау чәчәкләрен үреп, башына купшы такыя кигән. Үз итеп, елмаеп кул изи, имеш... Тәмле төш күрүче Гарәфетдиннең эчкерсез елмаюдан йөзе нурланды. Шул садә-сихри мәлдә, калын кара болытлар арасыннан көтмәгәндә килеп чыккан «Мессершмидт» ташлаган авыр бомбаның төнге тынлыкны ярып гөрселдәве серле-сәгадәтле минутны урталай кисеп узмаса, ымсындыргыч татлы төш мизгел эчендә кырыс өнгә әверелмәс иде кана. Елмайтучы фәрештәсе кай арада күз алдыннан гаип булды? Бәхет кошы әле генә кул сузымында, бик якында гына иде ләбаса. Офыкны кан төсенә манган дәһшәтле балкышка күзе төшкәч, тиздән фронт сызыгына якынлашачакларын чамалап, батырлыкка омтылган яшүсмернең йөрәге дулкынланып типте.

Әллә сез Гарәфетдин юкка гына бик нык хәвефле, озынозак юлга чыгарга тәвәккәлләгәндер, дисезме? Юкка гына аның кушаматы Куш йөрәк түгел лә. Сәбәпләре үтә дә саллы. Горур Алпар оныгының былтыр Мәскәү астында һәлак булган әтисе Гайнетдин өчен үч кайтарасы бар. Җитмәсә, чит-ят күзләрдән җиде кат йозак артына яшереп саклый торган, үзе генә белгән тагын бер кәттә сере бар.

Гарәфетдин, быелгы көздә калада укый башлады. Фабрика-завод өйрәнчекләренә бирелә торган кадерледән кадерле тәгамын – ике йөз илле граммлы арыш ипие сыныгы салынган азык-төлек паегының бер өлешен, иптәшләренә сиздермичә генә, тулай торакның җылыткыч торбасы артына яшереп, киптереп җыеп бара иде. Үз тамагы туеп җитмәсә дә, туган авылындагы салам түбәле иске йортта, үпкә чиреннән интегеп, үлле-мәлле хәлдә урын өстендә газапланып ятучы газиз әнкәсе Мәскүрә янында ачлыктан тилмереп, көч-хәлгә җан асраучы, берсеннән-берсе кечкенә, чандыр гәүдәле, ач яңаклы энекәшләре аның күз алдыннан китмәде. Дәү абый булып йөргән Гарәфетдин нарасыйлар ачлыктан өзлекмәсен, вакытыннан алда гомерләре киселмәсен дип, үз авызыннан өзеп, шуларга өлеш чыгара. Беркадәр мая тупланган, авылга кайтып, якыннарын сөендереп китә.

Соңгы мәртәбә туган төбәгенә аяк басуында, уйламаганда-көтмәгәндә, инеш өстендәге тар басмада арткы урамда яшәүче чытлыкый Гайшә белән юллары кисеште. Бер мизгел эчендә Гарәфетдингә әллә ни булды. Борын очы, уч төпләре тирләп чыкты. Гүя чалт аяз көндә, аның күңел күген балкытып, серле аҗаган камчысы җемелдәп узды. Уймак авызлы, көлгән чагында алсу бит очларында мәхәббәт чокырчыклары хасил була торган, кыңгырау чәчәге төсле зур зәңгәр күзле, биленә җиткән калын озын толымлы, башбирмәс чибәркәй Гайшәдән күзләрен ала алмыйча, тораташтай терәлеп катты ул. Ә ул хәерсез, су буен яңгыратып бер чыркылдап көлде дә, башын горур тотып, ап-ак беләкләрен алмалы көянтәсе өстенә сузып салган килеш, зәңгәр чиләкләре тулы тешеңне сындырырлык салкын чишмә суын чайпалдырмыйча, килешле билләрен матур уйнатып, кәс-кәс атлап, үзләре тыкрыгыннан менеп китте. Очрашканда, күрмәмешкә салышып, борынын чөеп узуын күр әле син аның, сер бирмәгән була, имеш. Тапкыр егетнең менә нинди асыл кошның мәхәббәтен яулап аласы бар!

***

Торбасыннан зәһәр төтен пошкыра-пошкыра, паровоз хәвефле маршрут буенча алга ыргылды. Изге максатына якынлашуын сизгәнгә күрә, әүвәлге мәлдә вагон түбәсеннән тирә-юньне кызыксынып күзәтеп барган Гарәфетдиннең сөенечтән күңеле мәтәлчек атты. Элек бергә укыган дуслары Никита, Сергей, Фоат инде икенче ай фронтта. Насыйп булса, күрешүләре ихтимал. Бергәләшеп тотынсак, фрицлардан он-талкан ясап, туган илебездән бик тиз куып чыгарырбыз, дип үсмерләрчә җиңел фикер йөртте ул.

Таң аткач, манзара алышынды, әйләнә-тирәдәге күренешләр канны катырырлык шыксыз, тормыш чынбарлыгы аяусыз иде. Кая карама убыр авызыдай ямьсез снаряд чокырлары, чәбәләнеп ауган агачлар, янып күмерләнгән баганалар. Җимерелгән бистә йортлары, таланган вокзаллар, мич торбалары гына тырпаеп торган, тулаем яндырылган авыллар янынннан узып китә башлагач, дөнья күрмәгән, хәтта балалыктан чыгып җитмәгән яшүсмернең күңеленә шом керде. Состав бер станциядә туктап, уттай кызган тәгәрмәч боксларын суыткан, вагоннардагы чаннарга су, юлда ягып барырга ташкүмер, утын тутырган чагында, дошман пулеметчылары туры наводка белән



тимер юл тирәсен утка тота башлады. Гарәфетдин, кичә үзе менеп кунаклаган «сәндерә»сеннән җәлт кенә җиргә сикереп төшеп, тиен җитезлегендә ишегә ачык бер вагон эченә кереп чумуын сизми дә калды. Ерак тылдагы оланнарын өзелеп сагынучы карт сугышчылар үсмерне куып төшермәде, киресенчә, аны полк улына санап, җылы кабул итте. Куе солы боткасы салып бирделәр, кайнар чәй белән сыйладылар. Кайгыртучан интендант Галимулла старшина, мәрхәмәт күрсәтеп, үсмергә җылы солдат бушлаты, сырган калын чалбар, өр-яңа аяк чолгаулары, күпне күргән киез итекләр табыштырды. Билен йолдызлы солдат каешы белән кысып бугач, ул киң күкрәкле, нык бәдәнле чын солдатка охшап куйды. Башкалар белән бергә утлы мәхшәр эченә юл алган Гарәфетдин, алда үзен нинди дәһшәтле хәлләр, зур сынаулар көткәнен күз алдына китерми иде әле.

***

Алгы сызыкка барып җиткәнче, зур привал булды. Ул фронтка яңа алынучылар белән бергә кыска сроклы хәрби әзерлек курслары үтте. Әүвәле сафта тигез атлап йөрергә, төз атарга, хәрби командаларны төгәл үтәргә, таныш түгел урында карта һәм компас ярдәмендә ориентлашырга, кирәкле объектны тиз арада эзләп табарга өйрәттеләр. Куркусыз Алпар оныгы, зиһенле, зирәк, искиткеч чыдам булып чыкты, хәрби әзерлек эшендә олылардан калышмаска омтылды. Сугышчан отрядта хәрби ант кабул иткән үткер Гарәфетдин, алгы сызыкта хәтәр хәлләргә тарыганда да югалып калмады. Разведрота командиры капитан Рябушкин, яшь булса да куркусыз, чыдам татар егетен үз күрде, күз уңыннан ычкындырмады. Аның немецча ярыйсы шәп сукалавын белеп алгач, «тел алу» операцияләрендә катнаштыра башлады. Дошман тылында четерекле сугышчан заданиеләрне уңышлы үтәп, караңгы төннәрдә хәвефле утлы тәбеләрдән ничәмә-ничә мәртәбә исән-имин котылдылар. Соңгы баруларында кармакка эләктереп кайткан симез «балык» күп нәрсәдән хәбәрдар булып чыкты. Штабс-капитан Ганс фон Элефантен, сугыш утында кырысланып, башкаларның җанын рәхимсез кыярга гаять остарып беткән булса да, үз гомерен саклап калу бәрабәренә, шактый әһәмиятле хәрби серне чиште. Аның планшетындагы кәттә картасын кулга төшерү разведротаның гына түгел, хәтта алгы сафтагы тулы бер полкның хәрби тактикасына сизелерлек үзгәреш кертте, безнекеләргә зур уңыш китерде. Командование җитәкчесе генерал Харламов, яшь дип тормады, әлеге мөһим операциядә катнашкан унҗиде яшьлек рядовой Гарәфетдин Алпаровны да «Батырлык өчен» медале белән бүләкләде. Сөенечтән егетнең түбәсе күккә тиде. Фронт газетендә аларның күмәк фотосы басылып чыкты. Ул шуны кисеп алып, өчпочмаклы хатка төреп, әнисенә салды. Яхшы хәбәр авылда күз ачып йомганчы таралды, газит кисәге кулдан кулга йөреп, таушалып бетте. Моңа Чыпчык Гайшәсе аеруча нык сөенде булса кирәк. Үткен-чая кыз «Пушты» Әминәдән Гарәфетдиннең адресын белеште дә, ике-өч авыз сүздән торган хат кисәге сырлап, кыю авылдашына юллады. «Булдыргансың, Куш йөрәк! Котлыйм! Гитлерның арт сабагын укыт! Исән йөреп, сау кайт!» – дигән сүзләрне укыгач, Гарәфетдин сөенечтән май кояшы кебек балкыды. Авыл белән ике арада сагынычлы хатлар йөри башлады. Тамчы, үзе нәни булса да, үҗәтләнеп бер урынга тып-тып тама торгач, каты ташны да тишә, диләр. Бер ел дигәндә, фронттан агылган назлы җылы сүзләр горур, башбирмәс Гайшәнең күңелен балавыз сыман эретте. Ул соңгы хатында батыр егетне көтәргә вәгъдә бирде. Егетнең бәхет капкасы киерелеп ачылды.

***

…Канкойгыч Севастополь оборонасы вакытында килеп чыккан бер күңелсез вакыйга, ут эчендә йөреп шомарып беткән Алпар оныгының көйле язмыш арбасын көтмәгәндә баштүбән әйләндереп каплады. Четерекле хәл көтмәгәндә хасыйл булды. Кара диңгез эчендәге бер утрауга җиде сугышчыдан торган десант төшереп, тау куышына яшерелгән корал складын сакларга боердылар. Разводящий кече лейтенант Пинчук гаскәриләрне утрау буйлап үзе таратты. Командирның ышандыруынча, караңгы төшкәч, аларны бередән үзебезнең катер кереп алачак. Дислокация урыны тау-таш арасында булганлыктан, сугышчылар бер-берсен күрү, үзара хәбәрләшү, ярдәмләшүдән мәхрүм иде. Һәркайсы үз позициясенә берегеп катты. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, десантчыларны мөһим операциягә әзерләп озатырга тиешле интендант хезмәтенең айнымас старшинасы Маргушаның сансызлыгы аркасында, төче сулы зур канистр, коры паек тутырылган юл капчыгы очкычка кертеп куелмаган, хәрәкәттәге хәрби берәмлекнең складында онытылып калган иде.

Алмаш ул төндә түгел, икенчесендә дә килмәде. Ә өченче көнне, вакыт төштән авышкач, ачлыктан бигрәк, сусызлыктан, баш миен кайнаткан кызу кояш астында интегүдән аңнарын югалтып егылган җиде сугышчыны, катерга төяп частька алып кайттылар. Аларның хәленә керүче булмады, киресенчә, күрәләтә нахак бәла тагып, кансыз «Смерш» офицеры, майор Гайдай кулына илтеп тапшырдылар. Шәхсән үзе дары исе иснәп карамаган, «штаб күсесе», фронтның диңгез яры буйлап дистәләрчә чакрымга сузылган алгы сызыгында каты бәрелешләр барган көннәрдә объектив рәвештә килеп туган катлаулы вазгыятьне анализлап маташмады. Коры җирдәге чиктән тыш хәтәр хәлләргә бәйле рәвештә, утрауда бүленеп калган десантчылар взводына алмашның ни өчен өч көнгә соңарып килүен ачыклауны кирәк дип санамады.

Юан корсаклы, мин-минлекле эшем иясе җирәнгән кыяфәт белән Алпар оныгы Гарәфетдиннең погоннарын умырып алып, аяк астына ыргытты. Әлеге зат егетнең түш кесәсенә кадерләп төреп салынган «Батырлык өчен» медален ирексезләп тартып алды. Ул, күзләреннән хәтәр утлар чәчеп, каршысында көч-хәлгә басып торган, чарасызлыктан хәсрәткә баткан, җаны-тәне үтереп сызлаган егетнең муен тамырына бала башы чаклы йодрыгы белән берне томырды. Гарәфетдин чайкалып куйды, әмма егылмады. Котырынган офицер, аты-юлы белән сүгенә-сүгенә, дагалы күн итеге белән кече сержант Алпаровның ике бот арасына китереп типте. Мизгел эчендә таш идәнгә капланып төшеп, ике учы белән касыгын тотып яман ыңгырашып, уңлы-сулы тәгәрәгән сугышчыны майор тамчы да кызганмады. Үз-үзеннән канәгать калып, түбәнсетелгән солдатка мыскыллы караш ташлады, лач иттереп битенә төкерде.

– Анагызны фәлән итим! Сатлык җаннар! Гитлер тегермәненә су коючы җирбитләр сез! Берни түгел, коралларны немецларга төяп җибәрергә алдан ук сүз куешкансыз! Арсеналны күз карасыдай саклыйсы урында, кәпә-көндез арт түңкәйтеп йоклап яткансыз! Сезне моның өчен трибунал үлем җәзасына тартачак! – дип зәһәрен чәчте.

Офицер ничаклы үҗәтләнеп рухи басым ясаса да, горур Алпар оныгы провакациягә бирешмәде, «N утравындагы коралларны үз теләгебез белән немецларга тапшырырга җыендык» дип язылган кәгазьгә кул куймады. Тәкәббер зат, гарьләнеп, корбанына янәдән явыз карчыга кебек ташланды һәм егетне, канга батырып, карцерга кертеп атты.

PRESSA.RU

***

Хәрби мәхкәмә карары кырыс булды. Бәхетсезлеккә юлыккан гаскәриләрне Ватанын саткан хаиннәргә тиңләштереп, унбишәр ел төрмә срогы чәпәделәр, ярый әле атып үтермәделәр. Богаулап, товар вагонына төяп, Себергә этаплап озаттылар. Бер ай дигәндә, уран руднигына китереп ташладылар. Фашист концлагерьлары мәхшәре аша үтеп, могҗиза белән исән калган бичара сәяси тоткыннар да биредә иза чигә икән. Кубесенең сәламәтлеге ташка үлчим. Монда килеп капкан бәхетсез җаннар, көнене ундүртәр-уналтышар сәгать зарарлы шахтада авыр хезмәттә интегүдән тыш, ачлыктан, чирләрдән, кыйналулардан чебен урынына кырылды. Гарәфетдинне илле ике яшьлек сәяси тоткын Вәкил абзый бригадасына беркеттеләр. Шахтага төшкәч, алар иңгә иң куеп эшләде. Берьюлы рудникта көтелмәгән хәл килеп туды. Штрек эчендәге беркетмә түшәм борыслары сынып төшеп, бер төркем мәхбус калын руда өеме астында калып изелде. Радиацияле шурфта бүленеп калган Гарәфетдинне бу юлыга Газраил бугазыннан буып алмаса да, котылуга өмет аз иде. Вәкил абзый, үз гомерен куркыныч астына куеп, бригадасындагы ышанычлы ике ирне үзе белән алып, янәдән аска төште. Азаплана торгач, развал өеме беркадәр чистартылды, тар тоннель хасил булды. Яшь егетнең гомере бетмәгәнгәдер, күрәсең. Ходайның рәхмәте белән үлемнән ярты адымда гына качып калган унтугыз яшьлек Алпар оныгының чем-кара чәчләре берничә сәгать эчендә чаларган иде. Шул көннән соң, Гарәфетдин үзенә икенче гомер бүләк иткән миһербанлы милләттәшен әтисе урынына күреп, аның белән якыннан аралаша башлады. Язылмаган канунга буйсынып, гадәттә, биредәгеләр артыгын сөйләшмиләр, үз эчләренә бикләнергә мәҗбүрләр. Артык ачылып китсәң, шымчыларның илтеп җиткерүе, үз башыңа бәла чакырып китерүең бар.

Колгадай озын буйлы, тумыштан нык бәдәнле, тере карашлы Вәкил абзыкайның үзенең дә монда килеп капканчы күрмәгәне калмаган икән. Зыялы Пенза татары Хәеров, яшь булса да, төпле булып күренгән Гарәфетдингә серен саклык белән чиште. Вәкил абзый, могҗиза белән Освенцим тәмугыннан качып котылып, хәрәкәттәге армиянең укчылар дивизиясен эзләп тапкан булган. Исән-имин үзебезнекеләргә килеп кушылуына сөенеп, мәхбүсләрне этләрдән талаткан, ачлыктан интектергән, аяусыз җәзалаган фашистлардан үч алу теләге белән янучы кичәге тоткынның кулына корал бирәсе урынга, аны трибунал хөкеменә тапшырып, хаин статусы такканнар һәм, радиацияле рудникка олактырып, әкренләп үлүгә дучар иткәннәр.

Гарәфетдин кебек изге ният белән, Туган илен, гаиләсен, якыннарын дошманнардан сакларга чыгып киткән чып-чын патриотлар, бер дигән совет кешеләре интегә иде биредә. Ә хәзер, адәм рисвае саналып, меңләгән бичаралар үз илендә иза чигә. Өйләрендә яраткан хатыннары, газиз балалары, гаҗизләктән вакытсыз картайган аналары, сөйгән ярлары әлегәчә өметләнеп-тилмереп көтәдер. Трибунал карары белән мәҗбүри рәвештә «хәбәрсез югалтылганнар»га якыннары белән хәбәрләшү тыелган иде. Алар – тере мәетләр, төрлесе төрле бәхетсез очрак, бөтенесе бергә – ил өстенә килгән коточкыч афәт, аяусыз сугыш корбаннары. Исемнәре дә, җисемнәре дә шушы юеш, салкын баракларда, радиацияле караңгы рудник эчләрендә мәңгелеккә югалып калырмы икәнни соң? Хәтта сугыш беткән очракта да, алар туган җирләренә башкалар кебек күкрәк киереп, җиңүче сыйфатында кайта алмас, күбесенә якыннары кочагына ташлану насыйп булмас инде. Шуларны уйлагач, чарасызлыктан Гарәфетдиннең мие кайнап чыгар дәрәҗәгә җитә, башы катып, тубалдай була. Вәкил ага диндар адәм иде, Гарәфетдингә догалар өйрәтте. Ходайга сыгыну икесенә дә рухи көч бирде.

Ниһаять, 1945 елның 9 мае таңы атты. Җиңү хәбәрен ишеткәч, амнистиягә өмет баглап, биредәгеләр чиксез куанышса да, сәяси мәхбүсләргә ирек капкалары тиз генә ачылмады. 1953 елда «милләтләр атасы» җан тәслим кылгач булып узган ярлыкау шаукымы, Гарәфетдиннәр руднигына ярты елдан соң гына килеп ирешә. Җәһәннәм газаплары кичереп кырысланган җаннар, күләгәдәй селкенүче ябык тәннәр, яралы язмышлы бәндәләр, бер-берсе белән саубуллашып, олыраклары – бәхилләшеп, СССР дигән иксез-чиксез зур Ватанның төрле почмакларына таралышты. Тоткынлык газаплары кичергәндә, гаярь Алпар оныгының тәне шактый гарипләнсә дә, тешләк егетнең көчле рухын мәхбүсләргә карата эттән яман кыланган НКВДчылар сындыра алмады. Бу нәселнең тамыры тумыштан нык иде. Гарәфетдин беркайчан да туган авылы Кылчыклының ипигә ягып ашарлык чем кара туфрагына аяк басудан өметен өзмәде. Иң авыр минутларында кыңгырау чәчәгедәй зәңгәр карашлы гүзәл Гайшәсен исенә төшереп юанды. Энеләрем исәйгәндер, әнкәйнең кул арасына керәләрдер, дип уйлады. Четерекле хәлләргә тарыганда, бер Ходайга сыгынганга, якыннары белән күрешүгә өмете өзелмәгәнгә, егетнең күңеле катып, җансыз ташка әверелмәде.

Сугышның беренче елында ук итәк тулы бала белән тол калган әнисенең хәсрәт утында көеп парә-парә телгәләнгән йөрәге өрлек кебек олы улының хәбәрсез югалуын күтәрә алмады. Мәскүрәнең гомер шәме сүнүгә, тома ятимнәрне ирексезләп төрле приютларга тараттылар. Гарәфетдингә бу хәлләрнең берсе дә мәгълүм түгел иде.

***

...1954 елның язгы аяз таңы беленгән мәлдә, чишмә тыкрыгы очындагы агач йортта ялгыз интегеп көн күрүче сазаган кыз-сыер савучы Гайшә бүген бик матур төш күрде. Алар сөйгән егете белән челтерәп аккан көмеш сулы Аныстау кизләве янындагы чирәмлектә утыралар икән. Җанынан артык яраткан Гарәфетдине, елмаеп күз кысып, аның чигүле алъяпкычы итәгенә алсуланып янып торган пар алма салды. Шул сусыл алмаларның берсен тешләп кабыйм дигән мәлдә, нидер сизенгәндәй, кыз дертләп уянып китте. «Төшеңдә су күрсәң – сөенечкә! Саф сулы чишмә – бәрәкәтле тигез гомергә ишарә бит ул! Берни түгел, бәгыркәем исән! Кайтыр юлга чыккандыр», – дип төшен яхшыга юрады ул. Түр тәрәзә өстендәге тар киштәдән, чигүле кульяулыкка таслап төреп куелган бер нәни төргәк алып төшеп, дистә елдан артык нәүмизләнеп, кирәге чыгуын моңаеп көтеп утыручы бирнә сандыгы өстенә җәеп салды. Кыз идәнгә тезләнде. Мәскүрә апасын мәңгелек йортына озаткан көнне, җыйнаулашып мәет чыккан өйне юган чагында, тәрәзә кашагасы артына кыстырылган җиреннән табып алып, кешегә сиздермичә генә алъяпкыч кесәсенә бөкләп тыккан кадерле ядкәргә ихластан елмаеп бакты. Саргаеп беткән фронт фотосыннан үзенә томырылып карап торган чибәр егетнең түгәрәк битен кытыршы бармак очлары белән сыйпап үтте, кыяр-кыймас кына көләч иреннәреннән назлап үпте. Гайшәнең зур зәңгәр күзләре дымланды, иркә кыңгырау чәчәкләреннән иртәнге саф чык бөртекләре мөлдерәп тамгандай булды. «Вәгъдә – иман! – дип, антымны бозмыйча, ничәмә-ничә ел өзелеп көтәм бит үзеңне! Тизрәк кайтып җитә күр инде, кыю бөркетем! Минем дә пар канатлы буласым, сине дә, үземне дә бәхетле итәсем, итәк тутырып балалар үстерәсем килә, – дип пышылдады кыз. – Ишетәсеңме, алтыным? Кайтмый калырга хакың юк! Кылчыклыга нигез салган гаярь Алпар бабай нәселен дәвам итәргә бурычлы бит без!»

Нәкъ шул нурлы иртәдә Кылчыклы урамына озын буйлы, киң җилкәсе ялалы кош канатыдай каерылып, гәүдәсе бер якка янтайган, яңаклары сулган, күзләре эчкә баткан, тешләре череп каралган, сулаганда үпкәсе гармун күрегедәй гыжылдап торган бер ир заты килеп керде. Туган нигезендәге җилкапканы киереп ачып, ашкынып ишегалдына узгач, ниргәләре бер якка авышкан иске өйнең ишегендәге күгәргән йозакны, моңсу тәрәзәләргә аркылы-торкылы кадакланган, череп мүкләнгән такталарны күргәч, коточкыч авыр озын-озак юл узып, җирсеп, туганнарын сагынып кайткан ир-егетнең тамак төбен ачыттырып, бугазына нәрсәдер килеп тыгылды, күзләренә яшь бөялде. Ул сәҗдәгә киткән сыман, яшел чирәмгә тезләнеп, туган туфрагына башын орды. Аннан соң, җитез генә кыланып, сикереп торды да, муртайган такталарны тиз-тиз каерып атты, борынгы йозакны күгәненнән суырып чыгарып, ышанычлы адымнар белән бусагадан эчкә узды.

Ул утны-суны кичкән, Бөек Җиңүгә үз өлешен керткән, хәтта тәмуг газапларына дучар ителгән чакта да иманы нык, намусы саф калган данлыклы көрәшчеләр токымының куркусыз бер Алпары – егерме сигез яшьлек Гарәфетдин иде...

Реклама

PRESSA.RU



ӘЛЕГЕ УКУ ЙОРТЫҺӘРВАКЫТТА РЕСПУБЛИКА ҺӘМ БАШКА ТӨБӘКЛӘРНЕҢ

ТУГАН ҖИРЕБЕЗ ӨЧЕН **ҖАВАПЛЫЛЫК ТОЕП**

Уку-укыту фермасы, Җир училищесы, Казан авыл хуҗалыгы институты – Россиянең иң өлкән вузы – Казан дәүләт аграр университетының озын тарихи үсеш юлы әнә шундый. Шушы еллар дәвамында вуз һәрвакыт Татарстан авыл хуҗалыгын кадрлар белән тәэмин итү бурычын үтәп барды. Хәзерге вакытта республиканың әлеге тармагы Россиядә әйдәп баручы позицияләрнең берсендә тора икән, монда Казан ДАУ ректоры Җәүдәт Фәйзрахманов җитәкчелегендәге укытучылар составының роле зур.

Бүгенге көндә икътисад фәннәре докторы, РФ һәм ТРның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы Җәүдәт Ибраһим улы Фәйзрахманов гомеренең зур өлешен үткәрә торган «икенче туган йорты» турында сөйли.

– Җәүдәт Ибраһимович, сез инде егерме елдан артык җитәкчелек итә торган вузның тарихы турында сөйләгез әле…

– 1846 елда Казанда биш губерна: Казан, Түбән Новгород, Кострома, Вятка һәм Пермь губерналары өчен агрополигон булырга тиешле уку-укыту фермасы ачыла.

Ә 1922 елның 22 маенда РСФСР Главпрофобр тарафыннан КДУның урман факультетын һәм Политехника институтының авыл хуҗалыгы факультетын мөстәкыйль Казан авыл

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ӨЧЕН КАДРЛАР ӘЗЕРЛӘҮ МӘКТӘБЕ БУЛДЫ

хуҗалыгы һәм урманчылык институтына берләштерү турында карар кабул ителә.

Бүген без Россиядә беренчеләрдән булган аграр укыту-тәҗрибә хуҗалыгына нигез салынуның 160 еллыгын һәм безгә вуз статусы бирелүнең 95 еллыгын билгеләп үтәбез.

– Татарстан авыл хуҗалыгы тармагының дәрәҗәсен, аның потенциалын Сез ничек бәялисез?

– Кризис елларында Татарстан, РФ нең күпчелек башка субъектларыннан аермалы буларак, авыл хуҗалыгы җитештерүен саклап кына калмады, үстерә дә алды. Республика тулай авыл хуҗалыгы продукциясенең кыйммәте буенча Россия төбәкләре арасында – өченче урында һәм Идел буе федераль округында беренче урында тора.

Бу уңышка агросәнәгать комплексын үзгәртеп кору һәм техник яктан коралландыру, заманча технологияләр кертү аша ирешелде. 2011 елда ТР Хөкүмәте карары белән Казан дәүләт аграр университеты Татарстан АСК фәнни-мәгариф кластерының баш вузы итеп тәгаенләнде. Кластер үз эченә 9 урта һәм башлангыч һөнәри белем бирү учреждениесен алды.

– Бүгенге көндә сезнең вуз абитуриент булып килүчеләргә нәрсә тәкъдим итә ала?

– Соңгы биш елда Казан аграр университетында белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләренең саны өч тапкыр артты. Хәзер бездә әзерлек юнәлешләренең 20дән артык программасы тормышка ашырыла: бакалавриат, белгечлек, магистратура һәм аспирантура буенча.

Өстәмә һөнәри белем бирү, шул исәптән Вагенинген университеты (Нидерланд) һәм Европа AGRIMBA Ассоциациясе белән берлектә тормышка ашырыла торган «Агробизнес» MBA халыкара программасы (Россиядә беренче) актив үстерелә.

Казан ДАУ авыл җирлекләреннән максатчан заказ белән студентлар әзерләүне актив алып бара. Уку белән кызыксынуны үстерү өчен 2015 елда безнең башлангыч белән төбәктә АСК өчен кадрларны максатчан әзерләү программасы тормышка ашырыла башлады. Мондый әзерлек ике яклы килешү белән алып барыла: предприятие – студент. Максатчан әзерләүнең мондый схемасы яшь белгечләрне җәлеп итә, һәм шул ук вакытта кабул ителә торган карарлар өчен һәр ике якның да җаваплылыгын арттыра.

– Вузны тәмамлаучыларның күпмесе «кырларга» китә, ә күпмесе фәнни карьераны сайлый?

– Безнең вузны тәмамлаучыларның белгечлекләре буенча эшкә урнашу күрсәткече РФндә иң югарылардан – 70% тәшкил итә. Укып чыгучыларны эшкә урнаштыру үзеге эшли, ул булачак эш бирүчеләр белән күптөрле очрашулар һәм чаралар үткәрә. Башка вузлардан аермалы буларак, бездә әлегә

PRESSA.RU



Рөстәм Миңнеханов,
ТР Президенты,
КАХИның 1978 елгы
чыгарылышы:

«Казан авыл хуҗалыгы институты укытучыларын зур рәхмәт хисләре белән искә алам. Хәзер, инде тормыш тәҗрибәсенә ия булгач, алар безгә үз белемнәрен һәм тәҗрибәләрен генә түгел, үз җаннарының да бер өлешен безгә биргәннәрен аңлыйм. Казан авыл хуҗалыгы институты миңа профессия генә бирмәде. Ул мине иң мөһименә – универсаль фикерләргә һәм үлчәнгән карарлар кабул итәргә өйрәтте.

Мин студентларга гомуми агым иярүне җиңүләрен һәм алга ыргылуларын теләр идем. Бу омтылыш һәркемгә һөнәри яктан да, шәхес буларак та формалашырга булышыр. Шулай ук бу безнең республиканы һәм гомумән илне әйдәп баручылар сафына чыгарыр».

ММЧ мәгълүматлары буенча.

кадәр предприятие гаризалары буенча электән мәгълүм «распределение» дә гамәлдә.

Шул ук вакытта университетта талантлы яшь галимнәргә дә ихтыяҗ зур. Факультетларда 50 гә якын фәнни түгәрәк эшли, аларда студентларның фәнни-тикшеренү эшләре университетның Яшь галимнәр советы белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашырыла.

Хәзерге вакытта 92 аспирантыбыз бар. Вузда 35 яшькә кадәрле яшь галимнәрнең 25%ы фәннәр кандидаты дәрәҗәсенә ия.

– Университетның укытучылар составы турында сөйләсәгез иде.

– Университетта 165 укытучы белем бирә. Бу – уникаль фәнни-техник һәм кадрлар потенциалы.

Уңышлы рәвештә өч диссертация советы эшли, үз фәнни-гамәли журналыбыз бар, ул РФ ВАК тәкъдим иткән басмалар исемлегенә кертелгән.

Университет галимнәренең эшләнмәләре АСК предприятиеләренә киң рәвештә кертелә. Соңгы елларда 100 гә якын патент алынган, 30 дан артык инновацион проект эшләнгән һәм авыл хуҗалыгы машиналары төзү һәм агробиотехнологияләр өлкәсендә 30 дан артык төрле грант отылган.

– Татарстан Республикасының күп җитәкчеләре сезнең уку йортын тәмамлаган. Димәк, алар махсус белемнән тыш, вузда тагын да нәрсәнедер күбрәк алалар?

– Әйе, без үз университетыбызда Татарстанның кадрлар элитасы белем алуы белән горурланабыз. Алар – беренче Президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймиев, Татарстан Республикасының хәзерге Президенты Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов, республика хөкүмәтенең кайбер министрлары, РФ Дәүләт Думасы һәм ТР Дәүләт Советы депутатлары, республика районнары һәм агросәнәгать предприятиеләренең күпчелек җитәкчеләре...

Безнең вузда авыл һәм авыл хуҗалыгы хезмәте – безнең яшәешебезнең төп нигезе, халык зирәклеге һәм мәдәниятенең чыганагы,

“ – Шушы уңайдан Минтимер Шәймиевнең алтын сүзләрен мисалга китерәм: «Һәркем аз булса да «авыл хезмәтчәне» булып караса, шул чакта кешеләр тормышны яхшырак аңлый башлар иде».

туган телне саклау һәм әхлак формалашуның базасы булуы турындагы фикер саклана һәм тәрбияләнә. Ә бит «культура» сүзе дә иң элек турыдан-туры авыл хезмәтенә мөнәсәбәтле булган һәм латинчадан тәрҗемә иткәндә ул «эшкәртү» мәгънәсендә аңлашыла.

Икенче яктан караганда, авыл хуҗалыгы хезмәте табигать күренешләренә һәм тере системаларга бәйле. Бу даими үзгәрүчәнлек һәм көтелмәгән вазгыять дигән сүз, ул шәхестә җайлаша белү, тиз арада карарлар кабул итү, үз өстенә җаваплылык алу сыйфатларын тәрбияли. Башкача әйткәндә, бу – инновацион кеше компетенцияләре. Безнең катлаулы заманда аеруча әнә шундый сыйфатларның таләп ителүе очраклы хәл түгел.

– Сезнең үз вузыгызга, аны тәмамлаучыларга һәм булачак студентларыгызга теләкләрегез?

– Бу юбилей елында мин үз университетыбызның чәчәк атуын һәм яңа һөнәри биеклекләргә ирешүен, ТРның әйдәп баручы аграр вузы дәрәҗәсен саклап калуын телим. Чыгарылыш студентларына һәм абитуриентларына шуны әйтәсем килә: алар дөрес профессия сайлаганнар, ул аларга уңышлы, һәрвакыт ихтыяҗга ия һәм көндәшлеккә сәләтле булырга ярдәм итәр. Һәм тагын. Бервакытта да ирешелгәннәрдә туктап калырга ярамый, алга таба хәрәкәт итәргә һәм үз иңнәребездә туган җиребез өчен зур җаваплылык ятканын истә тотарга кирәк, чөнки ул безне ашата һәм яшәү өчен рухи көч бирә!

Минтимер Шәймиев,
Татарстанның беренче Президенты, ТР Дәүләт Киңәшчесе, РФ Хезмәт Герое, КАХИның 1959 елгы чыгарылышы:

«Соңгы вакытта аграр университет республика президетларын әзерләүдә махсуслаша, дип шаярталар. Бу, мөгаен, игелекле туфракка иядер. Димәк, аграр университет бүгенге дөньяда уңышларга ирешергә мөмкинлек тудырырлык лаеклы белем бирә. Һәм бөтен кешегә дә президент булу мәҗбүри түгел. Бездә әлеге институтны тәмамлаган уңышлы җитәкчеләр күп – министрлар, Хөкүмәт әгъзалары арасында, башка вазыйфаларда, шулай ук фән һәм җитештерү өлкәсендә дә.

Үз институтымның юбилее уңаеннан укытучыларыма тирән ихтирамымны һәм зур рәхмәтемне белдерәм. Алар төрле иде, әмма иң мөһимен эшләделәр – безгә искиткеч белем һәм тәрбия бирделәр. Без алар алдында һәрвакыт бурычлы. Без күп яктан аларның өметләрен акладык һәм аклыйбыз, дип уйлыйм».

ММЧ мәгълүматлары буенча.

PRESSA.RU

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНДА ТӨПЛЕ БЕЛЕМ НИГЕЗЕНӘ ИЯ БУЛУ КИРӘК

«Сколково»га Татарстан делегациясе.

Казан дәүләт аграр университетын тәмамлаган Фәннур Зарипов бүгенге көндә нәсел үгезләре орлыгын җитештерү һәм тарату өлкәсендә эш итүче Россиядәге иң эре баш нәсел предприятиеләренең берсе – «Элита»ны җитәкли.

Фәннур Зарипов, «Элита» Баш нәсел предприятиесе АҖнең генераль директоры

«Тормышыңны авыл хуҗалыгы белән бәйләү, – ди ул, – һәрвакыт бер адымга алдарак баруны таләп итә, чөнки бу өлкәдә бар да бик тиз үзгәреп, яңарып тора. Нәкъ менә аграр секторда төпле белем нигезенә ия булып, даими үсеш кичерү зарур».

– Укыган чакта дәресләрне «тозламагыз», укытучыларның лекцияләрен зур игътибар белән тыңлагыз һәм практик дәресләрне калдырмагыз, – дип киңәш бирә аграр белем алучы студентларга Фәннур Зарипов. – Киләчәктә болардан башка берни эшли алмаячаксыз. Бүгенге көндә авыл хуҗалыгы шулкадәр зур тизлекләр белән үсә ки, белгеч буларак сезгә ихтыяҗ булсын өчен, бар көчегезне эшкә җигү сорала. Авыл хуҗалыгы университетында югары класслы мөгаллимнәр яхшы теоретик нигез – база бирәләр, әмма үзеңне үстерү турында да онытырга ярамый. Диплом алып, баштанаяк авылдагы бизнеска кереп чумгач, кайчандыр алып бетермәгән белемнәреңне кабат үзләштереп утырып булмый инде. Әйтик, синең, җитәкче буларак, бухгалтерия, эш башкару буенча белемең җитеп бетмәве ачыкланырга мөмкин.

Фәннур Зарипов нәсел терлекчелеге өлкәсендәге биотехнологияләрнең яңарышын даими күзәтеп килә, республика һәм дөнья авыл хуҗалыгындагы вакыйгалар турында хәбәрдар булып тора.

– Хәзер авыл хуҗалыгы университетын тәмамлаучылар өчен үз белемнәрен, көчләрен һәм амбицияләрен куллану өчен мөмкинлекләр бик мулдан, – дип дәвам итә Фәннур Зарипов. – Перспективалы һәм яшьләрнең килүе зарур булган юнәлешләр дә шактый күп. Компьютерлаштыру тормышның барлык өлкәләрен колачлап ала, авылга да килеп җитте ул. Грамоталы һәм төгәл исәптән башка бүген чәчү кампаниясен уздырып булмый, сөт фермасын, терлекчелек комплексын торгызып та. Авыл хуҗалыгы тагын да ныграк төгәлләшергә һәм чыгымнарның кимүенә йөз тотарга тиеш.

«Элита» нәсел предприятиесе җитәкчесенең эмбриология белән шөгыльләнә башлау нияте дә бар. Көтүне тиз вакыт аралыгында яхшырту буенча үтә кызыклы тәкъдимнәр һәм технологияләр бар икән. Хәзерге вакытта предприятие өчен үтемле булган вариантны өйрәнү һәм сайлау процессы бара.

– Терлекчелектә ясалма орлыкландыру ысулы күптәннән кулланыла, хәзер инде нанотехнологияләр дә пайда булды, – дип, үсеш перспективалары белән уртаклаша Зарипов. – Бүген бездә баш исәбе – 70, бу республикадагы иң шәп нәсел үгезләре! Безнең бурыч – республикадагы терлекчелек комплексларын югары сыйфатлы орлык белән тәэмин итү. Болар – сөтле, голштин һәм колмогор, итле герефорд, абердин-ангус, обраки, лимузин токымнарына караган нәсел үгезләренең орлыгы.

Узган елның августында Фәннур Зариповка Ирландиягә авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә барырга чакыру килгән. Күргәзмәдә җирле терлекчелек хуҗалыкларында исәп алып бару турында презентация тәкъдир ителгән. Ирландлар, һәр хайванга генетик бәя биреп,шуның буенча аның нәселлелек кыйммәтен ачыкларга ниятлиләр. Бу проект ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм «Сколково» вәкилләре катнашында инде сөйләшенгән.

– Геномлы бәяләүне Татарстанда үзләштерә башларга дигән тәкъдим керде, чөнки без илдәге МЭТ* һәм сөтне тулаем савып алу буенча иң зур микъдарга ия аграр республика, – ди Зарипов. – Минемчә, моның үз мантыйгы бар. Республика хуҗалыкларындагы көтүләрне яхшырту зарур, һәм бу тәҗрибәне башка регионнарга тартырга да кирәк.

«Элита» моннан 40 ел элек оештырыла. Алга таба предприятие үсеп китә һәм заманча җиһазландырыла. Фәннур Зариповның горурланырлыгы да бар:

– Бездә ике лаборатория ачылды: сөтнең селекцион сыйфатын ачыклау өчен һәм иммун-генетик лаборатория. Бу елдан башлап, без сөтнең сыйфатын билгеләү һәм нәсел хуҗалыклары өчен караган хайваннарның нәселен ачыклау буенча хезмәт күрсәтә башладык. Без сыерларның генотиплы һәм фенотиплы күрсәткечләрдән гыйбарәт нәсел җебен төзибез. Мәгълүматларны ТРның бердәм базасына туплыйбыз. Бу Татарстандагы терлекчелектә яңа күренеш,тиздән аның нәтиҗәләре дә күренәчәк. Максатыбыз – республикада лактация арасында савымы 6,5–7 мең кг сөтне тәшкил итә торган югары продуктивлыкка ия көтүләр булдыру. Хәзер без республикадагы барлык терлекчелек хуҗалыклары белән эш итә башладык. Без көтүнең сыйфатын тәэмин итәбез, ә бу – зур җаваплылык!

* Мөгезле эре терлек.

Реклама

УҢЫШЛЫ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК НӘТИҖӘСЕ

Республиканың авыл хуҗалыгы сәнәгате үсешенә бик зур финанс ярдәме күрсәтелеп килү бүген үзенең уңай нәтиҗәләрен бирә. Татарстанның авыл хуҗалыгы – Россиядә иң яхшылар рәтендә.

Гүзәл Рәхмиева,
«ДаМилк» ҖЧҖ
директоры

Эре терлекчелек комплексларыннан кала монда гаилә фермалары, шәхси хуҗалыклар да актив үсеш кичерә. Компаниябез терлекчелек белән шөгыльләнгән авыл кешеләре өчен инде тугыз ел иң төп ярдәмчеләрнең, эшлекле партнёрларның берсе булып тора. Без үзенең 95 еллыгын билгеләп үтә торган Казан дәүләт аграр университеты белән дә тыгыз хезмәттәшлек кылабыз. Республикадагы авыл хезмәтчәннәренең эше уңышлы барсын өчен, йөкне бергәләп тартабыз, дияргә дә мөмкин.

Теория һәм практика – икесе ике нәрсә. Тормышта шулай килеп чыга ки, аграр уку йортлары студентлары авылда кулланылмый торган, инде күптән искергән техниканы өйрәнә. Бәхеткә, республика кырларында һәм фермаларында, югары җитештерүчәнлеккә ия заманча техника инде шактый күп. Бу исә уку-укытуда башкачарак эш йөртүне таләп итә: университет бусагасын атлап чыкканнарны өстәмә укытырга түгел (моңа вакыт та юк), ә уку йортының үзендә үк һөнәри югарылыкка ирешкән белгечләр әзерләргә кирәк.

Шуны да әйтергә телим: бизнес-партнерыбыз булган Казан дәүләт аграр университеты – бик акыллы карар кабул итеп, дөньякүләм сыналган уку-укыту тәҗрибәсе юлын сайлады. Авыл хуҗалыгы предприятиеләре өчен профессиональ инженерлар әзерләү мәсьәләсе монда эре агробизнес – авыл хуҗалыгы техникасы һәм җиһазлары белән тәэмин итә торган компанияләр, бу техниканы җитештерә торган заводлар һәм университет арасындагы хезмәттәшлек ярдәмендә хәл ителә. Бердәм тырышлык нәтиҗәсендә, 2008 елның апреленнән башлап, университетта Механизация һәм техник сервис институтының уку-укыту һәм күргәзмә үзәге эшләп килә. Монда студентлар дөньякүләм танылган җитештерүчеләрнең техникасын өйрәнү генә түгел, сынап та карый ала. Күргәзмәдә «ДаМилк» ҖЧҖнең дә практик мәйданчыгы бар, анда бу көн өчен актуаль барлык җиһазлар да тәкъдим ителә. Әлеге үзәктә тагын бер кирәкле юнәлештә эш алып барыла: авыл хуҗалыгы ширкәтләре белгечләре һәм университет укытучылары фәнни-гамәли тикшеренүләрне бергәләп тормышка ашыра. Уку елы дәвамында студентларның, педагогларның, республикадагы авыл хуҗалыгы предприятиеләре инженерларының белемен күтәрү өчен семинарлар, курслар даими рәвештә уздырылып тора.

Шулай итеп, университетның күргәзмә үзәге асылда уку-укыту процессының, эшмәкәрлек һәм җитештерү эшенең яңа төрдәге үзара бәйләнеш формасы ул. Һәм мондый хезмәттәшлек ике як өчен дә файдалы, чөнки студентлар – киләчәктә безнең потенциаль сатып алучылар һәм кулланучылар. Ә бүген исә алар, үзләренең иртәгә кирәк булачак һөнәри осталыкларын арттырганда, бушлай бирелгән заманча техника һәм җиһазлардан файдалана. Өстәвенә, бу – читләтеп тәкъдим ителгән реклама – технологияләрне базарга кертү ысулы да, авыл хуҗалыгы һөнәрләренә карата кызыксынуны арттыру чарасы да.

Хәзер университетның уку-укыту һәм күргәзмә үзәге үзе бер уку-укыту юнәлеше, авыл хуҗалыгы кластерының үзенчәлекле бер элементы булып үсеп җитте. Белем бирүнең әнә шундый заманча рәвешен гамәлгә кертеп җибәрү югары уку йортының абитуриентлар санын да күбәйтергә мөмкинлек тудырды.

Университетны тәмамлап чыккан яшьләргә яки практика узучы студентларга эш урыннарының бик теләп тәкъдим ителүе дә белгечләр әзерләүнең югары сыйфаты турында сөйли. «ДаМилк» ҖЧҖ, хәер, республиканың авыл хуҗалыгы тармагында эш йөрткән башка ширкәтләр дә, Казан дәүләт аграр университеты егетләрен һәм кызларын практика узарга яки эшкә бик теләп кабул итә.

Казан дәүләт аграр университетына 95 ел тулган бу көннәрдә, безнең белән күп еллар хезмәттәшлек иткән өчен, республикада авыл хуҗалыгы тармагы үсешенә булышлык иткән уртак проектларыбызны уңышлы тормышка ашырган өчен, уку йорты җитәкчелегенә, педагогларга һәм студентларга рәхмәтебезне җиткерәбез. Сезгә һөнәри уңышлар, өметле яңа башлангычлар һәм тотрыклы үсеш телибез.

Реклама

PRESSA.RU

БАРЫ АЛГА ГЫНА!

95 ел – Татарстанның иң өлкән вузларының берсе өчен әллә ни зур гомер түгел, әмма аз дип тә әйтеп булмый. Бигрәк тә, аның кичәгесе һәм бүгенгесе үзенчәлекле вакыйгаларга һәм менә дигән традицияләргә, шәхесләргә бай булуын исәпкә алсак. Казан дәүләт аграр университеты үсеш-үзгәреш этапларында шактый катлаулы юл үтә. Хәзер ул – тотрыклы бүгенгесе булган һәм киләчәккә йөз тоткан уку йортларының берсе.

Александр Фокин, «Агромакс» ФҖП» ҖЧҖ, Казан ДАУның (КАХИ) 1976 елгы чыгарылышы

Минем өчен Казан ДАУ – студент елларының иң матур сәхифәләреннән берсе. Уку да ул, факультетның комсомол оешмасындагы иҗтимагый эшчәнлек тә, студент-механизатор отрядларындагы беренче хезмәт тә. Узган гасырның 80нче елларында КАХИның студент-механизатор отрядлары Россиядә иң шәпләрдән исәпләнә иде. Алар Татарстанда гына эшләп калмыйча, Казахстандагы чирәм җирләрендә дә тир түктеләр. Андагы командирлар – Васил Гарипович Хаҗиев белән Разиф Галиевич Кәримов – бүгенге көндә ТРның Тукай һәм Зәй муниципаль районнарын җитәклиләр. КАХИ үрнәге буенча, Татарстанның күп кенә башка вузлары һәм урта махсус белем бирү йортлары да студент-механизатор отрядлары төзи башладылар. Җиңел булмады, әмма ул чакларның хатирәләре – иң яктылардан. Нәкъ менә шунда без институтта алган белемнәрне гамәлдә сынап карадык. Хәзер университетта студент отрядлары традициясе кабат яңарды. Һәм бу – шәп күренеш!

Институтта укыган вакытта бәйләнгән дуслык җепләре бүгенге көнгә кадәр сузылып килә. Алар инде 40 ел буе сыналган. Группадашлар – Фәнил Фатыйхович Шәйхаттаров, Нияз Зәйнуллович Хисмәтов, Олег Николаевич Спиридонов, Валерий Федорович Бикановлар белән без гаилә дуслары, күп кенә мәсьәләләр буенча даими киңәшләшеп яшибез. Бик күп группадашларым белән бәйләнештә торам. Бигрәк тә – Алмаз Зәкәриевич Кашапов, Хәмзә Харисович Әхмәтсафин, Азат Зәйнәкович Нәҗметдинов, Рамил Мөхтәрович Вәгыйзовлар белән. Дуслык җепләренең күп еллар дәвамында өзелмәвенә һәм ныгуына зур өлеш керткән шәхес – ул 213нче төркемнең, шулай ук терлекчелек фермаларының электрификациясе һәм механизациясе кафедрасы җитәкчесе, профессор Игорь Евгеньевич Волков. Ул – уку йортын тәмамлаучылардан торган фәнни мәктәпкә нигез салган шәхес. Бу мәктәпне бүген КДАУның проректоры, профессор, техник фәннәр докторы Булат Госманович Җиһаншин җитәкли.

Авыл хуҗалыгы предприятиеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү һәрчак мөһим иде. Өстәвенә, бүген шәхси һәм заманча фермер хуҗалыклары төзүгә һәм үстерүгә зур игътибар бирелә. Безнең предприятие сөтчелек терлекчелеген өр-яңадан кору, республикадагы авыл хуҗалыгы тармакларына заманча технологияләр һәм җиһазлар кертү белән шөгыльләнә. Һәм без Казан ДАУ белән күп кенә мәгариф программалары буенча тыгыз хезмәттәшлек итәбез: университет лабораторияләрен заманча җиһазлар белән тәэмин итү дә кирә монда, фәнни эшләр яклангаңда оппонентлык итү дә. Сыерларны машина ярдәмендә саву буенча уздырылган халыкара симпозиумнарда катнашабыз. 25 ел дәвамында ВИЭСХ РАН белән бергә терлекчелекне механикалаштыру һәм автоматлаштыру өлкәсендә эш алып барабыз. Бердәм эшчәнлекнең соңгы нәтиҗәсе – ул РАН әгъза-корреспонденты, техник фәннәр докторы Юрий Алексиевич Цой белән хезмәттәшлек. Сөт бирүче көтү заллары белән программа ярдәмендә идарә итү өчен электрон блоклар булдыруны күздә тота иде ул. Фән белән җитештерү өлкәләренең үзара

Реклама

Үзләрендә эшләнгән саву җайланмалары өчен кирәк-яраклар.

ярашкан килешүе бу. Республика авыл хуҗалыгының алга таба да үсеше өчен нәкъ менә профессионаллар һәм үзебездә уйлап табылган эшкәртмәләр кирәкле.

Хәзерге КДАУ – ирешкән нәтиҗәләрен башкалар белән дә уртаклашырга әзер булган перспективалы, ныклы нигезле, олпат уку йорты. Күпьеллык хезмәтләрен дөньяга күрсәтү белән бергәттән, үсешнең дә алдынгы баскычында ул.

Бу нәтиҗәләр һәм уңышлар артында университетның күпсанлы хезмәткәрләренең, аның җитәкчелегенең, студентларның, аспирантларның һәм инде вузны тәмамлаучыларның да озак елларга сузылган олы эшләре һәм җентекле хезмәте тора, шуны онытмаска кирәк.

Тормыш бер урында таптанып тормый, безгә дә таптанмаска куша. Бер генә мизгелгә тукталып тору да – артка чигенешкә тиң, шуңа да Казан ДАУ һәм мәгариф, һәм фәнни юнәлеш буенча актив эшчәнлеген дәвам итә. Аграр университет бүген өлкәдәге инновацияле эшчәнлек алып баручыларның алдынгы рәтендә исәпләнә. Вуз галимнәренең нигезле фәнни һәм кулланма хезмәтләре ТР фәнен үстерүгә зур өлеш кертә.

КДАУ тәмалаучыларны Татарстанда гына түгел, ә аннан читтә дә колач җәеп каршы алалар. Безнең республикада авыл хуҗалыгы җитештерүе актив үсештә, димәк ки, Татарстанның агросәнәгать комплексында заманча һәм югары квалификацияле кадрларга ихтыяҗ һәрчак булачак. Бу вузның студентлары, аны тәмамлап чыкканнан соң, эшсез калмаячак, дигән сүз. Бу чыннан да шулай. Уку йорты аграр юнәлештә, һәм анда укучылар нигездә авылныкы булуга карамастан, соңгы елларда монда укырга кирәргә шәһәр яшьләре тартыла башлады. Бу тенденция вузның престижы турында сөйләүче фактор түгелмени?

Казан аграр университетының студентларын, аспирантларын, укытучыларын һәм барлык коллективын чын күңелдән 95 еллык юбилейлары белән тәбриклим! Әлеге уку йортында ничә буын акыллы, белемле, кешелекле, уңышка омтылучан яшьләр тәрбияләнде. Алар туган җирләрен ярата һәм үз профессиясенә тугрылык саклый.

Мондый студентларның алга таба да сезгә агылып торуын телим. Сәламәтлек, бәхет, иҗади уңышлар телим. Юлларыгыз гел алга гына илтсен!

Реклама

PRESSA.RU

ИННОВАЦИЯЛӘРГӘ ЙӨЗ ТОТЫП...

Казан дәүләт аграр университеты республиканың авыл хуҗалыгы сәнәгате тармагындагы компанияләр һәм предприятиеләр белән ныклы бәйләнештә тора. Татарстан авыл хуҗалыгындагы барлык мәсьәләләрне әлеге уку йортында әзерләнгән кадрлар кайгырта. Басу-кырлардагы һәм эшкәртү тармагындагы бүгенге уңышлар – бай тарихлы белем йорты укытучыларының да хезмәт нәтиҗәсе ул. Хәзерге заманда авыл хуҗалыгын Казан ДАУ әзерләп чыгара торган югары квалификацияле белгечләрсез күз алдына да китереп булмый. Алардан башка катлаулы технологияләрне үзләштерү дә, инновацияле ысулларны куллану да, авыл хуҗалыгын керемле итү дә, продукцияне сыйфат белән көндәшлек сәләтенә ия булырлык дәрәҗәгә ирештерү дә мөмкин түгел.

Генераль директор Рөстәм Салихҗан улы Кәлимуллин җитәкчелегендәге «Татагрохимсервис» ААҖ коллективы университет укытучыларын юбилей белән котлый, аларга фән-гыйлем мәйданында уңышлар, берсеннән-берсе сәләтле һәм рәхмәтле студентларның күбрәк булуын тели.

«Татагрохимсервис» ААҖ – Россиядә авыл хуҗалыгын химияләштерү мәсьәләләрен комплекслы рәвештә чишүне тәэмин иткән аз санлы ширкәтләрнең берсе. Минераль ашламалар белән сәүдә итә торган әлеге зур компания авыл хуҗалыгы техникасы да, шулай ук үсемлекләрне, кыр культуралары орлыкларын саклау өчен препаратлар да җитештерә.

КЫРГА ЗАМАНЧА ТЕХНИКА ЧЫГА

Компаниянең төп эш тармакларыннан берсе – авыл хуҗалыгы техникасы җитештерү һәм сату. Боларга ОМПШ-2500/3000–18-24м штангалы тагылма сиптергечләр, ПС-20М-4 «МАЭСТРО», ПС-18, ПС-5 үзйөрешле орлык агулагычлар, КСН-3 һәм КСН-4 культиваторлары, БДМ 6х4 дискаторлары керә.

«Татагрохимсервис» ААҖнең «Агрохиммаш» филиалы авыл хуҗалыгы машиналары төзү тармагында инде 30 елдан артык эшли.

Бүген «Агрохиммаш» – үсемлекләрне саклау эше өчен ышанычлы кораллар һәм җиһазлар җитештерелә торган заманча завод. Күпьеллык тәҗрибә бәрабәренә предприятие белгечләре фермерларның бурычларын һәм аларның эшләрендәге төп үзенчәлекләрне, кыенлыкларны яхшы тоемлый. Филиал вакыт сынавын узган ПС-18 «Оптима», ПС-20 «Маэстро» агулагычлары, «Шторм-3000» сиптергечләре һәм шулай ук үзенең яңа коралларын, мәсәлән, болгаткыч-эреткеч җайланма тәкъдим итә.

«Татагрохимсервис» ААҖ техникасы Татарстан басу-кырларында һәм Россиянең башка төбәкләрендә үзен яхшы яктан күрсәтте, хәзер ширкәтнең ил буенча 35 тән артык рәсми дилеры бар.

НИ ЧӘЧСӘҢ, ШУНЫ УРЫРСЫҢ

«Татагрохимсервис» ААҖнә буйсынган «Казан Агрохимсервис» ҖЧҖ – үсемлекләрне саклау чаралары, авыл хуҗалыгы культуралары орлыклары һәм эрүчән микроашламалар белән эш итә торган иң алдынгы, иң эре чит ил һәм Россия компанияләренең дистрибьюторы. Төрле маркетинг чаралары уздыру һәм җитештерүчеләр белән күләмле эш алып бару бәрабәренә предприятие үз партнерларын һәм кулланучыларын продуктларының һәм хезмәтләренең ассортименты һәм техник үзенчәлекләре турында мәгълүмат белән вакытында һәм тулысынча тәэмин итә.

Компаниянең максаты – хуҗалыкларда иртәгәге көн өчен ышаныч булдыру, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә сыйфатлы мул уңыш алуда булышлык күрсәтү. «Казан Агрохимсервис» сыналган алым-ысулларга таяна һәм шул ук вакытта инновацияле технологияләр куллана.

2017 елда «Казан Агрохимсервис» белгечләре, кукуруз, көнбагыш, рапс, соя һәм шикәр чөгендереңнең 150дән артык сортын һәм гибридын төрле туфрак һәм климат шартларында сынау өчен, республикада һәм Россия Федерациясенең күрше төбәкләрендә 20дән артык участок булдырырга ниятли.

Былтыр төрле хуҗалыкларның басу-кырларында 166 гибрид сынау узды. Безнең төбәк өчен иң туры килә торган гибридлар һәм технологияләр тәҗрибә ысулы белән сайлап алынды. Җитештерү компанияләренең иң яхшы белгечләре катнашында семинарлар оештырылды. Төрле участоклардагы уңыш күрсәткечләре бердәм мәгълүмати базага тупланды, хәзер хуҗалыклар аларны сортлар, гибридлар һәм технологияләр сайлаганда файдалана.

Рөстәм Кәлимуллин, «Татагрохимсервис» ААҖнең генераль директоры

«Татагрохимсервис» ААҖ

Үзәк офис
420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Красносельская ур., 51а йорт.

8 (843) 562-22-85 (тел.)
8 (843) 562-22-86 (ф.)
secretar@tatagrohimservis.ru

Фото: tatagrohimservis.ru

Реклама

10 ЕЛЛЫК УҢЫШЛЫ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

Университетның хәзерге җитәкчелеге, республиканың авыл хуҗалыгы көндәшлеккә сәләтле булсын өчен, бик күп хезмәт куя. Бу җайлы, гади эш түгел. Үзенең төп миссиясе – аграр сектор өчен белгечләр әзерләү вазыйфасын университет һәрвакыттагыча бик шәп башкара.

Руслан Рәхмәтуллин,
«ХЛ-Поволжье» ЖЧЖнең генераль директоры

Коллективыбыз Казан дәүләт аграр университеты җитәкчелеген, аның укытучыларын, хезмәткәрләрен һәм студентларын уку йортының 95 еллыгы белән ихлас күңелдән тәбрик итә.

«ХЛ-Поволжье» ЖЧЖ Германиядән HLHamburger Leistungsfutter* компаниясенең Россиядәге вәкиллегенең филиалы булып тора. Татарстан Республикасы, Удмурт Республикасы, Киров өлкәсе, Мари Эл һәм Чуваш Республикасында эш алып барган дәвердә без терлекләр өчен азык матдәләре белән даими тәэмин итә торган һәм бер үк вакытта эре авыл хуҗалыгы холдингларына да, кечкенә фермерлык предприятиеләренә дә консалтинг хезмәтләре күрсәтә торган ширкәт булып танылдык. Безнең продукцияне куллана торган хуҗалыклар уртак хезмәттәшлек чорында әлеге продукциянең – төрле концентратлар, премикслар, престартерлар, минераллар, витамин-минерал өстәмәләр, яшь бозауларны ашату өчен майсызландырылган һәм гади сөт алмашлары, Германиянең бер заводында чыгарыла торган махсус продуктларның югары нәтиҗәлелегенә һәм тотрыклы югары сыйфатлылыгына ышана алды. Тәбәкнең терлекчелек базарында компаниянең тотрыклы урын биләвен исбатлый торган дәлил – клиентларыбызның уңай бәяләмәләре һәм югары дәрәҗәдәге икътисадый уңышлары.

Проектның максат-бурычларын анализлаудан, сыйфатлы продукт тәкъдим итүдән, терлекләрне асрау һәм ашатуга бәйле консалтинг хезмәтләре күрсәтүдән башлап, үзебез эшләп чыгарган системаны күзәтә-көйли баруга кадәр эшләрне колачлаган макчатчан хезмәт компаниябезнең үзенчәлеге булып тора.

«ХЛ-Поволжье» ЖЧЖ оешкан көненнән бирле – инде ун ел – Казан дәүләт аграр университеты белән хезмәттәшлек итә. Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстанның Фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылары кооперативлары ассоциациясе ярдәме белән без терлекчелек тармагының нәтиҗәлелеген күтәрү, ит һәм сөт терлекчелегендә заманча технологияләр кертү һәм үстерү буенча уртак фәнни-гамәли семинарлар уздырабыз. Аларда төрле агрохолдинглардан вәкилләр, товар җитештерүчеләр, фермерлар һәм, әлбәттә инде, студентлар катнаша. Моны республиканың авыл хуҗалыгы тармагын үстерү өчен чыннан да нәтиҗәле хезмәттәшлек дип билгеләргә мөмкин.

Хәзерге тиз үзгәреп-үсеп торган дөньяда икътисадны яңарту, камилләштерү, халкыбызның тормыш дәрәҗәсен күтәрү турында сүз алып барганда, мәгариф тармагының, андагы уку-укыту сыйфатының һәм дәрәҗәсенең, уку йортларында кирәкле яшь белгечләр әзерләп чыгару сәләтенең роле бик зур.

Казан дәүләт аграр университетына шушы юбилей көнендә, иң мөһиме, яхшы традицияләрне саклап калып, заман белән бергә атлавын, ә аның җитәкчелегенә, укытучыларына, хезмәткәрләренә, студентларына һәм аны тәмамлаучыларга яңадан-яңа иҗади уңышлар, ныклы сәламәтлек һәм имин, мул тормыш телибез!

Реклама

* Гамбургның югары продуктивлы терлек азыгы.
** Ибека, Панто.

БЕЛЕМ ҺӘМ МӨМКИНЛЕКЛӘР БЕРГӘЛЕГЕ

Казан ДАУ тырышлыгы белән бүген белем, фән һәм җитештерүнең бергә җигелеп алып барылуы гаять күркәм күренеш. Әлеге ныклы, әһәмиятле бергәлек югары уку йортының визит карточкасына әйләнде, һәм авыл хуҗалыгы бизнесы моның файдасын һәм нәтиҗәлелеген бәяләргә дә өлгерде.

«Инкор» ЖЧҖ Казан ДАУның барлык хезмәткәрләрен, укытучыларын һәм студентларын уку йортының олуг бәйрәме белән котлый. Безнең арадагы ныклы партнерлык мөнәсәбәтләре сакланып калачагына һәм тагын да үсешкә барачагына ышаныч белдерәбез.

«Инкор» ЖЧҖ коллективы

«Инкор» компаниясе – Россия Федерациясенең егерме төбәгендә, шул исәптән Татарстан Республикасында да STIHL* һәм VIKING** техникасының рәсми импортеры.

Җитди җитештерүче продукцияне мөмкин кадәр нәтиҗәле һәм куркынычсыз куллану турында һәрвакыт кайгырта. Тупланган белем һәм тәҗрибәнең бай базасын без бу белем-тәҗрибә файдалы һәм кызыклы булган өлкә – шул профильдәге уку-укыту йортлары белән бүлешергә теләдек. Шуларның берсе – Казан дәүләт аграр университеты.

Татарстандагы авыл хуҗалыгы предприятиеләре инженерларының белемен күтәрү кысаларында, «Инкор» компаниясе STIHL продукциясе буенча өч тапкыр махсус өйрәтү дәресләре уздырды. Барлыгы 120 гә якын кеше белем алды. Без шулай ук күрсәтмә әсбаплар һәм күргәзмә материаллар аудиториясен дә хәзерлибез – компания тәкъдим иткән продуктлар буенча студентларга дәресләр үткәрү өчен агрегатлар, уку-укыту материаллары биреп торабыз, тематик чаралар уздырганда, техниканы эшләтеп тә күрсәтәбез. Бу вакытта төп игътибар куркынычсызлыкны тәэмин итүгә юнәлтелә.

Университет өчен бу – уку-укыту процессының дәрәҗәсен күтәрүдә өстәмә стимул, ә студентларга исә чын профессионаллар куллана торган заманча эш кораллары һәм техника белән якыннан танышу өчен бик шәп мөмкинлек. Чөнки әлеге вузга «Урман эше» һәм «Ландшафт архитектурасы» юнәлешләре буенча укырга керергә теләгән абитуриентлар саны елдан-ел арта бара.

Реклама

* Штиль.
** Викинг.

«АВЫЛНЫ САКЛАУ» ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕНӘ ТАБА

Яшь булса да, авыл хуҗалыгы техникасы базарында үзен шактый ышанычлы тоткан «Восток Капитал» компаниясе директоры Рөстәм Хаҗиәхмәтов «Татарстан» журналына ни өчен кайвакыт үзебездә җитештерелгәннең чит илдән кайтартылганга караганда яхшырак һәм чәчүдә кемнең иң мөһим кеше булуын аңлатты.

Рөстәм Хаҗиәхмәтов, «Восток Капитал» ҖЧҖ генераль директоры

– «Восток Капитал» әле 1,5 ел гына эшли, әмма сез шул вакыт эчендә бөтен Идел буенда – Татарстанда, Оренбург өлкәсендә, Башкортостанда, Самара өлкәсендә – сатып алучыларның шактый киң челтәрен булдырырга өлгергәнсез. Моның сере нидә?

– Бу сер түгел, кагыйдә: без клиент белән аралашканда, ул даими сатып алучыбыз булсын өчен, хәлдән килгәннең барысын да эшлибез. Үзара хезмәттәшлегебез техника сату белән генә чикләнми. Без аңа сервис хезмәте күрсәтәбез, запчастьләр һәм кирәк булганда өстәмә җиһазлар да табып бирәбез.

– Әмма сезнең көндәшләрегез дә шундый ук шартлар тәкъдим итәдер бит?

– Көндәшлек – ул гомумән яхшы нәрсә. Ул сине яхшырак эшләргә мәҗбүр итә. Һәм моннан бөтен кеше – без дә, клиентлар да ота. Мәсәлән, без аларга лизинг белән булышабыз. Кешенең машина алырга килү мөмкинлеге юк икән, илтеп бирәбез. Һәм без үзебез белән эшләүчеләргә тулысынча ышанабыз. Шундый очраклар да була – без мондый сатып алучыларга машинаны акчасын соңыннан аз-азлап түләү шарты белән дә биреп җибәрәбез.

– Ихтыяҗга нинди факторлар йогынты ясый?

– Безнең туфрак эшкәртү өчен асылмалы прицеп техникасы сегментында сезонлылык зур роль уйный. Хәзер менә ихтыяҗ зур – менә-менә чәчү башланырга тора, бу вакытның бер көне ел туйдыра. Тәҗрибәле фермерлар аңа алдан ук әзерләнә, әмма кайбер нәрсәләрне, мәсәлән, агрегатның тулысынча сафтан чыгуын, һәрвакытта да алдан күреп булмый. Мондый очракларда без кыска вакыт эчендә яңа машина китереп бирергә әзер.

– Сез үзебездә һәм чит илдә җитештерелгән техника тәкъдим итәсез. Кайсын күбрәк сайлыйлар?

– Төрле категорияле хуҗалыкларның стратегиясе дә төрле. Күп хуҗалыкларда зур тизлекле, күп энергия куллана торган зур тракторлар эшли. Үзебездә җитештерелгән кайбер сабан һәм культиваторлар аларга туры килми, ә менә чит илдә җитештерелгән агрегатлар бик шәп эшләячәк. Кайбер хуҗалыклар исә бары тик үзебездә җитештерелгән техника белән генә эшли. Аларның механизаторлары бу техниканы яхшы белә һәм сезонга сыйфатлы итеп әзерләп куя. Өченче төрләләр дә бар – аларның чит ил техникасын сатып алырлыклары булса да, тулысынча механикалаштырудан качу һәм эш урыннарын саклап калу өчен, аны сатып алмыйлар. Кагыйдә буларак, бу – республиканың ерак районнарындагы авылның терәге булган хуҗалыклар. Аларның җитәкчеләре яхшы аңлый: кешене машина белән алыштырсаң, аның бүтән барыр җире юк. Авылны исә эш булганда гына саклап калып була.

– Хуҗалыкта механизаторга күп нәрсә бәйлеме?

– Сезон вакытында да, аңа әзерлек чорында да ул – төп белгеч. Без хуҗалыкка «алтын» сабан сата алабыз, әмма анда аны дөрес файдалана белүче кеше юк икән, акча җилгә очкан, диген сүз.

– Сез бездә җитештерелгән техника чит илнекеннән бераз калыша, дидегез. Сез сатып алучыларыгызга бу турыда әйтәсезме?

– Әлбәттә. Без сата торган агрегатларның бәясе 500 мең сумнан алып 3–5 миллион сумга җитә. Күп хуҗалыклар өчен бу – бер еллык керем. Һәм фермер шулкадәр акча сарыф итә икән, без аңа барысын да аңлатырга, дөрес сайларга булышырга тиеш.

– Сез «Профессиональ белем (Агроинженерия)» белгечлеге буенча Казан дәүләт аграр университетын тәмамлагансыз. Әмма хуҗалыкта эшләүгә караганда үз эшегезне ачуны мәгъкульрәк күргәнсез.

– Мин үзебезнең тармакка булышу мөмкинлегем барлыгын күрәм. Без авыл хуҗалыгы техникасы сату белән генә чикләнмибез, без Татарстан фермерларын яңа нәтиҗәле технологияләр белән таныштырабыз, күргәзмәләр, семинарлар, укыту программалары оештырабыз. Безнең миссия шундый.

Казан аграр университеты һәрвакыт кадрлар әзерләүче булды. Ул безнең республикабыз өчен төп тармак саналган аграр сферада республиканың күп кенә җитәкчеләренә һәм талантлы белгечләренә юл башы булып тора. Яңашәбездә нинди генә фәнни-техник прогресс күзәтелмәсен, без һәр көн табыннарыбызда яңа пешкән ипи һәм сыйфатлы май булуын телибез. Ә боларның барысы да иртәдән кичкә кадәр, кояшта да, яңгырда да Татарстанның төрле почмакларында хезмәт куйган авыл хезмәтчәннәре тырышлыгы белән булдырыла. Үземнең югары уку йортына озын гомер һәм республикабызны данлаячак югары дәрәҗәле белгечләр әзерләвен телим!

Рөстәм Хаҗиәхмәтов,
«Восток Капитал» ҖЧҖ генераль директоры

Реклама

PRESSA.RU

БИРЕДӘ РЕСПУБЛИКА ГОРУРЛАНА ТОРГАН ПРОФЕССИОНАЛЛАР ӘЗЕРЛӘНӘ

95 ел – мәгариф учреждениесе өчен мөһим дата. Мин бу юбилей белән үзем укыган аграр университетны тәбрик итәм. Әлеге вакыт эчендә югары уку йорты зур укыту-фән үзәгенә әйләнде, һәм бүген бу – югары һөнәри белемле меңнәрчә белгеч әзерләп чыгарган заманча уку йорты.

Казан ДАУ – авыл хуҗалыгы өчен кадрлар әзерләүче уку йорты, ул республика агросәнәгать комплексы тармагындагы фән-мәгариф кластерын җитәкли. ВУЗ галимнәренең эшкәртмәләре җитештерүдә һәм уку процессында киң кулланыла, отылган фәнни грантларның күләме исә елдан-ел арта бара. Аграр сегментта кадрлар проблемасы һәрвакыт актуаль иде, бүген исә бигрәк тә кискен тора. Күп хуҗалыклар – югары технологияле, механикалаштырылган җитештерүләр, аларга чын профессионаллар, шул исәптән югары белемле белгечләр таләп ителә. Һәм аларның һәркайсының куәте нәкъ биредә укытыла торган грамоталы хезмәткәрләргә бәйле. Бүген Казан ДАУ, педагогик составының менә дигән эшләве һәм вуз җитәкчелегенең дөрес курс сайлап алуы нәтиҗәсендә, югары дәрәҗәдәге белем бирә. Мин дә, безнең «Восток» ҖЧҖ нең баш агрономы Илфат Мөхәрләмов та биредә укыган елларны искиткеч җылылык белән искә алабыз һәм югары белемне нәкъ менә Казан дәүләт аграр университетында алганга язмышыбызга рәхмәтлебез.

Бүген «Восток» ҖЧҖ республиканың әйдәп баручы аграр предприятиеләре белән бер сафта тора. Аның үсешендә һәм алга барышында яшь һәм квалификацияле белгечләр командасының, шул исәптән Казан дәүләт аграр университетын тәмамлаучыларның да өлеше зур. Моннан ун ел элек банкротлык хәлендәге артель базасында оештырылган «Восток» ҖЧҖ бүген югары күрсәткечләре тотрыклы булган заманча хуҗалыкка әверелде. Без җитештерү процессын тулысынча яңарттык. Эшчәнлекнең төп юнәлешләре арасында – нәселле терлек үрчетү, ит һәм сөт продукциясен сату, үсемлекчелек, бәрәңге үстерү. Бер генә эштә дә хәрәкәтсез торырга ярамый, даими үсәргә, киңәергә, яңа идея һәм проектларны тормышка ашырырга кирәк. Бүгенге заман яңа бурычлар куя, дөньядагы азык-төлек куркынычсызлыгы мәсьәләләре исә һаман саен актуальләшә бара. Шунлыктан Казан ДАУ һәм республика авыл хуҗалыгы предприятиеләренең традицион дуслыгы һәм нәтиҗәле үзара хезмәттәшлеге соңгы елларда яңа эчтәлеккә баеды. ВУЗ, студентларны, тыңлаучыларны һәм партнерларын – авыл хуҗалыгы предприятиеләрен, җирдә эшләүчеләрне җәлеп итеп, үзенең эшчәнлеген һәм оештыру структурасын даими камилләштерә. Һәм бу ике як өчен дә файдалы хезмәттәшлек, чөнки безнең Казан ДАУ белән бурычыбыз бер – республика халкын сыйфатлы һәм табигый продуктлар белән тәэмин итү.

Алексей Леонтьев, «Восток» ҖЧҖ директоры, Казан ДАУның (КДАХА) 2004 елгы чыгарылышы

Җитәкчелекне, профессорлар һәм мөгаллимнәрне, студентларны һәм әлеге югары уку йортын тәмамлаучыларның барысын да Казан дәүләт аграр университетының 95 еллыгы белән ихластан тәбриклисем килә! Татарстанның төрле районнарыннан һәм Россиянең башка төбәкләреннән килгән яшь егет-кызлардан биредә ил һәм республика горурлана торган искиткеч профессионаллар тәрбияләнә.

Югары уку йорты коллективына яңа иҗади уңышлар, югары үрләр, хезмәт сөючән студентларның күбрәк булуын телим. Иң мөһиме, уңыш Казан дәүләт аграр университетын беркайчан да ташламасын, бигрәк тә яңа проектларны гамәлгә керткәндә!

Реклама

«ЭЛИТА» – ҺӘР НӘРСӘНЕҢ НИГЕЗЕНДӘ

«Хәерби» хуҗалыгына барганда Лаеш районының Хәерби авылы аша узабыз. Әле яңарак кына салынган пөхтә кирпеч йортлар арасыннан яңа балалар мәйданчыгы, түрбакчасы балкып торган мәктәп бинасы, яңа модульле ветеринария пункты күренеп ала...

Радик Вафин,
«Хәерби» ҖЧҖ
генераль директоры

Реклама

Хуҗалык ишегалдында механизаторлар техникага ревизия ясый. Генераль директор Радик Вафин минем өчен чак берничә минутын сарыф итәргә мөмкинлек таба. Аңа бертуктаусыз тәэмин итүчеләр белән сатып алучылар шалтырата, йомыш белән килүчеләр игътибарын таләп итә. Радик Кадыйрович алар белән агымдагы мәсьәләләрне хәл иткән арада мин машина-трактор паркын карап чыгарга өлгерәм. «Хәерби»нең паркы – искиткеч шәп. Бер почмакта «Киров заводы»ның өр-яңа тракторы тора, янәшәсендә – «ХаРаШа» Лаеш чәчкече. Ә иң үзәктә Deutz-Fahr (Дойц-Фар) немец җитештерүчесенең тракторы эшкә әзер тора. Болар – парктагы техник җайланмаларның кайберләре генә.

– Мондый ресурсларыгыз булуы белән горурланасыздыр, мөгаен?

Радик Кадыйрович елмая:

– Мин күбрәк кадрларым белән горурланам. Әйтик, механизаторыбыз Суфьян Ибәтуллин, ветеран дисәк тә була үзен. Немец машинасын бары тик аңа гына ышанып тапшырам. Аның эш кенәгәсендә бары бер генә эш урыны теркәлгән – безнеке, – дип сөйли Радик Кадыйрович. – Икенче белгечебез – Илсур Галиев – икенче буын механизатор. Мондый кешеләрдән башка эшне алып барып булмый.

«Хәерби» хуҗалыгы башлыгы үзе бу хуҗалыкта 22 ел эшли икән инде.

– Машина йөртүче буларак башлаган идем, ул чакта хуҗалык әле «Татплодоовощпром» составына керә иде. Эшли башлагач, югары белем алырга кирәк икәнлегенә төшендем. Армиядән соң, олы абыем әзләреннән китеп, Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга кердем. Анда алган белем миңа бик нык ярдәм итте. Хәзерге Казан ДАУ ректоры – Җәүдәт Ибраһимович Фәйзрахманов һәм диплом эшемнең җитәкчесе Фаик Нәбиевич Сафиуллин белән хәзер дә аралашам. Алар миңа һәрчак ярдәм итәргә, кирәк чакта консультация бирергә әзерләр. Безнең казанышларыбызда өлешләре бик зур, – ди Радик Вафин.

Ишегалдына чираттагы машина килеп керә – «Элитные семена Татарстана» ассоциациясе җитәкчесе Юрий Еров икән. Радик Кадыйрович белән сөйләшәләр. Аннан Юрий Васильевич «Хәерби» башлыгының кулын кыса да китеп бара.

– Чәчү эшендә булышабыз. Безгә өметләре зурдан, – дип аңлата Радик Кадыйрович.

Сүз уңаеннан, «Хәерби»дә орлыкчылык – төп юнәлешләрнең берсе. Инде берничә ел хуҗалык ассоциация составына керә.

– Суперэлита чәчәбез, элита җыеп алабыз, беренче һәм икенче буынында. Бу орлыкларга ихтыяҗ бик зур, Чувашия, Башкортостаннан ук киләләр. Берничә ел элек уңыш күләме гектарыннан 15–17 центнерны тәшкил итсә, хәзер югары продуктивлыкка ия орлыклардан торган чәчүлекләр гектарыннан 30 центнердан да кимрәк булмый. «Элита»дан да түбәнрәкне чәчмибез, – дип ачыклык кертә «Хәерби» башлыгы. – Монда да күп нәрсә кадрлардан тора. Әгәр бездә инде 45 ел дәвамында эшләүче баш агроном Шамил Әхмәтҗанович Кушмин булмаса, мондый уңышларга ирешү мөмкин булмас иде.

Чәчүлек мәйданының колачы киң – 4200 гектарны тәшкил итә. Орлыкчылыктан кала, хуҗалык яшелчә үстерү һәм терлек үрчетү белән дә шөгыльләнә. 1380 баш терлекнең өчтән артыгын савым көтүе тәшкил итә. Биш ел дәвамында «Хәерби»нең күрсәткечләре барлык юнәлешләрдә дә үсеш кичерә.

Радик Кадыйровичтан моңа ничек ирешүләре хакында сорыйм. Югыйсә, техника көннән-көн кыйммәтләнә, сөткә бәяләр төшә, ә орлык бәясе исә менә берничә ел инде һаман да шул бер дәрәҗәдә тора.

– Әйе, проблемалар җитәрлек. Кайсыларын дәүләт программаларына, Авыл хуҗалыгы министрлыгына таянып ерып чыгабыз. Лаеш районы башлыгы Михаил Павлович Афанасьев бик нык булыша. Без аңарга ярдәме өчен бик рәхмәтлебез, – ди «Хәерби» җитәкчесе.

Төп проблемаларыннан берсе – кадрларда шәһәр белән көндәшлек.

– Без, ни генә дисәң дә, шәһәр читендә урнашканбыз, эшкә урнашу буенча кешеләрнең сайлау мөмкинлеге бар. Эш хакы мәсьәләсенә килгәндә, шәһәрдән калышмаска тырышабыз. Әмма эш хакы белән генә җәлеп итеп булмый халыкны. Эш шартлары кырыс, яллар юк диярлек, – дип сөйли безгә Радик Кадыйрович.

Һәм аңлашыла: аның эше асылда үз абруена һәм кешеләргә булган мөнәсәбәтенә бәйле рәвештә җайга салынган. Әмма бу югары материяләр турында сөйләшеп тормыйбыз. Радик Кадыйровичның моңа вакыты да юк, чәчүгә керешергә вакыт. Кешеләр өйләренә эш хакы алып кайтсын, шәһәрләрдә түгел, ә нәкъ менә биредә эшләргә теләсеннәр өчен.

Хөрмәтле Җәүдәт Ибраһимович! Сезне һәм Казан ДАУ коллективын 95 еллык юбилее белән тәбриклим! Үз тарихында вуз Татарстан үсешенә хәлиткеч өлешен керткән шәхесләрне аз тәрбияләмәде. Бу уку йортын тәмамлап чыгучылар арасында аграрийлар гына түгел, ә хуҗалык һәм предприятиеләрнең булачак җитәкчеләре дә, безнең авыл хуҗалыгы тармагы һәм гомумән республиканың азык-төлек белән тәэмин ителеше язмышын хәл итәрдәй шәхесләр дә бар. Абитуриентларыгыз арасында сәләтле, инициативалы, кызыксынучаннары елдан-ел арта барсын! Газиз уку йортыма чын күңелдән озын гомер телим, ә аның коллективына – сәламәтлек һәм иминлек!

PRESSA.RU

Вәгыйз Минһаҗев,
«Россия авыл хуҗалыгы үзәге» ФДБУнең ТР буенча филиалы җитәкчесе

Монда фикерләргә өйрәтәләр

Казан дәүләт аграр университеты быел 95 еллыгын билгеләп үтә. Бер уйласаң, вуз өчен бу әллә ни зур вакыт та түгел, әмма бу еллар эчендә Казан ДАУ республикабызның әйдәп баручы уку йортларының берсенә әверелде. Аның укытучылары тарафыннан авыл хуҗалыгы сәнәгате өчен яхшы кадрлар әзерләнде. Алай гына да түгел, алар югары әзерлекле икътисадчылар, менеджерлар, инженерлар... Республикада хәтта аграр университет республика президентларын әзерләүдә махсуслаша, дип тә шаярталар. Ике президент та: беренчесе – Минтимер Шәймиев тә, хәзергесе – Рөстәм Миңнеханов та – Казан ДАУ тәмамлаган. Нәтиҗәдә университет яхшы белемнәр бирә, һәм алар бүгенге дөньяда зур уңышларга ирешергә ярдәм итә. Монда универсаль фикерләргә һәм дөрес карарлар кабул итәргә өйрәтәләр. Казан ДАУ – үз традицияләре булган, бүгенге заман белем бирү таләпләреннән калышмаучы алдынгы вуз. Моның өчен университетта фән-техниканың агросәнәгать комплексларындагы сәнәгать һәм бизнес-структуралары белән хезмәттәшлегенең яңа формалары уңышлы үстерелә – бу уртак лабораторияләр, бизнес-структуралар, тәҗрибә-җитештерү хуҗалыклары, уртак кафедралар булдыру юлы белән эшләнә. Аграр университет партнёрлары арасында – республиканың иң эре авыл хуҗалыгы берләшмәләре, комбинатлары һәм комплекслары.

Юбилей көннәрендә вузга яңа зур уңышлар телим һәм биредә заман куйган теләсә нинди, иң катлаулы бурычларны да үти алырлар, дип ышанам!

Реклама

Генадий Миңнуллин,
Крестьян-фермер хуҗалыгы башлыгы

Авыл өчен кадрлар әзерләүдә әйдәп баручы

Казан дәүләт аграр университетын бик рәхәтләнеп юбилее белән котлыйм! 95 ел дәвамында вуз республика авыл хуҗалыгы өчен кадрлар әзерләүдә әйдәп баручы булып тора. Институтның фәнни потенциалы, аның заманча җитештерү базасы һәм, иң мөһиме, көчле укытучылар корпусы Казан ДАУна бүгенге көндә аграр сектор үсешенә, аның чәчәк атуына һәм уңышына юнәлтелгән катлаулы бурычларны хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Һәр вузның төп казанышы – аны тәмамлап чыгучылар һәм аларга ихтыяҗ булу. ТРның беренче Президенты Минтимер Шәймиев тә, хәзергесе – Рөстәм Миңнеханов та аны тәмамлаганнар һәм аграр университетның горурлыгы булып торалар. Бу исемлекне озак дәвам итәргә була – вузның горурланырлыгы бар, ул чын кадрлар мәктәбе.

Казан ДАУ – республикабызның авыл хуҗалыгы фәне үзәге дә. Бүген университет белем бирүнең яңа, тагын да биегрәк үренә күтәрелде, бу турыда аның фәнни-гамәли эшчәнлеге, инновацияле фәнни-тикшеренү өлкәләрендә уңышлы эшләве дә сөйләп тора.

Юбилей көнендә мин университетка киләчәктә дә республикабыз һәм Россиянең уңышлары хакына яңа казанышларга ирешүен телим. Һәр хезмәткәренә, педагогына, шулай ук вуз студентларына һәм аны тәмамлаучыларга ныклы сәламәтлек, һөнәри үсеш һәм күтәренке кәеф юлдаш булсын!

95 яшьлек еллык датасы университетка яңа биекләр яулау өчен стимул өстәсен!

Азат Айзатуллов,
ТР Буа муниципаль районы башлыгы

Сәлим Даутов,
ТР Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе

Фән – авыл хуҗалыгына

Буа муниципаль районы кешеләре һәм шәхсән үз исемебездән Казан дәүләт аграр университеты укытучыларын, аспирантларын, студентларын, ветераннарын, барлык хезмәткәрләрен – вузга нигез салынуга 95 ел тулу уңаеннан котлыйбыз!

Бу еллар эчендә университет Татарстанда гына түгел, төбәктә дә – аның социаль-икътисадый үсешенә, авыл хуҗалыгына органик рәвештә кушылганга күрә, әйдәп баручы фәнни-белем бирү һәм методика үзәгенә әверелде. Яңа фәнни мәктәпләр булдыру, алдынгы технологияләр эшләү һәм аларны тормышка ашыру буенча байтак эшләр башкарылган. Вузның турыдан-туры ярдәме белән Татарстанның күп районнарындагы агросәнәгать комплексларына яңа юнәлешләр һәм технологияләр кертелә һәм, алар авыл кешеләренең авыр хезмәтен җиңеләйтергә ярдәм итә.

Үз эшчәнлеге елларында университет авыл хуҗалыгы өчен югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә ныклы нигез салды, шул рәвешчә төбәк икътисадын киң спектрдагы авыл хуҗалыгы, икътисад, табигый-фәнни һәм инженерлык юнәлешләре буенча белгечләр белән тәэмин итә башлады.

Һәр университет – бу беренче чиратта кешеләр, һәм шуны билгеләп үтү мөһим: профессор-укытучылары составының профессиональлеге ярдәмендә университет авыл хуҗалыгы тармагы өчен яхшы белгечләр әзерли алды, АСКлар өлкәсендә Татарстан Республикасының өстенлекле үсеш юнәлешләре буенча ышанычлы фәнни-техник нигез булдырды. Ә икътисадның чәчәк атуына авыл хуҗалыгы үсешеннән башка ирешү мөмкин түгел.

Казан ДАУна чын күңелебездән тотрыклы фәнни һәм иҗади куәт, якты идеяләр һәм яңа проектлар, һөнәри ачышлар, һәм шулай ук киләчәк планнарының уңышлы тормышка ашуын телибез!



Минталип Миңнеханов,
ТРның Тукай районы фермерлары идарәсе рәисе,
ТРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре,
Россиянең атказанган фермеры, КФХ башлыгы

Бер тарыдан ботка булмас

Татарстанның иң өлкән вузларыннан берсе булган Казан ДАУ котлаганда, шуны әйтәсем килә: без сезнең белән коллегалар диярлек. Соңгы еллар күрсәткәнчә, фермерлар республиканы азык-төлек белән тәэмин итүгә саллы өлеш кертә ала. Университет кебек үк. Татарстанның авыл хуҗалыгына аның никадәр файда китерүен, никадәр яхшы белгечләр әзерләвен, лаеклы кешеләр тәрбияләвен күз алдына китерү дә авыр.

Сез – авыл хезмәтен, ә без аның бер тармагын – фермерлыкны пропагандалыйбыз. Вуз өчен укытучылар, студентлар, аспирантлар һәм чыгарылышлары зур гаиләгә әверелгән кебек, фермерларга да төп ярдәм нәкъ менә гаиләдән – ир белән хатыннан, аларның балаларыннан, оныкларыннан килә. Бер тарыдан ботка булмый, гаилә ярдәменнән башка хуҗалыкны күтәрү мөмкин түгел. Безнең фермерлык предприятиесе Тукай районында 2000 елда оешты. Шушы еллар эчендә җиргә мәхәббәт, көндәлек тырыш хезмәт аны ныклы гаилә – авыл хуҗалыгы предприятиесенә әверелдерде. Бүген без Яр Чаллының барлык социаль учреждениеләрен бәрәңге белән тәэмин итәбез, аны балалар бакчаларына, мәктәпләргә, сәламәтлек саклау оешмаларына ташламалы бәяләрдән озатабыз.

Республикада авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнергә тәвәккәлләүчеләр елдан-ел арта. Бу сөендерә. Димәк, җир эшкәртүченең, игенченең, халыкны туендыручының игелекле хезмәте дәвам итә. Авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнергә мәҗбүр итеп булмый. Мондый теләк кешенең канында була, генетика дәрәҗәсендә тапшырыла. Һәм продукциянең кешегә ошавын, аны сатып алуларын һәм көтеп торганнарын күргәч, җирдә эшләвеңнән канәгатьлек аласың.

Мин безнең бөтен тату гаиләбез исеменнән Казан ДАУ 95 еллыгы белән ихлас котлыйм. Сезнең тагын күп юбилейларыгызны каршылавыгызны телибез. Сәламәт һәм бәхетле булыгыз. Казан ДАУ чыгарылышларының барысының да, укуларын тәмамлагач, тәвәккәлләп авылларга кайтуларына өметләнәбез.

PRESSA.RU

Илһам Вәлиев,
Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы, Казан ДАУның (КАХИ) 1983 елгы чыгарылышы

Һәрвакыт бер адымга алда

Казан дәүләт аграр университеты үзенең 95 еллыгын билгеләп үтә. Традицион рәвештә республикабызның авыл хуҗалыгы казанышларына күп очракта әлеге вузны тәмамлаган буыннарның хезмәте нәтиҗәсендә ирешелә. Вуз югары квалификацияле бихисап белгечләр үстереп чыгарды, бүген алар хакимиятнең федераль һәм республика органнарында эшлиләр, төрле югары вазыйфалар билиләр, бизнеста зур уңышларга ирешәләр. Казан ДАУның дипломы – югары сыйфатлы белем турындагы таныклык ул, һәм хезмәт базарында ихтыяҗ булуга гарантия дә.

Мин, әлеге вузны тәмамлаган биология фәннәре кандидаты буларак, безнең университетның киләчәктә дә югары аграр профессиональ белем бирүнең игелекле традицияләрен дәвам итәчәгенә өметләнәм. Бу катлаулы, әмма бик тә актуаль мәсьәлә, чөнки аграр университетлар авыл хуҗалыгыннан бер адымга алда булырга тиеш. Шулчакта гына киләчәктә үзеңне ышанычлы тою мөмкинлеге була, һәм абитуриентлар Казан ДАУна укырга кереп, киләчәктә үз язмышларын аграр өлкә белән бәйләячәк.

Юбилей елында әлеге уку йортына Балык Бистәсе районының барлык халкы исеменнән үсеш юлында яңа уңышларга ирешүен, кызыклы фәнни ачышлар ясавын һәм бик яхшы студентлар тәрбияләвен телим. Иминлек, күтәренке кәеф, уңышлар, киләчәк үсешегездә чәчәк ату насыйп булсын!

Марат Хәсәнов,
«Свияга» авыл хуҗалыгы предприятиесе» ҖЧҖ директоры

Озын юл узган вуз

Һич арттырусыз шуны әйтергә була: аграр өлкә бөтен Татарстан өчен өстенлекле урын алып тора, һәм авыл хуҗалыгы өчен квалификацияле кадрлар алтын бәясендә. Без моны бик яхшы беләбез, чөнки үзебез җирдә эшлибез. Безнең хуҗалык белгечләр белән тулысынча тәэмин ителгән, һәм аларның күбесе – Казан ДАУ ын тәмамлаган. Аграр университет инде күп дистә еллар Татарстан, бөтен Урта Идел, Россия Федерациясенең башка төбәкләрендәге күп кенә авыллар өчен кадрлар әзерләү мәктәбе булып тора.

Бүген республиканың озын үсеш юлы узган иң өлкән вузы – вакыт белән сыналган, Россиядә аграр белем бирү системасында лаеклы урын тоткан популяр уку йорты. Аның җитди кадрлар һәм фәнни потенциалы бар, ул тиешле матди-техник базага, югары квалификацияле белгечләр әзерләүдә бай тәҗрибәгә ия.

Чын күңелемнән безнең хуҗалыкның бөтен коллективы исеменнән Казан ДАУның җитәкчелеген, укытучыларын, студентларын һәм чыгарылышларын 95 еллыклары белән котлыйм! Юбилей көннәрегездә без сезгә чын йөрәктән бетмәс-төкәнмәс илһам, ныклы сәламәтлек, бәхет, имин тормыш, яңа хезмәт батырлыклары һәм фәнни казанышлар телибез!

МАХСУС ПРОЕКТ

— 21нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

PRESSA.RU

РЕКТОРЛЫК: СӘЛӘТ ҺӘМ ВАЗЫЙФА

Рәшит Низамов, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты ректоры, техник фәннәр докторы, профессор, май аенда үзенең 60 яшен билгеләп үтә.

«Әгәр 80 нче елларда кем дә булса минем, бернинди яклаучысыз, гап-гади район егетенең, шушындый көчле, кызыклы, дәрәҗәле университетның ректоры булачагым турында әйтсә, көлгән генә булыр идем», – бу сүзләрне бәйсез кандидат Рәшит Корбангалиевич 2008 елның көзендә Россиянең әйдәп баручы төзелеш вузларының берсенә альтернатив нигездә ректор итеп сайлап куелганнан соң әйтә.

Ул мәктәп укытучылары гаиләсендә туа, КИТИның төзелеш-технология факультетын, аннары аспирантураны тәмамлый. Фәнни эшчәнлеген кафедра ассистенты буларак башлап җибәрә... Бүгенге көндә Рәшит Низамов җитәкчелек иткән вуз иң дәрәҗәле, перспективалы һәм көндәшлеккә сәләтлеләрдән санала. Казан архитектура мәктәбе үзенең комплекслы объектлар турындагы белемнәрен уңышлы тормышка ашыра һәм республиканың аеруча мөһим объектларын үстерү программаларын тәкъдим итә.

Рәшит Корбангалиевичның казанышлары «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем белән бәяләнгән.

Ректор-новатор

Ирек Закиров,
«Татагропромстрой» ААҖнең генераль директоры

Хөрмәтле Рәшит Корбангалиевич!

Барлык авыл төзүчеләре – Сезнең университетны тәмамлаучылар исеменнән 60 яшьлек юбилеегыз белән котларга ихлас шатмын!

23 ел инде Сезнең исемегез Россиянең иң яхшы архитектура-төзелеш вузларының берсе – КДАТУ белән бәйле, шуларның тугыз елы дәвамында Сез аңа җитәкчелек итәсез. Университеттагы белем бирү эшчәнлегенең югары дәрәҗәсе турында аның Россиядәге 503 дәүләт вузы арасында икенче урында торуы гына түгел, бәлки әлеге уку йортын тәмамлаучыларга даими ихтыяҗ булуы да сөйләп тора.

Архитектура һәм төзелеш – профессиональ булмауны һәм заман дәрәҗәсенә туры килмәүне кабул итми торган тармакларның берсе. КДАТУ соңгы елларда гына да күпсанлы зур күләмле һәм амбициоз объектларны проектлауда катнашты. Болар: «Баскет-холл», «Корстон», «Кол Шәриф» мәчете, 37 катлы «Лазурные небеса» торак комплексы, «Казан-Арена» стадионы...

Хөрмәтле Рәшит Корбангалиевич! Сезгә үзенчәлекле, новаторларча карарлар кабул итү һәм иң кыю идеяләрне тормышка ашыру сыйфатлары хас. Күтәренке кәефегез һәм эшкә дәртегез киләчәктә дә катлаулы һәм зур бурычларны уңышлы хәл итәргә ярдәм итсен. Сезгә, якыннарыгызга һәм фикердәшләрегезгә ихлас теләкләребезне җиткерәбез. Сезнең барысын да булдырачагыгызга ышанам! Сез барысын да булдыра ала торган шәхес, без моңа ышанабыз!

Күбрәк идеяләр, планнар, проектлар!

Марат Нуриев,
«Уютный дом» ИК»
ЖЧЖ генераль
директоры

Хөрмәтле Рәшит Корбангалиевич, Сезне әлеге түгәрәк дата – 60 яшегез белән котларга рөхсәт итегез!

КДАТУны тәмамлаучы буларак, Сезнең нәкъ менә үз урыныңдагы кеше булуыгызны яхшы беләм. Сездә инженерларча фикер йөртү, җитәкчелек итә белү, зыялылык, ораторлык сәләте, укытучылар һәм студентлар коллективын үз идеяләрегез белән кызыксындырып җибәрү осталыгы кебек сыйфатлар гаҗәеп рәвештә берләшкән. Стереотиплар – бу Сезнең хакта түгел.

Сез бик гади булмаган чорда КДАТУ ректоры итеп куелдыгыз. Ректор сайлауларында катнашуыгыз – уйланылган һәм кыю адым иде. Һәм Сез ирешкән нәтиҗә тагын да кыйммәтрәк – бүгенге көндә КДАТУ заманча укыту-инновация үзәге һәм Россиянең әйдәп баручы вузларыннан берсе.

Кискен һәм уйланылмаган адымнар ясамыйча, әмма таләпчән кеше буларак, Сез теләсә кайсы уку йорты җитәкчесе өчен мөһим булганны эшли алдыгыз. Бүген университетны тәмамлаучыларның барысы да диярлек – стандарт булмаган фикерле, тирән белемле, үз юнәлешләре буенча һәркайда таләп ителгән компетентлы белгечләр.

Без барыбыз да уңайлы, көтелмәгән казалардан якланган йортларда яшәргә, яхшы юллардан йөрергә, матур кинотеатрларда булырга, спорт матчларын җайлы спорт комплексларында һәм дөнья дәрәҗәсендәге стадионнарда карарга телибез. Һәм менә Сезнең җитәкчелектәге вуз республикабыз халкы өчен акыллары һәм куллары ярдәмендә әнә шуларны булдыручы профессионалларны әзерли.

Бүген КДАТУ – әзерлекле, инновацион вуз, Татарстан аның белән горурлана, һәм монда Сезнең хезмәтегезнең өлеше зур.

Сезгә тагын да күбрәк идеяләр, планнар, проектлар теләргә рөхсәт итегез. Һәм, әлбәттә инде, аларны тормышка ашыру өчен ныклы сәламәтлек, уңышлар юлдаш булсын! Сезнең йортыгызга җылылык һәм уңайлылык иңсен!

Киләчәккә ориентир

Гадел Хөснетдинов,
«Татинвестгражданпроект» ДУП генераль директоры

Хөрмәтле Рәшит Корбангалиевич! Без моннан күп еллар элек танышкан идек, һәм ул шушы еллар дәвамында мин Сезне гаҗәеп энергияле, максатчан, кыенлыклардан курыкмый торган кеше, искиткеч әйдаман, кызыксынучан профессор буларак беләм.

Сезнең Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты ректоры вазыйфасындагы күпьеллык актив хезмәтегез аның эшчәнлеген камилләштерүгә, инновацион белем бирү программаларын кертүгә, фәнни һәм практик якларны берләштерүгә юнәлтелгән. Күбесенчә нәкъ менә Сезнең хезмәт нәтиҗәсендә Татарстанның гына түгел, гомумән Россиянең төзелеш һәм сәнәгать өлкәләренә республика куйган стратегик һәм амбициоз бурычларны тормышка ашырырга әзер булган яшь, көндәшлеккә сәләтле белгечләр килә. Шундый профессионаллардан башка аның алдынгы предприятиеләрен үстерү мөмкин түгел, алар исәбенә «Татинвестгражданроект» ДУП та керә.

Сезнең эшкә бирелгәнлегегез, күтәренке кәефегез, һәрвакыт яңалыкка омтылышыгыз – бу сыйфатларыгыз университет студентларын һәм укытучыларын гына түгел, якын-тирәгездәге һәркемне илһамландыра һәм кешеләргә ориентир булып хезмәт итә.

Мин ышанам: киләчәктә Сезне тагын да кызыклырак проектлар, һөнәри уңышлар һәм казанышлар көтә!

Чын күңелемнән Сезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек һәм уңышлар телим.

Юбилеегыз белән!

PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН
TATARSTAN

Ветераннарга бүләк ясагыз – «Татарстан» журналына яздырыгыз!

2017 елның II яртыеллыгына
«Татарстан» журналына язылу дәвам итә

П 2381 **татар телендә** 900 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 900 сум 00 тиен

Реклама 16+

КҮГӘРЧЕН

«Татарстан» журналы, кызыклы атамалы татар авылларын, аларның тарихын һәм бүгенге яшәешен яктырту максаты белән, яңа сәхифә башлады. Сез дә безгә үз авылларыгызның хикмәтле яклары, гыйбрәтле хәлләре, уңган-булган кешеләре турында яза аласыз.



Балык Бистәсе районы Күгәрчен авылы

PRESSA.RU

«Мең душлы» Күгәрчен

Бу авылны элек-электән «мең душлы» дип йөрткәннәр, чөнки гомер-гомергә биредә меңнән артык кеше яшәгән. Сүз Балык Бистәсендәге Күгәрчен авылы турында бара. Күпләр Күгәрченне шәл бәйләүчеләр авылы дип тә белә, чынлап та бер гасыр дәвамында шәл бәйлиләр монда. Тагын... хатын-кызларның бик тә үзенчәлекле бер мавыгулары бар. Республиканың башка бер генә авылында да бу эш белән шөгыльләнмиләр. Нинди мавыгу ул? Һәм «мең душлы» Күгәрчен исеме бүген җисеменә туры киләме? Болар турында язманы укыгач белерсез.

Автор:
Руфия Фазылова

ДӘЛИЛЛЕ ТАРИХ

Гадәттә, сәфәргә баргач та, иң беренче эш итеп, авылның тарихын яхшы белгән кеше белән очрашабыз. Күгәрчендә мондый кешене хәтта белгеч дип тә атап була, туган авылы турында ике китап (дөрес, берсе брошюра) язган Габделхак Мингарипов бар. Җирле үзидарә Советы рәисе, Күгәрчен урта мәктәбе директоры, математика, тарих укытучысы, Туган авыл музее җитәкчесе булып эшләгән, бүген лаеклы ялда булган әлеге мөгаллим менә нәрсәләр сөйләде:

– 1968 елда авылыбыз тарихын археолог Равил Фәхретдинов өйрәнде. Аның хезмәтләренә, туган авылыбыз тарихын язган Гомәр Әгъзамовның язмаларына, шулай ук авыл картларының истәлекләренә таянып, 2014 елда «Авылым Күгәрченем» исемле китап яздым. Аны нәшер итәргә Күгәрчен авылы эшмәкәрләре Данил Нәбиуллин белән Зөлфәт Гыйлемханов ярдәм итте. Күгәрчен – бик борынгы авыл. Аңа 1367 елда нигез салынган дигән фикер яши. Авылыбыз янында Иске зират бар. Бүгенгәчә анда иске каберлек саклана. Зират турында атаклы галимнәр язган «Археологические памятники Татарской АССР» дип аталган китапта да әйтелә. Анда безнең иске зираттагы каберлекнең XIV–XVI гасырларга каравы искәртелә. Равил Фәхретдинов, Күгәрченгә килгәч, әлеге иске зиратта казу-тикшеренү эшләре үткәрә. Һәм, чыннан да, каберлектә мөселман кешесе җирләнү турында әйтә (кабер кыйблага таба урнашкан). «Каберлек ундүртенче йөзләргә карарга тиеш», – ди. Шуннан Равил Фәхретдинов авылның аксакалы Бикмөхәммәт Хәбибуллин белән очраша. Аксакал галимгә бабаларыннан ук калган бик иске бер китап турында сөйли:

– Китап кулдан-кулга йөреп таушалып, тузып юкка чыкты. Әмма шуны төгәл беләм: китапның бер буш битенә: «1367 ел. Агамкол бабай белән

Фото: Ната Смирнова

углы Хуҗамкол һәм тагы да ике гаилә, юлдашлары белән бергә килеп, Кугәрченгә нигез салып утырганнар» дип язылган иде, – ди.

Күрәсең, бабаларыбыз, киләчәк буыннар авыл турында белсен дип, махсус шулай язган. Һәм без аларга бик рәхмәтле. Һәр кеше туган авылы, нәсел-шәҗәрәсе турында белергә тиеш.

Габделхак Мингарипов туган авылы турында күп өйрәнгән, архивларда утырган. Аерым документларга тап булган:

– Мәскәү Үзәк Дәүләт Борынгы Актлар архивындагы (РГАДА) документларда Кугәрчен авылы турында беренче телгә алыну 1561–1566 нчы елларга туры килә. Сүз 1552–1557 нче елларда, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, аның җирләрен исәпкә алу турында бара, – диде.

Ә менә авылның исеме турында аерым риваятьләр генә калган. Имеш, кешеләр килеп урнашканнан соң, алар янына кугәрченнәр очып килгән. (Гадәттә, әлеге кошлар кешеләр булган җирдә яши бит). «Бу яхшы билге, нигезебездә тынычлык булыр», – дип, авылга Кугәрчен исеме биргәннәр.

ЙОРТ САЕН – ӨЧӘР СЫЕР

Кугәрчен авылында бүген 465 хуҗалык бар, 1155 кеше яши. Салаларда эшсезлек чәчәк аткан чорда кугәрченлеләр бу проблемадан чыгу юлын тапкан: күп итеп мал асрыйлар.

– Республиканың авыл хуҗалыгы белән таныш кешеләр белә, Балык Бистәсендә фермерлар күп, – дип сөйләде Кугәрчен авылы җирлеге башлыгы Альберт Сафин. – Безнең җирлектә 5 крестьян-фермер хуҗалыгы бар. Алар берничә еллап эшли, аякта нык басып торалар. Шулай ук фермер булып теркәлмичә, өч-биш сыер тотучылар күп. Ит өчен ун-унбиш баш үгез-тана үстерүчеләр дә бар. Мал асрау өчен дәүләт биргән төрле грантлардан файдаланалар.

Мал дигәннән, Кугәрчендә республикага билгеле сугым комплексы бар. Бик зур ул. Анда эшкәртелгән ит Казанның зур сәүдә үзәкләрендә сатыла. Ә иң мөһиме – авыл кешеләренә эш булган. Кугәрченнең алтмыш кешесе биредә эшли икән.

– Республиканың төрле районнарыннан мөгезле эре терлек алып кайтып суябыз, – дип сөйләде Кугәрчен сугым комплексы җитәкчесе Рәүф Хашимов.

– Мисал өчен апрель аенда гына да меңнән артык баш мөгезле эре терлек суйдык. Итне вакуумлы пакетларга тутырып Мәскәү, Пермь шәһәрләренә дә җибәрәбез. Киләчәккә тагын да зураерга ниятлибез. Ассортиментны да киңәйтәсе иде...

Журналыбызның узган санында 47 йортлы Арча районының Иске Му авылы турында: «Биредә мәктәп, балалар бакчасы, мәчет, кибет, ФАП та юк», – дип язган идек. Кугәрчендә исә урта мәктәп, зур балалар бакчасы, ике мәчет, биш кибет, ФАПтан кала, ветеринар үзәк, полиция пунктына кадәр бар. Зур бер бистәне хәтерләтә ул.

– Халык тик утырмый бездә, – дип сөйләде Альберт Сафин. – Читкә дә китеп эшлиләр, ирләр балта остасы буларак дан тота, ә хатын-кызлар шәл бәйләп сата. Теләсәң, авылда яшәрлек кенә акча эшләп була. Әнә, кешеләрнең йортларына керегез, каралты тулы мал, өйләре ялт иткән. Күбесенең бәдрәфе, мунчасы өйдә. Шәһәрдән ким яшәмиләр.

«СОРАУ КИМЕДЕ»

«Шәл бәйләп сатучы» хатын-кызларны эзләп озак йөрисе түгел, биредә һәр хатын-кыз буш вакыты булган саен кулына инә белән җеп ала. Без исә авылның оста, атаклы шәл бәйләүчесе (сатучысы да!) саналган Галия апа Динмөхәммәтова белән очраштык. 70 яшен тутырып килүче Галия апа әле кызлар кебек, ялгызы өй юып ята иде:

– И, балалар, бөтен пычракны күреп китәсез, – дип уңайсызланды ул. – Киләсегезне алдан белмәдем бит. Әйдә, узыгыз инде, – дип өенә чакырды. Галия апа ике төргәк шәл чыгарды, агы да, карасы да бар. Зурлыклары да төрле. Шәлләрне күтәреп караган идем: җип-җиңел, йоп-йомшак...

– Бу кадәр шәлне үзең бәйләдеңме? – дим Галия апага.

– Юк, барысы да үзем бәйләгән түгел. Кара мамыктан булганнары минеке, арадан бер-икесе туганнарныкы,

сатарга дип бирделәр, ә ак мамыклы шәлләрне Оренбургтан китерәләр, – диде Галия апа.

– Шулай кеше бәйләгән шәлләрне дә сатасызмы? – дим.

– Элек бик саттым, кызым. Хәзер яшь бара, зур сумкалар асып авылдан-авылга йөреп булмый.

– Районнарга да чыгасызмы?

– И, Татарстанның кайсы гына районында шәл сатмадык! Сызрань, Мәскәү, тагын башка шәһәрләргә кадәр йөри идек. Соңгы елларда юл чыгымнары үз-үзен акламый башлады: шәлне бик алмыйлар, билет бәясе кыйммәт. Еракка йөрүләрне туктаттым. Республика районнарына чыгып керәм.

– Сорау аз булгач, шәл бәйләүчеләр кимегәндер? – дим.

– Кимеде, ләкин минем кебек тик утыра алмаучылар күп әле. Бәйләү – чир ул. Бер өйрәнгән кеше ансыз тора алмый. Бездә кызлар 7–8 яшеннән шәл бәйли. Мин үзем дә 7 яшемнән бәйләргә өйрәндем. Азрак буш вакыт булдымы, тизрәк кулга инә аласы килә. Шәлгә сорау кимегәч, хатын-кызлар бияләй, йон оекбаш бәйләп сата. Мамык шәлнең бәясе 3 мең сум булса, бияләй-оекбашлар 350-400 сум тора. Шәл бит бер алгач бик озакка җитә, ә оекбаш туза. Шуңа халык соңгысын теләп ала. Кәҗә мамыгыннан бәйләнгән бияләйләр бик җылы да, матур да.

Кугәрчен хатын-кызлары шәлне бер гасыр буе бәйли икән инде. Авылның дәрәҗәле кешесе булган Кыям мулланың хатыны – Зәйтүнә Яруллина-Шәрәфиева Кугәрченнең беренче дипломлы укытучысы булган. Шәл бәйләүне бирегә нәкъ менә ул алып килгән. Аннан күреп башка хатын-кызлар да бу шөгыльгә өйрәнгән. 1930 елга кадәр Кугәрчендә шәлне сарык йонынннан бәйләгәннәр. Шуннан, кешеләрдән ишетеп, сарык йонына куян мамыгы да куша башла-

ганнар. Болай иткәч шәл йомшаграк та, җылырак та булган. Ә 1965 нче елларда хатын-кызлар шәлне кәҗә мамыгыннан бәйләүгә күчкәннәр. Яңа үрнәкләр өйрәнгәннәр. Күгәрчен ир-атлары кәҗә мамыгына дип, Донбасс, Ростов, Волгоград якларына кадәр барган. Соңрак, кәҗә асраучы шул як кешеләре, үзләре дә Күгәрченгә килеп, мамык саткан. Бүген исә кирәк кеше мамыкны үзе алып кайта. Казанда кәҗә мамыгы сата торган аерым нокталар бар икән. Хәер, шәлгә сорау кимегәч, кәҗә мамыгы элеккечә күп кирәк түгел.

ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨРӘШЕ?

«Республиканың башка бер генә авылында да бу эш белән шөгыльләнмиләр», – дип укучыларыбызда кызыксыну уятканмындыр, мөгаен. Ә хәзер игътибар: Күгәрчен хатын-кызлары... көрәшә! Әйе, чын-чынлап, батыр исемен алу өчен мәйданда көрәшәләр. Уйнап кына башланган бу шөгыль белән Күгәрчен хатын-кызлары бөтен республикага дан казанган.

– Хатын-кызлар көрәше беренче тапкыр 1985 елның Сабантуй программасына кертелгән иде, – дип сөйләде авыл җирлеге башлыгы Альберт Сафин. – Нәфис затлардан ир-егетләр көрәшендәге кебек профессиональлек таләп ителмәде. Хәтта башта аларга очко-баллар да куелмады. Хатын-кызлар көрәшенең максаты – Сабантуй программасын кызыклырак, үзенчәлеклерәк итү иде. Беренче елда берничә хатын-кыз гына көрәшсә, тора-бара бу киң колач алды. Хәтта читтән килүчеләр дә табылды. Җиңүчегә тәкә, башка кыйммәтле бүләкләр тапшырыла.

2005–2010 елларда Күгәрчендә хатын-кызлар көрәше бик нык популярлашып ала. Гүзәл затларның бил алышканын карарга хәтта җырчы Салават Фәтхетдинов та килә. Сабантуйда көрәшкән һәр хатын-кызга кыйммәтле бүләкләр, җиңүчегә акчалата приз бирә. Бүген дә Күгәрчендә Сабантуйлар хатын-кызлар көрәшеннән башка узмый. Ләкин соңгы елларда көрәшүче гүзәл затлар кими төшкән. Өлкәннәр картая, ә яшьләр киләмгә чыгарга бик теләк белдерми икән.

– Минем көрәшкә берничә тапкыр чыкканым бар, – дип сөйләде Күгәрчен авылында яшәүче Илзирә Динмөхәммәтова. – Кайберәүләр көрәшне уен дип кенә кабул итә. Ә анда хатын-кызлар чынлап көрәшә. Соңыннан хәтта берничә көн гәүдә сызлап интектерә. Көрәшүче хатын-кызлар турында нинди генә фикер ишетмәдек, бигрәк тә читтән килгән кешеләр, аерым журналистлардан. Янәсе, бу хатын-кыз эше түгел, безнең мөселманнарга бер дә килешми. Мин көрәшнең бер начар ягын да күрмим. Зур-зур ярышларда хатын-кызлар штанга күтәрә бит, ә милли көрәштә катнашырга ярамыймы?! Җирле җитәкчеләр, көрәшүче гүзәл затлар өчен хәтта җиңел материалдан, баштанаяк гәүдәне каплый торган комбинезонга кадәр тектерде. Хәлдән килгән кеше көрәшсен. Безнең Сабантуйның бер үзенчәлеге бит ул!

ЗӘҢГӘР КҮЛЛЕ КҮГӘРЧЕН

Күгәрчен авылы җирлегенә Зәңгәр күл авылы да керә, аралары өч чакрым ераклыкта гына урнашкан. Авыл җирлеге башлыгы Альберт Сафин безне Зәңгәр Күлгә барып килергә бик кыстады:

– Күгәрчен белән Зәңгәр Күл гомергә бергә яшәгән, бер авыл җирлеге булган. Ике авыл арасында узган ел Ял паркы төзедек, шуны карап китегез, миллион сумнан артыкка басты ул. Зәңгәр Күл кечкенә авыл булса да, анда өч фермер бар, – диде.

Күгәрчен белән Зәңгәр Күл авыллары арасындагы Ял паркы, чынлап та, җирле халык өчен менә дигән ял итү урыны икән! Машиналар кую өчен махсус мәйдан да ясаганнар. Шәһәр паркларыннан бер дә калышмый. Тирә-ягын чыршылар уратып алган җәяүлеләр аллеясы, ашап-эчеп утыру өчен «бура йорт» һ.б. Миңа исә гүзәл чишмә ошады: махсус ясалган буага ага ул. Шул рәвешле авыл башында күл барлыкка килгән. Зәңгәр күлнең икенче башында тагын бер күл бар икән.

Кызганыч, кайчандыр гөрләп торган Зәңгәр Күл бүген ничектер бушап калган төсле. Кечкенә кибеттән кала бирeдә бер социаль объект та юк. Балалар Күгәрчен урта мәктәбенә йөри, гомумән, нәрсә булса да, җирле халык күрше авылга бара.

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ!



Менә шуңа да күгәрченлеләр зәңгәр күлләрне якын итеп, авылдаш дәрәҗәсендә күрә икән.

Зәңгәр Күлдә эш юк, хәтта фермалар да беткән. Әле ярый авылда тырыш ир-атлар табылган: өч гаилә аерым фермер булып оешкан. Аларның төзек, яңа фермалары, зур йортлары әллә кайдан күренеп, авылның исән икәнлегенә ишарә ясый сыман. Без Зәйнуллиннар хуҗалыгына тукталдык. Хуҗа кеше, Айрат абый өйдә юк иде, хәер, шулай булачагын алдан белдем дә, чәчү вакыты бит.

– Гаилә фермасы төзү өчен узган ел дәүләттән, Грант нигезендә, 1 миллион 300 мең сум акча алдык, – дип хуҗалыклары белән таныштырып чыкты Тәгъзимә апа Зәйнуллина. – Айрат җир эшкәртү белән күптәннән шөгыльләнә, 200 гектар сөрү җире бар. Колхоз җирләрен дә арендага алды. Аннан күп итеп мал асрыйсы да килде. Яңа фермада бер ел үгезләр тоттык, аларны иткә суеп озаткач, 37 баш тана алып кайттык. Бер елдан, Алла боерса, алар савым сыеры булачак. Бүген үгез асрау файдалы түгел, иткә бәя түбән. Ә менә сыер үз-үзен аклый, сөткә бәя артты бит.

Зәйнуллиннар гаиләдә җиде кеше. Айрат абый төп нигездә калган, эти-әнисе Фоат абый белән Фатыйма апа һәм өч балалары яши бирә. Җитмеш дистәне тутырсалар да, әби белән бабай да маллар караша икән, балаларны әйткән дә юк.

– Безнең гаиләдә бер кеше дә эшсез утырмый,-дип елмайды Фоат абый. – Хәлдән килгәнчә без дә булышырга тырышабыз. Эшләсәң картлыкка бирешмисең ул.

Зәйнуллиннар эшкә ике авылдашларын да чакырганнар. Киләчәккә тагын да зураеп, ныклы фермер хуҗалык төзәргә ниятлиләр.

... Халык телендә «мең душлы» дип аталган Күгәрчен бүген дә җисеменә туры килә, шунысы сөендерде. Ә Зәңгәр Күлнең уңган ир-егетләре соклану уятты. Әйе, авылларны бары тик Зәйнуллин Айрат кебек кешеләр генә саклап кала ала.

P.S. Соңыннан Фәния апа Шакирова безне ит бәлеше ашарга үзләренә чакырды. «Безнең якта яраткан, хөрмәт иткән кунакларны бәлеш ашатмый җибәрмиләр», – диде. Пушкинга ияреп: «Без дә анда булдык, бәлеш ашадык, чәй эчтек, аздан гына телне йотмадык», – диясе килде.

PRESSA.RU

АЙ КӘЕФЕ: **ШИГЫРЬЛЕ ҺӘМ СӘХНӘЛЕ**

27 апрельдә «Угол» иҗат лабораториясенә җыелган тамашачы гадәти булмаган шартларга куелды – моңарчы ачып керергә тәвәккәлләмәгән ишекләре артындагы үз дөньясына аяк атлады. Кем өчен, ни өчен куелды бу спектакль һәм нәрсәне үзгәртте?

Ландыш Әбүдәрова, «Сөембикә» журналының бүлек мөхәррире, спектакльнең тамашачысы:

– Чынбарлыкта без көндәлек мәшәкатьләр белән вакыт-гомер узганны да искәрмибез, хисләрне дә менә бусы мондый төсмерле, монысы болай, дип сортларга бүлгәләп, аерып билгеләмибез. Реаль чынбарлык күпкә тонырак. Режиссер Резеда Гарипова тудырган спектакльдә исә ул хисләрнең, образларның үзләрен күрдек, алар гиперреаль иде. Сәгать ярым эчендә хисләр төрле метаморфозалар кичерде. Кайсыдыр агрессиягә әйләнде, кайсыдыр юашланды, кайсыдыр иреккә очты, кайсыдыр, киресенчә, йөгәнләнде... Моңа кадәр без акка кара белән язган шигырьне укый, сәхнәдән тыңлый гына идек, ә бу юлы шигырь сәхнәгә үзе чыкты.

«Угол» иҗат лабораториясе мәйданын яхшы белгән тамашачы аның үзгә бер – камералы, караңгы-сүрән, беркадәр интим, әмма шул ук вакытта перспективаны тирәнгә юнәлдерүче атмосферасы белән дә якыннан таныш. Спектакль башында ук безне әнә шул җәлеп итте һәм кәефне, таныш кодларга, символларга тоташтырып, Вуди Алленның «Полночь в Париже» рухынарак көйләде. Баш очында Ван Гогның көлтәләнеп, көйрәп, кайнап торган йолдызлы күге айкалып алды да, чәчелеп-сибелеп, микрофон алдына чыгып баскан җырчының джаз аһәңнәренә сеңеп бетте. Ә аңарчы Тинчурин театры артисты Зөлфәт Закиров герое залга көлемсерәүле, чак кына мыскыллы да карашын төбәп: «Йокысыннан айнып сискәнә дә Казан, кыяр-кыймас кына сорый: «Без кайда соң?!» – дип эндәшкән иде инде. Гомумән, бу спектакльдә, гаять нечкә-нәзберек фактура – шигырь тексты белән эш итүгә карамастан, ирония, хәтта ки сарказмга да урын җитәрлек бирелгән иде.

Фото: Юлия Калинина



Спектакльнең авторлары – шагыйрә Луиза Янсуар һәм режиссер Резеда Гарипова нәкъ менә шушы эффектка омтылганнар да икән – эштән, көндәлек мәшәкатьләрдән арып-талчыгып килгән тамашачыны көтелмәгәнчә халәткә «күчерү». Моны спектакль башында ике персонаж – Арлекин (Йолдыз Миңнуллина) һәм Пьеро (Рәдиф Кашапов) да үтемле башкарды.

«Узган гасыр башындагы кабаре, барлар мохитен тудырып, без тамашачыны иҗади дөньяга да алып кереп китәбез», – ди режиссер. Кәеф шунда ук үзгәрә: сәхнәгә ургылып килеп кергән берсеннән-берсе җете, хәтергә уелырдай персонажларның хис кичешләрен күз да йоммый, тын да алмый күзәтергә керешәсең.

Һәм менә, Париж, Монмартр, Дега, Ван Гоглардан башланган иҗади бу дөнья тора-бара шулкадәр таныш төсмерләр ала – үтә дә «безнекенә» әверелә. Бабасы белән көтү көтүче малай булып та әверелә ул, Сөембикә авазы булып та иңри, 41нче ел дәһшәтен, Әфган, Чечняларның сөремен дә бөркеп ала, ялантәпиле мәҗүси-илаһи биюгә дә әверелә. «Артык чын бу шигырьләр», – дигән иде спектакльдән соң тамашачыларның берсе. «Артык безгә охшаган бу каһарманнар», – дип кайтып китте күпчелеге.

Ә спектакль үзе, адәм баласының никадәр катлаулы зат икәнлегенә ишарә итепме, ирония белдерепме, могҗизаларга ышанырга чакырыпмы, «Ачылмаган ишек» дигән финал белән тәгәлләнде.

«Эксперт Татарстан» басмасы:

– Спектакль зур аншлаг белән узды. Залга сыеп бетә алмады тамашачы. Әмма барысы да бер сүзне кабатлады: «Урыннар җитмәсә, басып та тора алабыз». Әмма кайтып китәргә җыенучы берәү дә юк иде.

Ишек образын сайлап, спектакль авторлары ялгышмаган: сәхнәдәге тамаша барышында үз тормышыңа ишекләрне ачып, аналогияләр ясап утыру мөмкин булды. Луиза Янсуар әйткәнчә: «Кайчан кайсы ишеккә ачкыч яратасыңны, һәм кайсы ишек артында сине ни көтәсен белеп булмый бит».

Резеда Гарипова, спектакльнең режиссеры:

– «Мин шигърияттән бик ерак кеше: шигырьне укымыйм да, аңламыйм да», – диючеләр күпчелекне тәшкил итә. Гадәттә, без шигырьне рифма-ритмнан торган текст буларак кабул итәргә күнеккәнбез. Әмма сәхнәдә ул текст булудан туктый, аның чын асылы күренә. Ул кабат кеше язмышы булып әверелә.

Бүгенге заманча театрда сүзнең кыйммәте инде элеккеге түгел – күбрәк режиссер почеркына игътибар бирә тамашачылар да, театр тәнкыйтьчеләре дә, куелышка, формага. Ә миңа спектакльдә нәкъ менә сүз кадерле. Мәгънә. Эчтәлек. Шигъри спектакльдә бит акылга сыймастай декорацияләр, купшы сценография артына гына «качып» котылып булмый.

Луиза Янсуар, шагыйрә:

– Бүген шигырь халыкка кирәкми диючеләр белән һич килешмим. Кеше үз гомерендә һәрчак юанычка мохтаҗ. Ә шигырь шуның иң интим, иң сыналган бер формасы. Тормыш ыгы-зыгысы эчендә кайнаганда, ничек кенә көчле булып күренергә туры килмәсен кешегә, эчендә яшеренеп яткан «нарасые» барыбер дә наз көтә аның, яклау, саклау.

PRESSA.RU

ГКЗ
ГЛАЗОВСКИЙ
комбикормовый
завод

Входит в
группу компаний
КОМОС
ГРУПП

ПОДБИРАЙТЕ КОМБИКОРМА ПРАВИЛЬНО!

ДЛЯ ЛИЧНЫХ ПОДСОБНЫХ ХОЗЯЙСТВ.

Комбикорма ЭКОНОМ – «Доброе подворье» разработаны специально для животных, которые содержатся в условиях домашних хозяйств с традиционной технологией выращивания. Необходимое количество питательных веществ, витаминов и минералов обеспечат здоровье и продуктивность ваших животных.

• Фасовка 5 и 25 кг. •

ДЛЯ ПРОМЫШЛЕННЫХ ЖИВОТНОВОДЧЕСКИХ КОМПЛЕКСОВ И ПТИЦЕФАБРИК.

Рецептуры комбикормов ПРОФИ разработаны с учетом рекомендаций от создателей пород и кроссов сельскохозяйственных животных и птицы, оптимальны для применения в условиях промышленных комплексов с интенсивной технологией выращивания.

• Фасовка 25 и 40 кг. •

Реклама

АДРЕСА ТОРГОВЫХ ТОЧЕК

УДМУРТИЯ

«Глазовский комбикормовый завод»
г.Глазов,
ул. Красногорский тракт, 15
Отдел продаж:
тел.:(34141)3-85- 33
Фирменный магазин:
тел.:(34141)3-81- 20

«Можгинский элеватор»
г.Можга,
ул.Железнодорожная, 93
Фирменный магазин:
тел.: (912)019-54- 60

УДМУРТИЯ

«Крестьянский рынок»
Завьяловский район,
уд.Пирогово, ул.Торговая, 1
тел.: (3412)62-33- 89

БАШКИРИЯ

«Янаульский элеватор»
г. Янаул,
ул. Социалистическая, 19А
Фирменный магазин:
тел.: (34760)5-95-93

ТАТАРСТАН

«Крестьянский двор»
г. Набережные Челны,
п. Сидоровка,
ул. Магистральная, 47 Б
тел.: (927)416-95-07

«ИП Садреев»
г. Чистополь,
ул. Привалова, 86
тел.: (917)905-95-85

«ИП Минабутдинова»
г. Казань,
Горьковское шоссе, 113 В
тел.: (919)633-83-32

ПЕРМСКИЙ КРАЙ

«Агро-Торг»
г. Пермь,
ул. Буксирная, 4
тел.: (922)24-34-224

КИРОВСКАЯ ОБЛАСТЬ

«Оникс»
тел.: (912)874-82-00
тел.: (912)852-31-93